АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ АРХЕОЛОГИИ ИМ. А.Х. ХАЛИКОВА

**АЙРАТ СИТДИКОВ, ФАЯЗ ХУЗИН**

# ГОРОД БОЛГАР:

# МУСУЛЬМАНСКИЙ МИР НА ВОЛГЕ

**КАЗАНЬ**
**2026**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

А.Х. ХАЛИКОВ ИСЕМЕНДӘГЕ АРХЕОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫ

**АЙРАТ СИТДИКОВ, ФАЯЗ ХУҖИН**

# БОЛГАР ШӘҺӘРЕ:

# ИДЕЛ БУЕНДА МӨСЕЛМАН ДӨНЬЯСЫ

**КАЗАН**
**2026**

УДК 902
ББК 63.4
А87

Утверждено к печати:
Ученым советом Института археологии им. А.Х. Халикова АН РТ

**Рецензенты:**
д.и.н., академик АН РТ И.А. Гилязов, д.и.н. И.К. Загидуллин

**Редакторы:**
д.п.н., академик АН РТ Р.М. Мухаметшин
д.и.н., академик АН РТ Р.Р. Салихов

**Редакционная коллегия:**
д.и.н. Белорыбкин Г.Н., д.и.н. Зеленеев Ю.А., д.и.н. Иванов В.А.,
д.и.н. Никитина Т.Б., д.и.н. Пигарев Е.М., к.в.н. Асылгараева Г.Ш.,
к.и.н. Миргалеев И.М., к.и.н. Хамидуллин Б.Л.

**А87 Айрат Ситдиков, Фаяз Хузин**
**Город Болгар: мусульманский мир на Волге = Болгар шәһәре: Идел буенда мөселман дөньясы. – Казань: Изд-во АН РТ, 2026. – 380 с.**

**ISBN 978-5-9690-1515-9**

Книга посвящается 1100-летию официального принятия ислама волжскими булгарами (922) – предками современных татар, и адресуется широкому кругу читателей. В ней рассказывается об истории принятии ислама при правителе Алмуше с мусульманским именем Джа’фара ибн Абдаллаха и распространении его среди населения Волжской Булгарии и Золотой Орды, дальнейшем превращении Великого Болгара в центр притяжения мусульман России и его роли в сохранении этнической идентичности татар.

Китап Идел буе болгарлары тарафыннан Ислам динен рәсми кабул ителүнең 1100 еллыгына багышлана һәм киң катлам укучыларга адреслана. Укучыларга тәкъдим ителгән әлеге фәнни-популяр басмада Болгар хакиме Җәгъфәр ибн Абдаллаһ (Алмыш) хакимияте вакытында Исламны рәсми рәвештә кабул итү тарихы, яңа динне Идел буе Болгары һәм Алтын Урда халкы арасында тарату, шуннан соңгы чорларда Бөек Болгар шәһәренең Россия мөселманнарын җәлеп итү үзәгенә әверелүе һәм татарларның этник тәңгәллеген саклауда Ислам диненең роле яктыртыла.

ISBN 978-5-9690-1515-9

© ГНБУ «Академия наук РТ», 2026
© Институт археологии им. А.Х. Халикова, 2026
© А. Ситдиков, Ф. Хузин, 2026

*1100-летию принятия ислама волжскими булгарами – предками современных татар – посвящается*

*Идел буе болгарлары тарафыннан Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышлана*



## СОДЕРЖАНИЕ


К читателям ....................................................................................................8

**Глава 1. Ислам в Волжской Булгарии**

922 год в истории булгар: официальное принятие ислама............................18

Самая северная страна в мусульманском мире .............................................28

**Глава 2. Город Болгар и мусульманская культура Золотой Орды**

Ислам на Волге в золотоордынское время.....................................................96

Город Болгар – духовный центр ислама в Золотой Орде ...........................130

Болгар ал-Джадид – столица Казанского ханства........................................234

**Глава 3. Болгар – символ духовной памяти мусульман России**

Мусульманская культура татар в Российском государстве .........................262

Изучение и сохранение историко-культурного наследия Болгара .............284

Возрождение: Болгар в современной мусульманской культуре ..................348

Заключение ..................................................................................................372

Литература ................................................................................................376

## ЭЧТӘЛЕК


Укучыларыбызга мөрәҗәгать .......... 9

**Беренче бүлек. Идел буе Болгарында Ислам дине**

Болгар тарихында 922 нче ел: Ислам динен рәсми кабул итү .......... 19

Ислам дөньясындагы иң төньяк ил .......... 29

**Икенче бүлек. Болгар шәһәре һәм Алтын Урданың мөселман мәдәнияте**

Алтын Урда чорында Идел буенда Ислам дине .......... 97

Болгар шәһәре – Алтын Урданың ислам рухи үзәге .......... 131

Болгар әл-Җәдид – Казан ханлыгы башкаласы .......... 235

**Өченче бүлек. Болгар – Россия мөселманнарының рухи хәтере символы**

Россия дәүләте составындагы татар халкының мөселман мәдәнияте .......... 263

Болгарның тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү һәм саклау .......... 285

Яңарыш: хәзерге Ислам мәдәниятендә Болгар .......... 349

Йомгак .......... 373

Кулланылган әдәбият .......... 376

***1100-летию принятия ислама волжскими булгарами – предками современных татар – посвящается.***

Уважаемые читатели!

Ислам, как мировая религия, – это система духовных, философских, социальных и этических воззрений, кодекс регулирования обрядовой и общественной жизни, человеческих отношений, составная часть самосознания, важный фактор религиозной, идеологической, этнической, культурной консолидации народов.

21 мая 922 года (16 мая по старому стилю) булгарские предки современных татар Российской Федерации официально приняли ислам в городе Болгаре и стали частью мусульманского мира.

Прошло более 1100 лет после этого знаменательного исторического события. Ему предшествовал значительный этап в истории волжских булгар, связанный с постепенным их проникновением на новые земли, адаптацией населения к новым природно-географическим и климатическим условиям региона, становлением их в качестве лидирующей группы среди населения Волго-Камья.

Булгарское общество на Волге, включающее в себя тюркоязычные и финно-угорские племена, во главе с правителем эльтебером Алмушем, мечтавшим о создания мощного государства путём объединения разрозненных племён вокруг единого правителя, выбрало основой объединяющей силы для укрепления нового государства – ислам, широко распространявшийся в этот период на всей территории Евразии. Ислам стал идеологической основой, способной сплотить разноэтничные племена зарождающегося государства в единый народ.

Эта религия была знакома булгарам давно. Торговые и культурные связи булгар с Средней Азией и Закавказьем установились задолго до появления их государства на Волге. Немалая часть их была исламизирована ещё в Хазарском каганате, где

***Идел буе болгарлары тарафыннан***
***Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышлана***

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Ислам дине, дөньядагы башка диннәр кебек үк, рухи, фәлсәфи, социаль һәм этик карашлар системасы, йолаларны, иҗтимагый тормышны, кеше мөнәсәбәтләрен җайга салу кодексы, милли үзаңның аерылгысыз өлеше, халыкларның дини, идеологик, этник, мәдәни берләшүенең мөһим факторы булып тора.

922 елның 21 маенда (иске стиль буенча 16 майда) Россия Федерациясендә яшәүче хәзерге заман татарларының болгар бабалары Ислам динен рәсми рәвештә Болгар шәһәрендә кабул итеп, мөселман дөньясының бер өлешенә әверелде.

Бу истәлекле тарихи вакыйгадан соң 1100 елдан артык вакыт узды. Моңа кадәр болгарларның яңа җирләргә үтеп керүе, Идел буе төбәгенең табигый-географик һәм климат шартларына җайлашуы, Идел-Кама буйларында яшәгән җирле халыклар арасында алдынгы төркем буларак формалашуы белән бәйле шактый катлаулы һәм озын бер этапны үтүен дә күрсәтү кирәк.

Төрле кабиләләрне бер хаким тирәсенә берләштереп, көчле дәүләт төзү турында хыялланган хаким эльтебер (илтабар) Алмыш җитәкчелегендәге төрки телле кавемнәр һәм фин-угыр кабиләләре бергә тормыш кичергән Идел буендагы болгар җәмгыяте бу чорда Евразиядә киң таралган Ислам динен яңа дәүләтне ныгыту өчен берләштерүче көч итеп сайлый. Ислам дине оешып килә торган дәүләтнең төрле кавемнәрне бердәм халыкка берләштерергә сәләтле нигез булуын раслый.

Бу дин болгарларга күптән таныш булган. Болгарларның Урта Азия белән сәүдә һәм мәдәни элемтәләре Идел буенда дәүләт барлыкка килгәнче үк урнашкан иде. Аларның бер өлеше әле Хәзәр каһанлыгында яшәгән чорда ук мәҗүсилектән, дөресрәге, тәңречелектән, мөселман диненә күчкән була. Биредә, Хәзәр




*Династическая таблица правителей Волжской Булгарии. Часть художественно-пространственной экспозиционной инсталляции «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия». Авторы: И. Артамонов, А. Леухин, Ф. Валиуллин, Р. Шигабутдинов, И. Щетинин. Музей Болгарской цивилизации*

*Идел Болгары идарәчеләренең династия шәҗәрәсе. «Болгар цивилизациясе. Меңьеллыклар озынлыгындагы юл» исемле сәнгать-экспозиция инсталляциясенең бер өлеше. Авторлары: И. Артамонов, А. Леушин, Ф. Вәлиуллин, Р. Шиһабетдинов, И. Щетинин. Болгар цивилизациясе музее. Болгар*



*Памятник Кул Гали, Казань*
*Болгар шагыйре Кол Галигә һәйкәл. Казан*
*Скульпторы А. Балашов и А. Минуллина*

дәүләтендә, Шәрыкнең иң зур Ислам мәдәнияте үзәге – Хәрәземнан килгән мөселманнар күп була. Бу элемтәләр тугандаш төрки халыклар арасында рухи бердәмлекне ныгытуда сизелерлек роль уйнаган.

Шилки угылы Алмыш хан[1] Урта Азиядә таралган хәнәфи мәзһәбенең сөнни Исламын әле IX гасыр ахырында ук кабул иткәндер дип фаразлана. 902–908 елларда сугылган болгар тәңкәләрендә аның мөселман исеме Җәгъфәр ибн Абдаллаһ дип күрсәтелгән.

Болгарның Россия мөселман мәдәниятендә тоткан мөһим урыны шунда ки, 922 елда Багдад хәлифәлеге илчелеге, 2,5 мең чакрым юл үтеп, Болгарга барып җитә, һәм бу сәфәрнең нәтиҗәсе буларак, болгарлар рәсми рәвештә Ислам динен үз теләкләре белән кабул итәләр һәм бу диннең төньякка, Ислам цивилизациясе үзәкләреннән еракка таралуына юл ачыла.

Татарларның болгар бабалары белән бәйләнгән һәр нәрсәгә карата дулкынландыргыч мөнәсәбәтен аңлау кыен түгел. 2010 елның октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Болгарда Ислам динен рәсми кабул итү көнен истәлекле дата дип игълан итте һәм ел саен мөселманнар бу көнне зур бәйрәм буларак билгеләп үтәләр.

Хәтта республикадан читтә яшәүче татарлар да Болгарның изге урыннарына сәяхәт кылуны үзләренең изге бурычлары дип саныйлар, борынгы легендаларны, риваятьләрне хәтерләрендә саклыйлар. Дистәләр-



***Литое булгарское одностороннее подражание саманидскому дирхему с тамгой в виде перевернутой буквы «А». Русенихинский могильник. Погребение 3. Раскопки Т.Б. Никитиной***

***Әйләндереп куелган А хәрефе рәвешле тамга төшерелгән Саманилар дирһәменә охшатып эшләнгән берьяклы болгар коелмасы. Русинихино каберлеге (Түбән Новгород өлкәсе). Т.Б. Никитина казылмалары***

[1] Гади халык арасында Болгар хакимнәрен илтабар, әмир дип түгел, хан дип атау киң таралган. Бу социаль термин борынгы төркиләрнең каһан сүзеннән барлыкка килгән.



*Ю.Б. Лысогорский
Приход булгар на Волгу
Болгарский историко-архитектурный музей-заповедник*

*Ю.Б. Лысогорский.
Болгарларның Иделгә күчеп килүләре. Болгар цивилизациясе музее. Болгар*

было много мусульман, пришедших из Хорезма – крупнейшего центра исламской культуры Востока. Эти связи благоприятствовали упрочению духовного единства между родственными народами.

Шилки, отец эльтебера Алмуша, по некоторым сведениям, принял ислам среднеазиатского толка (суннизм ханафитского мазхаба) ещё в конце IX века. Приверженцем ислама был и Алмуш: на булгарских монетах, чеканенных в 902–908 годах, значится его мусульманское имя – Джа'фар ибн Абдаллах.

В 922 г. посольство Багдадского Халифата, пройдя более 2,5 тысяч километров, достигло Болгара, это привело к официальному добровольному принятию ислама болгарами и распространению новой религии на севере, вдали от центров исламской цивилизации.

В октябре 2010 года день официального принятия ислама в Болгаре Государственный совет Республики Татарстан объявил памятной датой, и каждый год мусульмане отмечают этот день 21 мая как большой праздник, восхваляя в молитвах Аллаха и его Пророка, своих правоверных предков и их благочестивых потомков.

Татары, проживающие даже далеко за пределами республики, считают своим долгом посещать святые места Болгара, хранят в памяти легенды и предания о них. Десятки известных татарских деятелей интеллектуалов вплоть до XX века с гордостью носили тахаллус «Булгари», прибавляя его к своим именам и фамилиям. В Казани и Ульяновске открыты скульптурные памятники булгарскому поэту Кул Гали, в Елабуге – хану Ибрагиму…

Книга, которую вы держите в руках, посвящена средневековому Болгару – одному из крупнейших городских центров, сыгравших ключевую роль в формировании средневековой булгаро-татарской урбанистической культуры на Волге в X – первой половине XV века, а впоследствии, в период Казанского ханства, ставшему символом единства мусульман России. Эту роль с до-

чә күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләре, XIX гасырга кадәр «Болгари» тәхәллүсен үз исемнәренә һәм фамилияләренә кушып, зур горурлык хисләре кичергәннәр. Соңгы елларда исә Казанда һәм Ульяндa болгар шагыйре Кол Галигә, Алабугада – Ибраһим ханга скульптура һәйкәлләре ачылды…

Сезнең кулыгыздагы китап Иделдә болгар-татар цивилизациясен формалаштыруда төп роль уйнаган мәшһүр шәһәр үзәкләренең берсенә, ә соңрак, Казан ханлыгы чорында, Россия мөселманнарының бердәмлек символына әверелгән урта гасыр Болгарына багышлана. Әлеге рольне ул бүген дә ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирас исемлегенә кертелгән «Вакыйгалар яки гамәлдәге традицияләр, идеяләр, ышанулар, сәнгать яки әдәби әсәрләр белән турыдан-туры яки матди



*Памятник хану Ибрагиму в Елабуге*
*Болгар әмире Ибраһимга һәйкәл. Алабуга*

яктан бәйле объект» дигән категориясе буенча лаеклы рәвештә башкарып килә.

Болгар мирасы, Россия Федерациясендә сан буенча икенче урында торган татар халкының борынгы



*М.Ш. Шаймиев в Болгаре на празднике «Изге Болгар җыены». 2018*
*М.Ш. Шәймиев «Изге Болгар җыены» бәйрәмендә. Болгар, 2018*

стоинством выполняет он и сегодня, будучи включённым в Список всемирного культурного и природного наследия ЮНЕСКО по категории, характеризующий его как *«объект напрямую или вещественно связанный с событиями или существующими традициями, с идеями, верованиями, с художественными или литературными произведениями и имеет исключительную мировую важность»*.

Наследие Болгара, сложившаяся коллективная память о предках современного татарского народа – второго по численности в Российской Федерации этноса, сакральность и преемственность мирного сосуществования культур представляют основу для устойчивого развития современного Татарстана. Важной определяющей чертой Болгара, его культуры является дух места, его характер и качества как территории принятия ислама, определившей цивилизационный выбор народа и имеющей главное смысловое и символическое значение.

Как убедится наш уважаемый читатель, город Болгар, расцвет которого пришёлся на времена правления золотоордынских ханов, даже после своего упадка не переставал привлекать паломников и любознательных путешественников. Его развалины посещали и весьма высокопоставленные особы: императоры Пётр I и Екатерина Великая, другие государственные деятели, крупные учёные с мировым именем.

Сегодня Болгар переживает, без преувеличения, «эпоху Возрождения». Благодаря активной деятельности Республиканского фонда возрождения памятников истории и культуры Республики Татарстан, созданного первым президентом республики М.Ш. Шаймиевым, и осуществлению принятой правительством РТ Комплексной программы «Культурное наследие РТ: древний город Болгар и остров-град Свияжск», проводились масштабные археологические исследования городища, работы по консервации и реставрации вновь открытых архитектурных сооружений и благоустройству территории памятника. Открыты новые музеи, среди которых уникальный Музей болгарской цивилизации. Событием огромной важности стало открытие Белой мечети и рядом расположенной Исламской академии, вновь превратившие Болгар в центр исламской культуры и одновременно – в объект внимания десятков и сотен тысяч российских и иностранных туристов, получающих истинное наслаждение от соприкосновения с древней и современной культурой татар татарского народа.

Важность 1100-летия принятия ислама Волжской Булгарией для истории и культуры народов нашей страны нашло официальное признание на государственном уровне: в 2021 году Распоряжением Президента РФ «О подготовке и проведении празднования в 2021 году 1100-летия принятия ислама Волжской Булгарией» событию был придан федеральный статус, а Указом Президента Республики Татарстан «О праздновании 1100-

бабалары турындагы гомуми бердәм хәтер, төрле мәдәниятләрнең тыныч яшәвенең асыл кадере һәм дәвамчанлыгы бу территорияне саклап калуга һәм тотрыклы үстерүгә нигез булып хезмәт итә. Болгар дәүләтенең, аның мәдәниятенең асыл кыйммәте һәм мөһим үзенчәлеге – халыкның үз тормышында цивилизация юнәлешен сайлавын билгеләгән төп мәгънәви һәм символик әһәмияткә ия Ислам динен кабул итү урыны булуында, аның рухы, үзгәлеге һәм характерының төп күрсәткече булып танылуында.

Хөрмәтле укучыбыз китапны уку барышында шуңа инаныр: Алтын Урда дәүләтчелеге чорында чәчәк атып яшәгән Болгар шәһәре, хәтта җимерелгәннән соң да зиярәт кылучы хаҗиларны да, кызыксынучан сәяхәтчеләрне дә үзенә җәлеп итүдән туктамаган. Аның харәбәләрен зират кылырга югары дәрәҗәле дәүләт җитәкчеләре, императорлар Петр I һәм Екатерина II, атаклы дин әһелләре, дөньякүләм танылган зур галимнәр килеп киткәннәр.

Бүгенге Болгар, (арттырып әйтүебез түгел!) чын-чынлап «Яңарыш чорын» кичерә. Республикабызның беренче президенты М.Ш. Шәймиев башлангычы белән оешкан «Татарстан республикасы тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу фонды»ның актив эшчәнлеге һәм хөкүмәтебез тарафыннан кабул ителгән «Татарстан Республикасы мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәрчеге» комплекслы программасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә, шәһәрлектә масштаблы археологик тикшеренүләр, ачык архитектура корылмаларын консервацияләү һәм реставрацияләү, шәһәрлек территориясен төзекләндерү эшләре алып барылды. Яңа музейлар ачылды. Алар арасында уникаль Болгар цивилизациясе музее да бар. Ак мәчет һәм янәшә урнашкан Ислам академиясе ачылу Болгарны яңадан Ислам цивилизациясе үзәгенә әйләндерде.

Болгарга бүген дә халык ташкыны агыла. Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән туристлар Идел буе болгарларының, аларның турыдан-туры варислары булган татар халкының борынгы һәм заманча мәдәнияте белән танышудан чын ләззәт алып китәләр.

Идел буе Болгар дәүләтенең Ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулу вакыйгасының илебез халыклары тарихындагы һәм мәдәниятендәге әһәмияте 2021 елда Россия Федерациясе Президентының «Идел буе Болгар дәүләтенең 2022 елда Ислам дине кабул итүенә 1100 ел тулуы уңаеннан билгеләп үтүгә әзерлек һәм аны үткәрү турында»гы Боерыгын кабул итүдә дә ачык чагылды. Әлеге вакыйга дәүләти федераль әһәмияткә ия булды һәм шул ук елда Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан «Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә Ислам динен кабул ителүгә 1100 ел тулуны билгеләп үтү турында»гы Указ белән өстенлекле чаралар исемлегенә кертелде.

Бәйрәм чаралары киң колачлы булды – Россиянең төрле төбәкләрен-

летия официального принятия Ислама Волжской Булгарией» эта дата закреплена в перечне приоритетных мероприятий.

Празднование имело широкий охват многих регионов России. Прошло более 150 мероприятий в разных областях во многих мусульманских уммах, в том числе и за рубежом. Кульминационное торжество состоялось 21 мая в Болгаре. В мероприятии приняли участие более 20 тысяч человек, включая государственных деятелей, представителей мусульманских и других религиозных конфессий, приехавших почти из 80 государств. В этом событии и связанных с ними мероприятиях, получивших общероссийский размах, воплотилось понимание богаство культурного наследия народов нашей страны и единство исторического прошлого.

*Панорама Болгарского городища с видом на центральный архитектурный комплекс Болгарского музея-заповедника*



дә, күп кенә мөселман өммәтләрендә, шул исәптән чит илләрдә дә, 150дән артык чара узды. Иң зур тантана 21 майда Болгарда – 922 елда Ислам дине рәсми кабул ителгән борынгы шәһәрдә үткәрелде. Чарада 80 гә якын дәүләттән килгән 20 меңнән артык кеше катнашты, шул исәптән, кунаклар арасында хөкүмәт вәкилләре, мөселман һәм башка дини конфессияләр әһелләре дә бар иде. Әлеге вакыйгада һәм аның белән бәйле гомумроссия масштабы алган чараларда илебез халыкларының мәдәни мирасының байлыгы һәм тарихи үткәненең бердәмлеге ачык чагылды.

*Болгар шәһәрлегенең үзәк өлешендәге архитектура корылмалары комплексы ягыннан гомуми күренеше*



# ГЛАВА 1

# ИСЛАМ В ВОЛЖСКОЙ БУЛГАРИИ

Родина ислама – древняя Аравия, которая в VII веке переживала процессы трансформации родоплеменных и зарождения новых общественных отношений. Переходный период, сопровождаемый острыми конфликтами между различными социальными слоями, политическими партиями и их учениями, выдвинул своих лидеров, способных вести за собой народ. В период кризиса средневекового арабского общества появление Мухаммада, сына Абдаллаха Абд ал-Муталлиба (570–632) с божественным посланием изменило жизнь бедуинов, а в будущем трансформировало многие сообщества на огромных пространствах Евразии. Мухаммад смог объединить вокруг ниспосланному ему божественного откровения разрозненные племена Аравии. Ислам, провозглашающий величие единственного и единого бога Аллаха, распространился далеко за пре-



*Рукопись Корана от слова tijarat в стихе 282 до слов nasiynā aw в стихе 286 Суры аль-Бакара. Пергамент. Стиль хиджази. VII век*

*Әл-Бәкарә сүрәсенең 282 аятендәге Tijarat сүзеннән башлап, nasiyanā сүзенә кадәр җөмләләрен эченә алган Коръән кульязмасы. Пергамент, хиҗази стиле. VII гасыр. © Дэвид коллекциясе, Копенгаген, Дания*

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

# ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРЫНДА ИСЛАМ ДИНЕ

Ислам диненең туган җире – VII гасырда борынгы ыруглык җәмгыятенең үзгәрүен һәм яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләр барлыкка килү процессын кичергән Согуд Гарәбстаны. Төрле социаль катламнар, сәяси партияләр һәм аларның өйрәтмәләре – идеологияләре арасында кискен конфликтлар белән үрелеп барган күчү чоры халыкны үзләре артыннан алга алып барырга сәләтле күренекле лидерларын тудыра. Урта гасыр гарәп җәмгыятенең иске, инде шактый какшаган нигезләре җимерелә башлаган бер чорда илаһи юллама – миссия белән килгән Габдулла ибн Габделмоталлиб улы Мөхәммәт (570–632) бәдәвиләрнең тормышын үзгәртә, ә алга таба исә ул Евразиянең гаять зур киңлекләрендә күп кенә җәмгыятьләр тормышын үзгәртеп коруга китерә.

Язмыш кушуы буенча вакыйгалар үзәгендә торып калган Мөхәммәт



*Макам аль-Харири. Группа всадников в ожидании праздничного шествия (седьмой макам). Яхья ибн Махмуд Аль-Васити. Багдадская школа живописи. 1237*

*Мәкам әл-Хәрири. Җайдаклар төркеме тантаналы марш башлану алдыннан (җиденче мәкам). Яхъя ибн-Мәхмүд әл-Васити. Багдад рәсем сәнгате мәктәбе, 1237. © Милли китапханә, Париж, Франция*




***Частичный вид на Мекку. Иллюстрация из кн.: Иоганн Бернхард Фишер фон Эрлах «Entwurff einer Historischen Architectur» («Проект исторической архитектуры»). Вена, 1721***

***Мәккәнең бер өлеше күренеше. Иллюстрация китаптан: Fischer von Erlach. Entwurf Einer Historischen Architektur. (Тарихи архитектура проекты). Vien, 1721***

делы полуострова и обрел широкое признание. После смерти Мухаммада в течение столетия огромные территории от Испании, Марокко и Мавритании на западе до Пакистана, Индии и Бангладеша на востоке, ограниченные на севере Средиземным, Чёрным, Каспийским и Аральским морями, а на юге – африканской Сахарой и морями Индийского океана, оказались соединены исламом в могущественном халифате в общее мусульманское культурное пространство.

В середине VII века началось проникновение ислама в Восточную Европу, на земли современной России. На Северном Кавказе главным противником Халифата оказался Хазарский каганат, который был многоэтничным, но состоял в основном из тюркоязычных и ираноязычных

пәйгамбәр, үзенә иңдерелгән илаһи вәхигә таянып, Гарәбстанның таркау кабиләләрен берләштерә алган. Бердәнбер Аллаһы Тәгаләнең бөеклеген игълан итүче Ислам дине, тиздән Гарәбстан ярымутравыннан читкә чыгып, башка төбәкләрдә дә киң таралыш ала.

Мөхәммәт пәйгамбәр вафатыннан соң йөз ел эчендә көнбатышта Испания, Марокко һәм Мавританиядән башлап, көнчыгышта Пакыстан, Һиндстан һәм Бангладешка кадәр сузылган, төньякта исә Урта, Кара, Каспий һәм Арал диңгезләре, көньякта Африка Сахарасы һәм Һинд океаны диңгезләре белән чикләнгән зур территорияләр һәм шул җирләрдә яши торган халыклар Ислам тарафыннан куәтле хәлифәлеккә берләшеп, уртак мөселман мәдәни киңлектә яши башлыйлар.

VII гасыр урталарында Ислам диненең Көнчыгыш Европага, хәзерге Россия җирләренә үтеп керүе башлана. Төньяк Кавказда халифәтнең төп көндәше – күпэтниклы Хәзәр каһанаты урнашкан, ләкин, күпкавемле

*Арабский халифат в 750 году н.э. Карта из «Исторического атласа» Уильяма Р. Шеперда. 1924*
*Гарәп хәлифәте 750 елда. Карта китаптан: Shepherd W.R. Historical Atlas. London, 1924*





*Мухаммад у Каабы Миниатюра рукописи ад-Дарира «Сийер-е Наби». 1595–1596*

*Мөхәммәд пәйгамбәр Кәгъбә янында. Әд-Дарирның «Сийер-е Нәби» кулъязмасыннан миниатюра. 1595–1596 © Топкапы сарае музее, Стамбул*




*Хазария и Хазарский каганат в VII–X веках. Художественное воспроизведение карты.*
*Авторы: И. Артамонов, А. Леухин, Ф. Валиуллин, Р. Шигабутдинов, И. Щетинин.*
*Музей Болгарской цивилизации*

*Хәзәр каһанлыгы VII–X гасырларда. Картаның сәнгатьчә күчермәсе.*
*Авторлар: И. Артамонов, А. Леушин, Ф. Вәлиуллин, Р. Шиһабетдинов, И. Щетинин*
*© Болгар цивилизациясе музее. Болгар*

*Кааба. Хадж*





*Кәгъбә. Хаҗ*

групп населения, среди которых доминировали болгарские и аланские племена. Арабо-хазарское противостояние продолжалось почти столетие. В 737 году полководцу и будущему халифу Марвану ибн Мухаммаду удалось заключить мирный договор с Хазарией. По условиям договора хазарский каган и его окружение приняли религию победителей.



*Музей Болгарской цивилизации. Вид со стороны Волги*
*Болгар цивилизациясе музее. Идел елгасы ягыннан күренеше*

булса да, әлеге дәүләт нигездә төрки һәм иран телле халык төркемнәреннән торган, алар арасында Болгар һәм Алан кабиләләре өстенлек иткән. Гарәп-Хәзәр сугышлары йөз елга якын дәвам итә. 737 елда полководец һәм булачак хәлифә Мәрван ибн Мөхәммәт Хәзәр дәүләте белән солых килешүе төзи. Шартнамә буенча, хәзәр каһаны, аның яраннары һәм кул астындагы халыклар, шул исәптән болгарларның бер өлеше дә җиңүчеләр динен кабул итәләр.



## 922 год в истории булгар: официальное принятие ислама

В 1956 году при археологических раскопках Неревского конца средневекового Новгорода был обнаружен клад куфических монет, в котором оказался крупный фрагмент дирхема с именем Джа'фара ибн-Абдаллаха. Сотруднице Государственного Исторического музея в Москве Светлане Яниной, активно занимавшейся в те годы восточной нумизматикой, удалось доказать, что Джа'фар ибн-Абдаллах – это мусульманское имя правителя Волжской Булгарии Алмуша, а сама монета чеканена в период правления аббасидского халифа ал-Муктафи (902–908), имя которого тоже указано на обратной стороне дирхема.

Ещё один интересный факт, который зафиксирован в седьмом томе большого энциклопедического труда «Ал-алак ан-нафиса» («Дорогие ценности»), написанного знаменитым арабским географом и историком ибн Русте в 903–913 годах. Он сообщает: *«Бóльшая часть их [булгар] исповедует ислам, и есть в селениях их мечети и начальные училища [мектебе] с муэдзинами и имамами <…> Одежда их похожа на мусульманскую; равным образом и кладбища их как у мусульман»*. Надо полагать, что сведения о булгарских мусульманах появились у ибн Русте не в период написания книги; они, скорее всего, отражают реалии более раннего времени – конца IX века.

Странно, что даже эти достоверные факты не смогли поколебать прочно утвердившееся в науке и ставшее хрестоматийным мнение о том, что население Волжской Булгарии приняло





*Волжские булгары в VIII–IX веках. Реконструкция по материалам Больше-Тарханского могильника. Рисунки О.Р. Гасимова*

*Идел болгарлары. VIII–IX гасырлар. Олы Тархан каберлеге материаллары буенча реконструкция. О.Р. Гасимов рәсеме*

## Болгар тарихында 922 нче ел: Ислам динен рәсми кабул итү

1956 елда Бөек Новгородның Нерев дип аталган бер өлешендә археологик казу эшләре алып барганда, Шәрык илләреннән китерелгән көмеш тәңкәләр хәзинәсе табыла. Хәзинәдәге тәңкәләр арасыннан бер ягына Җәгъфәр ибн Абдаллаһ исеме язылган дирһәм галимнәрнең игътибарын җәлеп итә. Ул елларда Көнчыгыш нумизматикасы белән актив шөгыльләнүче Мәскәү дәүләт тарих музее хезмәткәре Светлана Алексеевна Янина Җәгъфәр ибн Абдаллаһның Идел буе Болгары хакиме Алмыш ханның мөселманча исеме икәнен раслый, ә тәңкәнең исә дирһәмнең кире ягында күрсәтелгән Аббас хәлифәсе Әл-Муктафи (902–908) идарә иткән чорда сугылган булуын кире какмаслык дәлилләр белән исбатлый алды.



*Подражание дирхему. Серебро. Болгар, Алмуш-хан (?). Первая четверть X века. Русенихинский могильник (Нижегородская область). Раскопки Т.Б. Никитиной*

*Дирһәмгә охшатып эшләнгән тәңкә. Көмеш Болгар. Алмыш хан (?). Русинихино каберлеге (Түбән Новгород өлкәсе). Т.Б. Никитина казылмалары*

Тагын бер кызыклы факт. Ул 903–912 елларда танылган гарәп географы һәм тарихчысы Ибн Рөстә тарафыннан язылган «Әл-алак ән-Нәфисә» («Кадерле кыйммәтләр») дигән зур энциклопедик хезмәтнең җиденче томында теркәлгән. Ул болай дип хәбәр итә: *«Болгарларның күпчелеге Ислам динен тота, авылларында мәчетләре һәм имамнары-мөәзиннәре белән башлангыч мәктәпләр бар <...> Аларның киемнәре мөселманнарныкына охшаган, зиратлары да мөселманнарныкы кебек»*. Болгар мөселманнары турында мәгълүмат Ибн Рөстәнең китап язу чорында гына барлыкка килмәгәндер дип уйларга кирәк; бу мәгълүматлар, һичшиксез, IX гасыр азагы чынбарлыгын чагылдыра.

Шунысы гаҗәп, хәтта шушы фактлар да фәндә ныклап урнашкан һәм Идел буена килеп төпләнгән болгар халкы Ислам динен 922 елда гына, ягъни дин эшләре буенча һәм кайбер башка мәсьәләләрне хәл итү өчен махсус чакырылган Багдад илчелеге Болгар шәһәрендә булган көннәрдә генә Җәгъфәр ибн Абдаллаһ тарафыннан кабул ителгән дигән фикерне юкка чыгара алмады. Исламның болгарлар-



*Хазарская монета (т.н. «Монета Моисея»). Музей «Сокровища викингов», Висбю, Швеция*

*Хәзәр акчасы («Моисей тәңкәсе») © Викинглар хәзинәсе музее. Висбю, Швеция*



*Шигабутдин Марджани*
*Фотография конца XIX века*
*Шиһабетдин Мәрҗани*
*XIX гасыр ахырында төшерелгән фотография*

ислам в 922 году, в дни пребывания в городе Болгаре Багдадского посольства, специально приглашённого Джа'фаром ибн Абдаллахом для решения вопросов по делу веры. Факты более раннего проникновения ислама в большинстве случаев игнорировались.

Между тем, ещё в 80-х годах XIX века выдающийся учёный-богослов и историк Шигабутдин Марджани склонен был признать началом исламизации булгар не времена Алмуша / Джа'фара ибн-Абдаллаха, а время правления аббасидских халифов ал-Ма'муна (813–833) и ал-Васика (842–847), то есть первую половину IX века. К такому же мнению позднее пришёл известный советский археолог профессор Альфред Халиков, указавший на существовавшие при халифе Ма'муне тесные военно-политические и торгово-экономические связи между Хазарским каганатом и Средней Азией.



*Аббасидский халиф ал-Ма'мун отправляет посланника византийскому императору Феофилу. Миниатюра XIII века*

*Габбасилар хәлифәсе әл-Мә'мүн үзенең илчесен Византия императоры Феофил янына озата. XIII гасыр миниатюрасы. © Испания Милли китапханәсе, Мадрид*



га бик иртә үтеп керү фактларына игътибар итмәделәр.

Шул ук вакытта, XIX гасырның 80нче елларында ук танылган дин галиме һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани болгарларның Алмыш хан – Җәгъфәр ибн Абдаллаһ заманнында гына түгел, ә Габбаси хәлифәләре Әл-Мә’мүн (813–833) һәм Әл-Васыйк (842–847) идарәсе чорында, ягъни IX гасырның беренче яртысында ук Ислам динен

*Коллективный намаз в Самарканде. Фотография начала XX века*

*Сәмәркандтә күмәк намаз. XX гасыр башы фотографиясе*



*Общий вид Бухары. Фотография начала XX века*

*Бохараның гомуми күренеше. XX гасыр башы фотографиясе*

кабул итә башлаулары хакында язып чыкты. Шушы ук фикерне соңыннан, әле Советлар хакимияте чорында ук, күренекле археолог һәм тарихчы профессор Альфред Халиков та яклады. Ул үзенең хезмәтләрендә хәлифә Мә’мүн заманында Хәзәр каһанлыгы белән инде VIII гасырда ук мөселманлашкан Урта Азия арасында тыгыз хәрби-сәяси һәм сәүдә-икътисади элемтәләр урнашкан булуына басым ясады. Хәзәр дәүләтендә яшәгән болгарларга Ислам дине нәкъ менә Урта Азиядән, төгәлрәге Хәрәзем өлкәсеннән, күп санлы угыз мөселман төркемнәре белән бергә үтеп кергән булырга тиеш, дип фаразлады күренекле галим.



Каһанлык халкының шактый өлеше чыннан да Ислам динен тоткан дигән фикерне Дон елгасы бассейнында ачылган IX гасыр мөселман зиратларын казып тикшергән археологлар да раслый. Хәзерге вакытта Хәзәр каһанлыгы терри-

*Средняя Азия в начале IX – X веков*

*Урта Азия IX гасыр башы – X гасырда*



*Альфред Хасанович Халиков (1929–1994)*

*Альфред Хәсән улы Халиков (1929–1994)*

*Крышка с пестиковидной ручкой и лепной горшок из раскопок Билярского городища. X–XI века (по А.Х. Халикову)*

*Кулдан әвәләп ясалган чүлмәк; капкачының тоткасы киле сабы рәвешле. Биләр казылмаларыннан. (А.Х. Халиков буенча)*



Именно Средняя Азия, точнее, область Хорезма, являлась тогда ближайшим очагом мусульманства, откуда новая религия могла проникнуть вместе с многочисленными группами мусульманами-огузами и на земли Хазарии.

Мнение о том, что значительная часть булгарского населения каганата действительно исповедовала ислам, подтвердили новые исследования археологов, открывших мусульманские кладбища начала IX века на Дону. В настоящее время наука располагает данными около десятка крупных мусульманских могильников на территории каганата, преимущественно в Приазовье, т. е. там, где исследователи локализуют булгар, переселившиеся позднее на Среднюю Волгу. В Хазарии было много мусульманских купцов, воинов, представителей других



*Раннемусульманский могильник у с. Сидорово на р. Северский Донец (по Э.Е. Кравченко ). Раскопки древнего города Итиль, Хазарский каганат*

*Северский Донец елгасы буендагы Сидоровка авылы. янында әлгәреге мөселман зираты. IX гасыр. (Э.Е. Кравченко буенча)*



*И.К. Ахмадеев. Айдар-хан. Из цикла «Ветры древних Булгар». 2003. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*И.К. Әхмәдиев. Легендар Айдар хан. «Борынгы Болгар җилләре» циклыннан. 2003 © Болгар цивилизациясе музее. Болгар*

ториясендә, нигездә Азов буйларында, ягъни, соңрак Урта Иделгә күчеп утырган болгарлар тупланган урыннарда, дистәгә якын мөселман каберлекләре турында мәгълүматлар бар. Хәзәр илендә мөселман сәүдәгәрләре, сугышчылары, һөнәрчеләре, Урта Азиянең төрле төбәкләреннән килгән башка төркем вәкилләре күп була. Аларның археологик эзләре Урта Азия шәһәрләрендә сугылган тәңкәләр, тандыр тибындагы мичләре булган торак урыннар, керамик эшләнмәләр, башка әйберләр рәвешендә сакланып калганнар. Шундый ук әйберләр X гасырның беренче яртысында Идел болгарлары яшәгән шәһәр-авыл урыннарын казыганда да табылып тора.

X гасырда яшәгән гарәп географы Әбү-л Касыйм Мөхәммәт ибн Хәүкәл сүзләренчә, Хәзәр иленең башкаласы Итилдә утызга якын мәхәллә мәчете эшләп торган, мәчет каршында балаларны Коръән укырга өйрәтү өчен мәктәпләр ачылган. Шәһәрнең үзәк мәйданында биек манаралы Җәмигъ мәчете урнашкан.

Археологлар тарафыннан расланган тагын бер фактны исәпкә алырга кирәк: Идел буе Болгарына хәлифә Мөкътәдир илче-



*Туйбике. Рисунок Н. Максимовой. 2004*

*Н. Максимова. Патша кызы Туйбикә. 2004*

категорий населения из разных областей Средней Азии. Археологические следы их фиксируются в виде монет, чеканенных в среднеазиатских городах, жилищ с печами-тандырами, глиняных крышек с высокими пестикообразными ручками, другими восточными предметами, которые потом, в первой половине X века, появляются и на булгарских поселениях Среднего Поволжья.

О широком распространении ислама в Хазарском каганате, правители и часть населения которого исповедовали иудаизм, сообщают и письменные источники. По словам современника, арабского географа Абу-л-Касим Мухаммад ибн-Хаукаля, в столице Хазарии Итиле: было около 30 квартальных мечетей с мектебами для обучения детей Корану; на центральной площади стояла Соборная мечеть с высоким минаретом, который превосходил даже дворец кагана.

Надо учитывать, однако, и установленный археологами факт, что ещё задолго до приезда в Волжскую Булгарию посольства халифа Муктадира среднеазиатские купцы торговали на местных рынках, с ними приезжали и ремесленники, и проповедники ислама. В конечном итоге это привело к тому, что Булгария в культурном отношении начала превращаться «в настоящую колонию Востока», о чем с некоторым преувеличением, но, по сути, правильно отметил в своё время академик Ю.В. Готье.

* * *

Говоря о путях и времени распространения ислама среди булгар, нельзя обойти молчанием интересную гипотезу, согласно которой начало распространения ислама в России произошло ещё при жизни пророка Мухаммада и его асхабов (сахабов) – преданных ему сподвижников. Авторы этой гипотезы ссылаются в качестве доказательства на сочинение турецкого писателя XVI–XVII вв. Чокрыкчызаде. В его книге содержится рассказ об обращении в истинную религию Фаруха ибн Гамру Хизами – некоего правителя приазовских булгар до эпохи, предшествавшей образованию Великой Болгарии хана Кубрата. Это случилось якобы в 629 г.1

Весьма любопытно, что легендарный сюжет, приписывающий начало ислама в Волжской Булгарии асхабам пророка, часто встречается и в фольклорном творчестве татар. Как утверждается в старинной татарской рукописи, пересказанной в XIX в. ректором Казанского университета, ученым и врачом, почетным гражданином г. Казани, немцем по происхождению Карлом Фуксом, начало этому было положено в 9 году хиджры, когда Пророк Мухаммед стал рассылать своих сахабов (сподвижников) к народам и государствам мира для распространения ислама. Три таких сахаба Пророка, имамы Габдрахман (Абдур-Рахман) ибн-Зубайра, Талха ибн-Гусман, Зубайра ибн-Талка (Джагда), прибыли с мис-

[1] Давлетшин Г. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа. Казань, 2001. С. 169 и сл.

леге килгәнче үк, Урта Азия сәүдәгәрләре Болгар базарларында сәүдә иткән, алар белән һөнәрчеләр дә, Ислам дине дәгъватчылары да килгән. Нәтиҗәдә, Болгар дәүләте мәдәни яктан, академик Ю.В. Готье язганча (әлбәттә, бераз арттырып, әмма асылда дөрес), «Шәрыкның чын колониясенә» әверелә башлый. Бу исә болгарларның Ислам диненә күчү процессын җиңеләйтә генә.

* * *

Болгарлар арасында Ислам диненең таралу юллары һәм вакыты турында сөйләгәндә, бер кызыклы фаразны да читләтеп үтү мөмкин түгел. Бу фаразны алга сөрүчеләр Россия җирлегендә Ислам дине Мөхәммәт пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре чорында, ягъни VII гасыр урталарында тарала башлый, дип тәкърарлыйлар. Әлеге караш яклылар XVI–XVII гасырларда яшәгән төрек язучысы Чокрыкчызадәнең бер китабына таяналар. Аның китабында Кубрат хан чорына кадәр, әле Бөек Болгар иле оешканчы ук, Азов буе болгарларының Фәрух ибн Гамру Хизами исемле бер хакименең хак динне, ягъни Исламны кабул итүе турында хикәят бар. Әлеге вакыйга 629 елга карый, имеш.

Идел буе Болгарында Ислам динен кабул итүне Пәйгамбәребез сәхабәләре белән бәйләүче сюжет татарларның фольклор иҗатында да очрый. XIX гасырда Казан университеты ректоры, галим һәм табиб, Казанның мөхтәрәм гражданины, чыгышы белән алманлы Карл Фукс тарафыннан бәян ителгән борынгы татар кулъязмасын искә алсак, бу һиҗрәнең 9 нчы елында Мөхәммәт пәйгамбәрнең үзенең сәхабәләрен төрле халыкларга һәм дәүләтләргә Ислам динен тарату өчен җибәрүе һәм шуңа нисбәтле төрле төбәкләргә яңа дин үтеп керә башлавы хәбәр ителә. Пәйгамбәрнең өч сәхабәсе – Зөбәир ибн Талкә, Зөбәир ибн Җаһда һәм Габдрахман болгарларга дәгъват миссиясе (Ислам диненә чакыру) белән килгәннәр. Ерак якларга китәр алдыннан, пәйгамбәр аларга, башыннан салып, үзенең чалмасын, таягын һәм кара савытын тапшыра. Риватьләрдә әйтелгәнчә, әлеге сәхабәләр Айдар ханның Ислам динен кабул итүендә хәлиткеч роль уйнаганнар. Болгарда пәйгамбәрнең сәхабәсе һәм 33 «табигъыйн» (сәхабәләр аша Ислам динен кабул иткән кешеләр) каберләрен ихтирам итү дә шушы вакыйга белән бәйле.

Ул вакытта Айдар ханның Туйбикә исемле егерме яшьлек кызы озак вакытлар инде беркем дә дәвалый алмый торган начар авырудан интеккән. Сәхабәләр, ханга ярдәм итәргә теләп, кызны авыруыннан ничек коткарырга кирәклеген беләбез, дип мөрәҗәгать итәләр. Ханның ризалыгын алгач, алар Мөхәммәт бүләк иткән таякларын җиргә кадап куялар. Габдрахман дога кылганнан соң, бу урында су пәйда була, ә аннары күз алдында ук каен агачы үсеп чыга. Каен ботакларыннан себерке җыялар, һәм бу себерке белән авыру кызны мунчага алып барып чабалар. Тиздән Туйбикә тулысынча терелеп бетә. Могҗиза өчен рәхмәт йөзеннән



*Памятник сахабам в Болгаре. На стеле изображены легендарные чалма, посох и чернильница*

*Болгарда сәхабәләргә Истәлек ташы. Стела өслегенә чалма, юл таягы һәм кара савыты рәсеме төшерелгән*

сией дагвата (призыва к исламу) к болгарам. Перед отправкой в далёкие края пророк якобы вручил им чалму, сняв её со своей головы, а также посох и чернильницу. Эти сахабы по преданию сыграли решающую роль в принятии ислама Айдар-ханом. С этим же событием увязывают почитание в Болгаре могил сподвижника пророка и 33-х «табигинов» (людей, принявших ислам через сподвижников).

В то время, говорится в повествовании, дочь Айдар-хана, двадцатилетняя красавица Туйбике, страдала от тяжёлой болезни, которую никто не мог вылечить. Сахабы сказали хану, что они знают средство, как избавить девушку от болезни. Получив согласие хана, они воткнули в землю посох, подаренный Мухаммадом. Сразу после того, как Габдрахман прочёл молитву, на этом месте появилась вода, а затем прямо на глазах выросла берёза. Из веток берёзы собрали веник, и этим веником служанки попарили больную девушку в бане. Вскоре Туйбике исцелилась полностью. В благодарность за чудо Айдар-хан выдал свою дочь замуж за одного из сахабов пророка – Зубаира ибн-Талке, наизусть знавшего Коран. Они прожили вместе двадцать пять счастливых лет. Зубаир ибн-Талк после смерти был похоронен на кладбище у Малого минарета в городе Болгаре. На территории современного городища и сейчас имеется источник, связанный с именем Габдрахмана. У Малого минарета растет береза, символизируя духовную преемственность поколений.

Сюжет об исцелении есть и в средневековом трактате XII века ал-Гарнати. Он описывает предание о враче (факихе), который вылечил булгарского правителя и его жену, что послужило причиной принятия ислама булгарами. Это событие стало поводом для военного конфликта хазар с булгарами, правитель которых в гневе направил войска. Данное свидетельство указывает, что время принятия ислама было до гибели Хазарского каганата.

Эта история о начале распространения ислама среди булгар сахабами имеет легендарный характер и не подтверждается достоверными источниками. Все известные могильники населения Великой Булгарии (630–660-е) – языческие, в том числе и те, которые считаются оставленны-




*Р.И. Шәмсутов. Ибн Фадлан юлы. 1993*
*Р.И. Шамсутов. Карта пути ибн Фадлана. 1993*

Айдар хан үз кызын пәйгамбәребезнең бер сәхабәсенә – Коръәнне яттан белүче Зөбәир ибн Талкәгә кияүгә бирә. Алар егерме биш ел бергә яшиләр. Вафатыннан соң, Зөбәер ибн Талкә Болгар шәһәрендәге Кече манара янында барлыкка килгән Изгеләр зиратына җирләнә. Шәһәрлектә хәзер дә Габдрахман исеме белән бәйле чишмә (кое) һәм Кече манара янында каен утыртылган урын бар.

Күргәнебезчә, Болгар илендә Ислам дине таралу Пәйгамбәребез Мөхәммәт заманында ук башлана дигән фикер риваять-легендаларга гына таяна һәм объектив чыганаклар белән расланмый. 630–660 нчы еллар тирәсендә, ягъни Кубрат хан идарә иткән чорда, Бөек Болгар дәүләтенең халкы Ислам диненен тотмаган. Алардан соң калган зиратларда бары тик мәҗүси йолалар буенча күмелгән кеше сөякләре генә табыла. VII гасырның 60 нчы елларында, Кубрат хан дәүләте таркалганнан соң, Урта Иделгә күчеп килүчеләрнең беренче дулкыны булып саналган болгарлар да үлгән кешеләрне мәҗүсиләр йоласы буенча күмгәннәр. Ләкин әле бу, болгар халкы Ислам дине белән бөтенләй дә таныш булмаган, дигән сүз түгел. 922 елгы тарихи вакыйгалардан соң, элгәрегә күчеш ясап, Болгардагы Ислам тарихының Мөхәммәт пәйгамбәрнең үзе катнашында башлануын тасвир кылып, ул яшәгән чор белән бәйләргә омтылыш барлыкка килә. Бу омтылыш-теләк

ми первой волной переселенцев на Среднюю Волгу после распада государства Кубрата в 60-х годах VII века.

* * *

Ключевое событие в истории исламизации булгар произошло во время правления Алмуша с мусульманским именем Джа'фар ибн Абдаллах, булгарского эмира, носящего одновременно древнетюркский титул эльтебер в значении верховного правителя, владетеля страны.

Весной 921 года в Багдад прибыло посольство под руководством Абдаллаха ибн Башту, отправленное из далёкой Булгарии её правителем Джа'фаром ибн-Абдаллахом. В письме аббасидскому халифу ал-Муктадиру, переданном ему булгарским послом, Джа'фар ибн-Абдаллах просил *«о присылке к нему кого-либо, кто наставил бы его в вере, преподал бы ему законы ислама, построил бы для него мечеть и крепость, воздвиг бы для него кафедру, чтобы он установил от его [халифа] имени хутбу в его стране и во всех областях его государства, и просил его о постройке крепости, чтобы укрепиться в ней от царей, своих противников. И было дано согласие на то, о чём он просил»*.

21 июня 921 года из Багдада в Булгарию выехал большой караван – посольство во главе с послом халифа Сусаном ал-Расси и его секретарём Ахмадом ибн Фадланом. Его путь лежал через Хамадан, Рей, Нишапур, Мерв и Бухару до Хорезма. С трудом караван шёл по полупустынному плато Устюрт и вышел к реке Джаек (Урал). Преодолев огромные расстояния, через земли кочевых тюрков, путники приближались к Волге. Далее предоставим слово самому ибн Фадлану:

*«Когда же мы были от царя булгар, к которому мы направлялись, на расстоянии дня и ночи пути, он послал для нашей встречи четырёх царей, находящихся под его властью, своих братьев и своих сыновей. Они встретили нас, неся с собой хлеб, мясо, просо, и поехали вместе с нами. Когда же мы были от него на расстоянии двух фарсахов*[2]*, он встретил нас сам, и когда он увидел нас, он сошёл с лошади и пал ниц, поклоняясь с благодарением Аллаху, великому и могучему. В рукаве у него были дирхемы, и он рассыпал их на нас. Он поставил для нас юрты, и мы поселились в них. Наше прибытие к нему было в воскресенье, когда прошло двенадцать ночей месяца мухаррама триста десятого года»* (18 мая 922 года по современному григорианскому календарю).

Анализ маршрута Багдадского посольства безошибочно указывает на место, где происходили торжества, состоявшиеся 21 мая 922 года. Оно располагалось на расстоянии одного фарсаха от Итиля, как это отмечено в «Записках» ибн Фадлана, скорее всего, в ставке булгарского правителя в районе современного Болгара – небольшого тогда поселения.

[2] 1 фарсах равняется примерно 6–7 км.

болгарларның Ислам дине белән Урта Иделгә күчкәнче үк таныш булуларына ишарә, күрәсең.

* * *

Болгарларның Ислам динен кабул итү тарихында төп вакыйгаларның берсе, һичшиксез, бүген гади халык арасында Алмыш исеме белән танылган, чынлыкта исә 922 елга кадәр кимендә ике дистә ел элек үзенә Җәгъфәр ибн Абдаллаһ (Габдулла) исеме алган Болгар ханы белән бәйле. Заманында аның титулы борынгы төркиләрдәгечә *эльтебер/илтабар/йылтывар* (ил башлыгы, юлбашчы мәгънәсендә) дип йөртелгән, соңрак, Ислам динен кабул иткәч, *әмир* дип атала башлаган.

921 елның язында Багдадка Абдаллаһ ибн Башту җитәкчелегендәге илчелек килә. Илчелекнең ерак Болгарга килүенә төп сәбәпче – Болгар ханы Җәгъфәр ибн Абдаллаһ тарафыннан язылган хат була. Илче тарафыннан Габбасилар хәлифәсе Әл-Мөктәдиргә тапшырылган хатында Җәгъфәр ибн Абдаллаһ аннан «*дингә өйрәтүче, Ислам диненең кануннарын аңлатучы, аның өчен мәчет төзеп бирүче, аның (хәлифәнең) Ислам диненә өндәвен үзенең шәһәрендә һәм үзенең бөтен дәүләтендә халыкка җиткерү өчен аңа, Болгар патшасына, мөнбәр торгызучы кешеләр җибәрүен сораган һәм ул, Болгар патшасы, дошман патшалардан анда торып саклансын өчен, хәлифәдән кальга (крепость) салуын үтенгән... Хат килгәч, аңа, Болгар патшасына, аннан, хәлифәдән, нәрсә сораган булса, шуңа ризалык бирелде*».

921 елның 21 июнендә Багдадтан Болгар иленә хәлифә илчесе Сусан Әр-Расси һәм аның сәркатибе Әхмәт ибн Фадлан җитәкчелегендә зур караван-илчелек китә. Юл Хамадан, Рей, Нишапур, Мәрв һәм Бохара аша Хәрәземгә кадәр дәвам итә. Аннан соң кәрван зур кыенлык белән ярымчүлле Устюрт калкулыгы буйлап бара һәм Җаек (Урал) елгасына чыга. Ерак араларны үтеп, күчмә төрки халыклар биләп торган җирләр аша юлчылар Иделгә якынлаша. Сүзне Ибн Фадланга бирәбез:

*«Без болгарлар патшасыннан, ә ул – без бара торган кеше, бер көн һәм бер төн ара ераклыгында булганда, безне каршылау өчен үзенә буйсынган дүрт патшаны, ир туганнарын һәм улларын җибәргән иде. Алар безне каршыладылар, аларның ипиләре, итләре һәм тарылары бар иде, һәм алар безнең белән бергә кузгалып киттеләр. Һәм без болгарлар патшасыннан ике фәрсах ара ераклыгында булганда, ул безне үзе каршылады. Безне күргәч, атыннан төште, бөек һәм кодрәтле Аллаһыга табынып, рәхмәтләрен белдереп, йөзтүбән егылды. Аның җиң эчендә дирһәмнәр бар иде, һәм ул аларны безгә сипте. Ул безнең өчен чатырлар кордырды һәм безне аларда урнаштырды. Безнең аның янына килеп җитүебез – өч йөз унынчы ел мөхәррәм аеның уникенче төне үткәч, якшәмбе көнне булды»*. (Бу дата хәзерге календарь буенча 922 елның 18 маена туры килә).

Багдад илчелеге маршрутын һәм Ибн Фадлан язмаларын җентекләп



*Средневековый Багдад. Мечеть аль-Казимийя — шиитская святыня, расположенная в районе Багдада Кадимия[en]. Также называется «Золотая мечеть». Была построена в XVI веке. В ней находятся могилы седьмого имама шиитов Мусы аль-Казима и девятого имама шиитов Мохаммеда ат-Таки. Также в этой мечети похоронены богослов и историк Мохаммед аль-Муфид и полимат Насир ад-Дин Туси*

*Урта гасыр чорындагы Багдад. Әл-Казыймия мәчете – шыгыйларның Кадимия мәхәлләсендә урнашкан изге урыны, аны «Алтын мәчет» дип тә атыйлар. XVI гасырда төзелгән. Бу мәчеттә шыгыйларның җиденче имамы Муса әл-Казыйм һәм тугызынчы имамы Мөхәммәд әт-Такиның каберләре бар. Шунда ук күренекле дин белгече һәм тарихчы Мөхәммәд әл-Мөфид һәм полимат Насыйр әд-Дин Туси каберләре*

Послы *«оставались воскресенье, понедельник, вторник и среду в юртах, <...> пока собрались цари его земли, предводители и жители страны»*, а в четверг состоялась церемонии чтения письма халифа и вручения подарков. О состояшихся торжествах лучше нас расскажет секретарь посольства:

*«Все собрались, и мы развернули два знамени, которые были с нами, оседлали лошадь с седлом, присланным ему [в подарок], одели его, правителя булгар, в савад и надели на него тюрбан. Тогда я вынул письмо халифа и сказал ему: «Не подобает, чтобы мы сидели, когда читается это письмо». И он встал на ноги, – он сам и присутствовавшие знатные лица из жителей его государства, а он человек очень толстый и пузатый. Я начал и прочитал начало письма и, когда я дошёл до слов: «Мир тебе, и воистину я прославляю, [обращаясь] к тебе, Аллаха, кроме которого нет иного бога», – я сказал ему: «Ответь пожеланием мира повелителю правоверных». И он ответил, и они ответили все вместе.*

*Переводчик не переставал переводить [наше чтение] буква в букву. Когда же мы кончили его чтение, то они возгласили «Велик Аллах!» таким возгласом, от которого затряслась земля. Потом я прочитал письмо везира Хамида ибн ал-‘Аббаса, в то время как он стоял. Потом я пригласил его сесть, и во время чтения письма Назира ал-Харами он сидел. Когда же я окончил его [чтение], спутники его рассыпали на него многочисленные дирхемы. Потом я вынул подарки, [состоявшие] из благовоний, одежд, жемчуга, для него и для его жены, и я не переставал представлять ему и ей одну вещь за другой, пока мы не покончили с этим. Потом я облёк его жену [в почётный халат] в присутствии людей, в то время как она*



*Р. Шамсутдинов. Переправа посольства Ибн Фадлана через реку. 1999*

*Р.Г. Шәмсетдинов. Ибн Фадлан илчелеге Җаек елгасын кичә*

өйрәнү 922 елның 21 маенда узган тантаналарның кайда узуын ачык күрсәтә. Ул Итилдән бер фәрсах (6 чакрым) ераклыгында урнашкан Болгар дәүләте хакиме ставкасында, хәзерге Болгар җирлегендә – ул вакытта зур булмаган торак пунктта үтә.

Багдадтан килгән илчеләр якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе һәм чәршәмбе көннәрендә үзләренең чатырларында калалар, илнең башка төбәкләреннән бәкләр, олы бәйрәмгә чакырулы затлар килеп җиткәнче ял итәләр. Пәнҗешәмбе көнне барысы да Багдад хәлифәсенең хатын уку һәм бүләкләр тапшыру тантанасына җыелалар. Тантаналар турында бездән яхшырак итеп илчелек сәркатибе Әхмәт ибн Фадлан сөйләячәк:

*«Пәнҗешәмбе килеп җиткәч һәм халык җыелгач, без үзебез белән алган ике чигелгән байракны җәеп җибәрдек, Болгар патшасына җибәрелгән ияр белән атны иярләдек, Болгар патшасын кара киемнәргә киендердек һәм башына чалма кидердек. Мин хәлифәнең хатын чыгардым һәм аңа: «Хат укыганда утырып тору рөхсәт ителми», – дидем. Һәм ул аякларына торып басты, үз дәүләтенең шунда булган күренекле кешеләре дә торып бастылар. Мин укый башладым һәм хатның башын укыдым, һәм «Сиңа тынычлык булсын! Һәм чыннан да, мин сиңа мөрәҗәгать итеп, Аллаһыны данлыйм, Аннан башка бүтән бөек көч юк», дигән сүзләргә җиткәч, мин: «Мөселманнарның хөкемдарына тынычлык теләп җавап бир!» – дидем. Һәм ул җавап бирде, һәм шунда булган кешеләр дә барысы бергәләп җавап бирделәр.*

*Безнең укыганны хәрефен хәрефкә тәрҗемә итүдә тәрҗемәче дә ялгышмады. Һәм без хатны укып бетергәч, алар «Аллаһу әкбәр!» сүзен әйттеләр. Җир яңгырап торды.*

*Аннан соң мин вәзир Хәмид ибн Әл-Габбасның хатын укыдым, һәм Болгар патшасы бу вакытта басып торды. Аннан соң мин аңа утырырга куштым, һәм ул Нәзир Әл-Хәрәминең хатын укыганда утырып торды. Һәм мин хат укуны тәмамлагач, Болгар патшасының иярченнәре аңа бик күп дирһәмнәр чәчтеләр. Аннан соң мин хуш исле нәрсәләрдән, аның өчен һәм аның хатыны өчен булган киемнәрдән, энҗеләрдән торган бүләкләрне чыгардым... Аннан соң мин аның хатынын кешеләр барында бүләкләдем, ә ул аның (Болгар*



*Муэдзин в Багдаде.*
*Фотография начала XX века*
*Багдад мәэзине. XX гасыр фотосы*

*сидела рядом с ним, – таков их закон и обычай. Когда же я облёк её [в почётный халат], женщины рассыпали на неё дирхемы, и мы удалились».*

Вечером состоялся торжественный ужин в честь почётных гостей из Багдада. На этом закончилась важнейшая часть программы посольства багдадского халифа – узаконивание ислама в качестве официальной религии в Булгарии. Она стала самой северной страной средневековой исламской цивилизации.

Некоторое время ушло на ознакомление членов делегации со страной и её природой, образом жизни булгар, их занятиями, обычаями, верованиями, системой налогообложения, правилами наследования и т. д. В своих «Рисале» («Записках»), составленных по возвращении в Багдад, ибн Фадлан не преминул упомянуть единственный случай приобщения членов одной семьи к исламу, а также посещение им племени баранджаров в количестве пяти тысяч душ, имевших к тому времени деревянную мечеть, в которой те молились.

Секретарь посольства и его спутники находили время и на разъяснение муэдзинам и имамам некоторых положений ислама, спорных моментов, возникающих при чтении Корана и совершения намаза в летнее время. Так, ибн Фадлан описывает в своей книге разговор, происшедший между ним и булгарским эмиром по поводу того, как муэдзин, призывая к молитве, произносил икаму дважды, согласно среднеазиатскому ханафитскому мазхабу, а не один раз, как это принято у багдадских шафиитов («право же, господин твой, повелитель правоверных, у себя провозглашает икаму один раз»), в то время как в Багдаде утвердились мазхабы аш-Шафии и Ханбаля. Вопрос остался открытым. Не был разрешён и вопрос о количестве намазов в лет-




*Путь посольства ибн Фадлана на Волгу в 921–922 годах*

*Ибн Фадлан илчелегенең 921–922 елларда Болгарга килү юлы*

*патшасы) белән янәшә утыра иде. Һәм бу – аларның йоласы. Һәм мин аны бүләкләгәндә хатын-кызлар аңа дирһәмнәр чәчтеләр».*

Кич белән Багдадтан килгән мәртәбәле кунаклар хөрмәтенә тантаналы мәҗлес үткәрелә. Шулай итеп, Багдад хәлифәсе илчелеге программасының мөһим өлеше – Болгар дәүләтендә рәсми дин буларак Исламны канунлаштыру тәмамлана. Болгар иле урта гасыр Ислам цивилизациясенең иң төньякта урнашкан өлкәсе булып таныла.

Күпмедер вакыт делегация әгъзаларын ил һәм аның табигате белән таныштыруга, болгарларның яшәү рәвешен, аларның шөгыльләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен, салым салу системасын, мирас кагыйдәләрен өйрәнүгә китә. Шунысы игътибарга



*Л.А. Фаттахов. Ахмад ибн Фадлан с посланием к царю Альмушу. 1971. Болгарский историко-архитектурный музей-заповедник*

*Л.Ә. Фәттахов. Әхмәд ибн-Фадлан Алмыш ханга Багдад хәлифәсенең хатын укый. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы. Болгар*



*Лист из Мешхедской рукописи, в составе которой сохранился текст «Записок» ибн Фадлана. Мешхедская рукопись, содержащая сочинения Ибн-аль-Факиха, Абу-Дулафа и ибн Фадлана, хранится в библиотеке при гробнице имама Али ибн Риза в городе Мешхеде в Иране*

*Ибн Фадлан «Рисалә»се текстлары сакланган Мәшһәд кулъязмасының бер бите.*
*Ибн әл-Факих, Әбү-Дулаф һәм Ибн Фадлан әсәрләрен туплаган әлеге кулъязма Иранның Мәшһәд шәһәрендә, имам Али ибн-Риза төрбәсе каршындагы китапханәдә саклана*

ний сезон, когда ночь коротка, что позволяет, как считали булгарские мусульмане, объединить последний ночной и ранний утренний намазы. Любопытно, что булгары и их потомки, поволжские татары, долгое время совершали намаз четыре раза в день. Обязательный характер пятикратных молитв, ставший предметом оживлённых богословских дискуссий, был восстановлен практически только в XVIII веке.

* * *

Прошёл почти месяц пребывания багдадского посольства в Болгаре. Оставалось выполнить другую, не менее важную часть программы посольства, включённую по просьбе булгарского правителя, – о постройке крепости, «которая защитила бы его от иудеев, поработивших страну». Как известно, Булгария в это время находилась в зависимости от Хазарского каганата и платила ему дань мехами, зерном и драгоценностями. Сын булгарского эмира жил в Итиле в качестве заложника. Узнав о



А. П. Ковалевский

доктор исторических наук, профессор

КНИГА
АХМЕДА
ИБН-ФАДЛАНА
О ЕГО ПУТЕШЕСТВИИ
НА ВОЛГУ
В 921-922 гг.

Статьи, переводы и комментарии

ИЗДАТЕЛЬСТВО
ХАРЬКОВСКОГО ОРДЕНА ТРУДОВОГО КРАСНОГО ЗНАМЕНИ ГОСУДАРСТВЕННОГО УНИВЕРСИТЕТА имени А. М. ГОРЬКОГО
Харьков 1956

*Титульный лист издания А.П. Ковалевского «Книга Ахмеда ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. (Статьи, переводы, комментарии). Харьков: Изд. Харьковского госуниверситета им. Горького, 1956*

*Әхмәд Ибн-Фадланның 921–922 елларда Иделгә сәяхәте турында китап. Мәкаләләр, тәрҗемәләр, комментарийлар А.П. Ковалевскийныкы. Харьков, 1956 (Титул бите)*

лаек: Багдадка әйләнеп кайткач язылган «Рисалә»сендә Ибн Фадлан үзенең бары тик бер гаиләне генә Ислам диненә күндерүе турында хәбәр итә. Биш мең кешедән торган бәрәнҗәрләр кабиләсенә караган кешеләрнең барысы да күптән инде мөселманлыкка күчеп беткән булалар. Аларның агач бүрәнәләрдән салынган мәчетен гарәп илчесе үз күзләре белән күрә.



*Хан Алмыш. Первая четверть X в. Репродукция с картины художника Ф. Халикова (Фиринат Халиков, с. 27)*

*Ф.Г. Халиков. Алмыш-хан. X гасырның беренче чирегe*

Илчелек сәркатибе һәм аның иярченнәре мөәзиннәргә һәм имамнарга Исламның кайбер нигезләмәләре, Коръән укуда һәм җәй көне намазда килеп чыккан бәхәсле мизгелләргә аңлатма бирергә дә вакыт таба. Ибн Фадлан үзенең китабында Болгар ханы белән үзенең арасында килеп чыккан бер сөйләшү турында яза. Эш шунда ки, мөәзин мәчет манарасыннан намазга чакырып әйтелә торган сүзләрне, камәтне, Багдад шафигыйлары кебек бер мәртәбә генә түгел, Урта Азиядә кабул ителгән хәнәфиләр мәзһәбе таләпләренә туры китереп, ике мәртәбә әйтә. Бәхәсләр булып ала, әмма сорау җавапсыз кала. Дөресрәге, болгарлар камәтне үзләренчә әйтүдән баш тартмыйлар. Җәйге сезонда намазларның саны турындагы мәсьәлә дә хәл ителмәгән килеш кала, бу исә, Болгар мөселманнары фикеренчә, соңгы төнге һәм иртәнге намазларны берләштерергә мөмкинлек бирә. Шунысы кызык, болгарлар һәм аларның варислары, Идел буе татарлары озак вакытлар намазны көнгә дүрт тапкыр укыганнар. Биш тапкыр намазларның мәҗбүрилеге XVIII гасырда гына торгызыла.

* * *

Багдад илчелегенең Болгар иленә килүләренә бер ай чамасы вакыт үтеп тә киткән. Җәгъфәр ибн Абдаллаһның Багдад хәлифәсенә үтенеч булarak язылган һәм хәлифә тарафыннан ярдәм итәргә вәгъдә бирелгән тагын бер бик мөһим мәсьәләне хәл итәсе кала. Ул да булса, Болгар илен яһүдиләрдән, ягъни Хәзәр патшасыннан саклау өчен хәрби ныгытма (крепость) һәм мәчет төзү белән бәйле эшләр. Билгеле булганча, бу вакытта болгарлар Хәзәр каһанлыгының вас-



*И.М. Самакаев. Церемония вручения письма багдадского халифа эльтеберу Алмушу*
*И.М. Самакаев. Багдад хәлифәсенең хатын илтабар Алмышка тапшыру тантанасы*

красоте дочерей-красавиц правителя булгар, хакан потребовал их в свой гарем и, услышав отказ, отобрал силой. Поэтому можно понять стремление Джа'фара ибн Абдаллаха освободиться от унизительной зависимости от каганата.

Вопрос об этом поднял Джа'фар ибн Абдаллах во время одной из встреч с ибн Фадланом. И касался он денег в количестве пяти тысяч динаров из дозволенных Аллахом источников, обещанных, как сообщалось в письме халифа, в качестве благословения повелителя правоверных на постройку крепости. В силу ряда непредвиденных обстоятельств их не удалось доставить, и Джа'фар ибн Абдаллах после разговора на повышенных тонах с секретарём посольства объявил о решении начать строительство «на свои средства, на серебро или золото», которых у него в казне было достаточно («достать их не было никакой трудности»).

И отъехал булгарский правитель к реке под названием «Джавшыр»[3], и оставался около неё два месяца.

[3] Полагают, что это р. Малый Черемшан.



*Г.И. Семирадский. Похороны знатного руса в Булгаре. 1883.*
*Государственный Исторический музей, Москва*
*Г.И. Семирадский. Болгарда бай рус кешесен күмү. 1883 © Дәүләт тарих музее, Мәскәү*

саллары булып торалар. Җәгъфәр ибн Абдаллаһның улы Итилдә тоткынлыкта газап чигә, сөекле кызын җария итеп хәрәмдәге хатыннар янына алып китмәкчеләр. Шуңа күрә, Болгар патшасының хәзәрләрдән бәйсезлеккә омтылуын аңларга була.

Хәрби ныгытма төзү мәсьәләсен Багдад илчеләре белән очрашуда Болгар ханы үзе күтәрә. Эш шунда ки, Багдад хәлифәсе үзенең хатында Болгар илендә ныгытылган кала төзү өчен, Аллаһы Тәгалә тарафыннан мөмкин дип саналган чыганаклардан алып, дүрт мең динар акча вәгъдә иткән була. Ибн Фадланга кагылмаган төрле сәбәпләр аркасында, бу акча Болгарга килеп җитми. Җәгъфәр хан Ибн Фадланның аклануларын тыңларга да теләми: табыгыз акчаны – бетте-китте. Ахыр чиктә, Болгар патшасыннан Багдад илчесе болай дип сорый:

*«Синең дәүләтең бик зур, акчаларың күп, керемең күпсанлы, ә син ни өчен хәлифәдән киләчәк аз гына акчага ныгытма төзеп бирсен дип үтендең?»* Җәгъфәр ибн Абдаллаһның җавабы бик төпле:

*«Ул акчалар дини кануннар тарафыннан рөхсәт ителгән чыганаклардан алыналар дип санадым. Һәм чыннан да, әгәр дә мин үземнең акчаларга, көмешләргә яки алтыннарга*




***Багдад между 150 и 300 годами хиджры. По публикации 1883 года***

***Багдад һиҗри календаре белән 150 һәм 300 еллар арасында. 1883 елгы басма буенча***

не полностью. Исследователи не без основания полагают, что на реке Джавшыр состоялось заложение «крепости», вернее, настоящего города с Соборной мечетью в его центре – города Биляра. То есть осуществилось то, о чём просил халифа в своём письме булгарский правитель.

Напомним, в посольстве из Багдада первоначально было около пяти тысяч человек. Большинство из них скоро покинуло его, побоявшись трудностей предстоящего пути. Среди прибывших в страну булгар членов посольства были, несомненно, «умелые строители для сооружения крепости», о чём писал ещё Ш. Марджани. Под их руководством и была заложена «крепость».

Обратим внимание на планировку Биляра. Она двухчастная и включает в себя концентрически расположенные внутреннй и внешний город с мощными укреплениями в виде высоких земляных валов с деревянными стенами по гребню и глубоких рвов. Подобная структура очень характерна для урбанитических центров Востока во многих мусульманских странах. Подобная планировка и структура была широко распространена в это

*«Кроме того, он захотел, чтобы произошла перекочёвка [племён], и послал за народом, называемым суваз, приказывая им перекочевать вместе с ним. Они же отказали ему <…> И послал к ним царь булгар и сказал: «Воистину, Аллах могучий и великий даровал мне ислам и верховную власть повелителя правоверных, и я – раб его [Аллаха], и это – дело, которое он возложил на меня, и кто мне будет противиться, того я поражу мечом…»*. Когда он [Джа'фар ибн-Абдаллах] отправил им это послание, то они испугались его намерения и все вместе поехали совместно с ним к реке Джавшыр». Туда же направились люди из племени эсегел/искил.

Что происходило на этом месте летом 922 года? У ибн Фадлана нет прямого ответа на этот вопрос – рукопись его «Записок» сохранилась

*ныгытма төзергә теләгән булсам, минем өчен моңарда бернинди авырлык булмас иде»*.

Һәм Болгар ханы Җәгъфәр ибн Абдаллаһ Җаушир[1] дип аталган елга янына кузгалып китә. Биредә ул ике ай чамасы була. Җауширгә киткәнче, ул барлык кабилә башлыкларына хәбәр җибәрә. Алар үзләренә буйсынган халыкның бер өлешен (ир затларын) алып, килеп тә җитәләр. Арада сувар (суваз) дип аталучы кабилә юлбашчысы гына күренми. Алар, күрәсең, Җауширгә барудан баш тартканнар. Болгар патшасы аларга тагын бер чакыру җибәрә һәм кисәтә: *«Кодрәтле һәм бөек Аллаһ миңа Ислам динен һәм мөселманнар хөкемдарының хакимлеге дәрәҗәсен бүләк итте. Һәм мин аның колы, бу эшне ул (Аллаһ) миңа үзе йөкләде... Һәм кем дә кем миңа каршылык күрсәтсә, мин аны кылыч белән чабармын»*. Бу кисәтүдән соң, сувар халкы тиз арада Болгар ханына кушыла.

922 елның җәендә Җаушир елгасы янында нинди вакыйга булган соң? Бу турыда Ибн Фадлан язмаларында бер сүз дә әйтелмәгән (хәер, ул язмалар безгә тулысынча килеп тә җитмәгән бит). Галимнәргә тагын фаразларга гына кала.

Аларның фикеренчә, Җаушир елгасы буенда Җәгъфәр ибн Абдаллаһ белән килгән болгар төзүчеләре һәм Багдад илчелеге составына кергән шәһәр төзү осталары, бүген кулланыла торган сүз белән әйткәндә, архитекторлар, Биләр каласына нигез салалар. Эшне хәрби ныгытмалар һәм булачак шәһәр үзәгендә мәчет төзүдән башлыйлар. Ягъни мәсәлән, Болгар ханының Багдад хәлифәсенә язган үтенечен тормышка ашыра башлыйлар.

Исегезгә төшерәбез, Багдад илчелеге составында башта берничә мең кеше була. Алар арасында Ислам дине белгечләре һәм хәрби ныгытмалар, шәһәр-крепостьлар төзү буенча тәҗрибәле осталар булгандыр дип уйларга кирәк. Илчелекнең бер өлеше, бәлки әле күпчелегедер дә, юл авырлыкларыннан куркып, кире кайтып китәләр. Ә Болгарга килеп җиткәннәре арасында, һичшиксез, шәһәр ныгытмалары һәм мәчетләр төзү осталары булгандыр. Бу турыда Ш. Мәрҗани да шулай яза, күренекле тарихчыларыбыз да каршы фикер әйтмиләр.

Биләрнең планына күз салыйк. Ул бер-берсенә кереп утырган ике өлештән – бер үк вакыт аралыгында барлыкка килгән эчке һәм тышкы шәһәрләрдән тора. Урыны-урыны белән икешәр рәтле калын диварлар – туфрак өеп ясалган биек үрләр, шул үрләргә куелган агач буралар һәм башнялар белән ныгытылган эчке шәһәрнең мәйданы 130 гектар чамасы. Өч рәт диварлар белән уратып алынган тышкы шәһәр исә 490 гектар җирне биләп тора. Крепость диварларының гомуми озынлыгы 40 километр чамасы. Мондый структура Шәрыкның күп кенә мөселман илләренең урбанистик үзәкләренә хас, охшаш планировка һәм структура бу вакытта Урта Азиядә киң таралган

[1] Хәзер бу елганы Кече Чирмешән дип йөртәләр.




*Аэтофотосъемка Билярского городища – археологических остатков города Биляра*

*Биләр шәһәрлегенең 1973 елда төшерелгән аэрофотопланы*

города и охватывающих её кольцом торгово-ремесленных кварталов. При планировании Биляра градостроители, присланные халифом, безусловно, исходили из структуры и особенностей городских построек, характерных для мусульманских городов Востока.

В центре внутреннего города Биляра до сегодняшнего дня сохранились остатки белокаменной мечети с примыкающей к ней более ранней деревянной мечетью общей площадью около 2500 кв. м (не исключено, что деревянная часть была постро-

время в Средней Азии. Средневековый Багдад, из которого вышло посольство аббасидского халифа, тоже был круглым в плане и состоял из двух укреплённых частей: резиденции халифа в центре



*Вид сверху на раскопки центральной части внутреннего города Биляра с остатками мечети и кирпичного здания, получившего название «Дом феодала»*

*Биләрнең үзәк өлешендәге борынгы архитектура корылмаларының югарыдан күренеше: таш һәм агач мәчет, шартлы рәвештә «феодал йорты» дип аталган кирпеч бина хәрабәләре.*




була. Шунысы кызык, Биләр үзенең планировкасы белән урта гасырлар Багдадын хәтерләтә. Багдад та бит хәлифә резиденциясе урнашкан эчке һәм сәүдә-һөнәрчелек бистәләрен берләштергән тышкы шәһәрдән гыйбарәт булган. Биләрне планлаштырганда, хәлифә тарафыннан җибәрелгән шәһәр төзүчеләре, һичшиксез, Шәрыкның мөселман калаларына хас шәһәр корылмаларының структурасын һәм үзенчәлекләрен исәпкә алып эш иткәннәр.

Биләрнең эчке шәһәрендә, аның үзәгендә диярлек, гомуми мәйданы якынча 2500 квадрат метр булган ак таштан төзелгән мәчет һәм аңа тоташкан борынгырак агач мәчет калдыклары бүгенге көнгә кадәр саклан-

*Консервация руин Соборной мечети в Биляре. Современный вид*

*Биләрдәге Җамигъ мәчете хәрабәләре консервациядән соң*






*Варианты реконструкции Соборной мечети в Биляре*
*(а,б – по С.С. Айдарову и Ф. Забировой; в – по Э.Д. Зеливинской)*

*Җамигъ мәчетнең график реконструкцияләре:*
*а, б – С.С. Айдаров һәм Ф.М. Зәбирова буенча; в – Э.Д. Зиливинская буенча*



*Город Биляр, Соборная мечеть. XII в. По картине художника Р. Шамсутдинова*

*Р.Г. Шәмсетдинов. Биләр шәһәре. Җамигъ мәчет. XII гасыр*

ена раньше). Рядом с ней находятся руины кирпичного здания с архитектурными деталями, характерными, по мнению историков архитектуры, для строительной традиции Ближнего Востока и Средней Азии IX–X вв. Весьма любопытно, что в районе мечети в ранний период существования города располагались каркасно-глинобитные жилища с печами-тандырами, в том числе и переносными. Такие жилища совсем не характерны для нашего края. В них, вне всякого сомнения, жили восточные мастера-строители, прибывшие в составе Багдадскоо посольства.

Судя по всему, миссия посольства из Багдада завершилась весьма успешно, о чём Ахмад ибн Фадлан доложил по возвращении в Багдад самому халифу в своём письменном отчёте, один из списков которого по сей день хранится в одном из архивов города Мешхеда (Иран). Нужно при-

*Реконструкция «Дома феодала» в Биляре*
*Биләрдә «феодал йорты». А.Х. Халиков реконструкциясе*



ган. 1970 елларда Казан археологлары шул мәчет харәбәләрен казып чыгардылар. Бик ачык күренеп тора: X гасырның беренче яртысында ул ике өлештән торган. Борынгысы, 1400 квадрат метр мәйданда агач бүрәнәләрдән салынган өлеше, профессор А. Халиков фаразлавынча, IX гасырда ук корылмаган микән? 922 елда аның ак таштан салынган өлешен торгызганнар булса кирәк. Ул 1076 квадрат метр мәйданны били. Таш мәчетнең эчендә алты рәт колонналар тезелгән (һәр рәттә дүртәр колонна). Көньяк-көнчыгыш дивары ярымколонналар – пилястрлар белән ныгытылган.

Бу – Идел Болгарстаны дәүләтендә археологлар тарафыннан өйрәнелгән иң борынгы мәчет һәм ул, турыдан-туры булмаса да, Биләрнең беркайчан да гади шәһәрләр рәтендә йөрмәвенә ишарәли. Белгечләрнең раславынча, ул заманнарда Җәмигъ мәчете – вәгазь сөйләү һәм ил хакиме (хан/әмир) исемен кушып хөтбә уку өчен имам-хатибка дип махсус ясалган мөнбәре белән – бары тик дәүләтнең административ үзәгендә генә булган.

Шушы мәчет янында ук 1971–1972 елларда кирпечтән салынган зур гына бина харәбәләре тикшерелде. Биредә үзенең гаиләсе белән югары дәрәҗәле берәр дин әһеле яшәгәндер дип уйланыла иде. Бүген исә аның функциясен мунча яисә таһәрәтханә белән бәйләп аңлаталар. Бу фикер идән астында урнашкан җылыту системасы каналлары, суүткәргеч торба ватыклары кебек табылдыклар белән раслана. Архитекторлар исә Биләр биналары төзелешендә Якын Көнчыгыш һәм Урта Азия архитектурасы элементларын табалар.

Тагын бер кызыклы факт: мәчет тирәсендә гади кешеләр яши торган агач йортлар, хуҗалык корылмалары, ашлык саклау амбарлары урнашкан. Арада безнең якларга бөтенләй дә хас булмаган торак йортлар да бар. Аларның стенасы, талчыбыктан үрелеп, ике яктан калын итеп кызыл балчык белән сыланган. Өй эчендә, ишегалдында тандыр тибындагы мичләр тора. Баш ватып та торасы юк: биредә, һичшиксез, Урта Азия якларыннан, Шәрык илләреннән килгән кешеләр яшәгән. Ирексездән, «Багдад илчелеге белән килгән төзүчеләр түгел микән?» дигән уйлар туа.

знать и тот факт, что путешествие, оставившее прекрасные записи Ибн Фадлана, уже само по себе стало ценнейшим источником по истории распространения ислама среди народов Евразии.



Тарих фәнендә урын алган төрле фикерләргә карамастан, Багдад илчелеге алдында торган бурычлар тулысы белән диярлек тормышка ашырыла дип әйтәсе килә. Һәм Әхмәт ибн Фадлан, кире Багдадка әйләнеп кайткач, бу турыда хәлифәнең үзенә хисап тота. Аның кыйммәтле язмалары бүгенге көндә Мәшхәд шәһәренең (Иран) бер архивында саклана. Ибн Фадланның уникаль язмаларын калдырган сәяхәтнең Евразия халыклары арасында Ислам диненең таралу тарихын тасвирлау да үзе үк гаҗәеп күренеш булуын танырга кирәк.



*Консервация руин гражданского здания («Дом феодала»), расположенного рядом с Соборной мечетью Биляра. Современный вид*

*Җәмигъ мәчете янында урнашкан «феодал йорты» консервациядән соң. Бүгенге күренеше*

## Самая северная страна в мусульманском мире

Так стали называть Волжскую Булгарию, официально признанную со стороны Халифата в качестве одного из звеньев в цепи государств средневековой мусульманской культуры. Впрочем, у неё было и другое название – «страна у Моря Мрака». Оба названия подчёркивают невероятную для тех времён удалённость Булгарии от остальных стран мусульманского мира, занимавших южный пояс евразийского континента.

Волжская Булгария была крупным государством и занимала земли, где в настоящее время компактно проживают их потомки – волго-уральские татары. Археологические памятники булгар обнаружены в основном на территории Татарстана, в юго-восточных районах соседней Чувашии, в Ульяновской, Самарской, Пензенской областях. Отдельные памятники, в том числе в виде довольно крупных городищ, известны в Астраханской области и Пермском крае.




*Волжская Булгария в X–XIII веках. Художественное воспроизведение карты. Авторы И. Артамонов, А. Леухин, Ф. Валиуллин, Р. Шигабутдинов, И. Щетинин. Музей Болгарской цивилизации, Болгар*

*Идел Болгары биләмәләре X–XIII гасырларда. Картаның сәнгатьчә күчерелмәсе. Авторлар: И. Артамонов, А. Леушин, Ф. Вәлиуллин, Р. Шиһабетдинов, И. Щетинин*

*© Болгар цивилизациясе музее. Болгар*

## Ислам дөньясындагы иң төньяк ил

Шулай итеп, Урта гасыр мөселман цивилизациясе, дәүләтләре чылбырындагы буыннарның берсе буларак, хәлифәлек тарафыннан рәсми рәвештә танылган Идел буе Болгарын атый башлыйлар. Хәер, аның икенче исеме дә бар – «Караңгылык диңгезе янындагы ил» («страна у Моря Мрака»). Әйе, Болгар иле Евразия кыйтгасының көньяк поясын биләп торган мөселман дөньясындагы башка илләрдән бик еракта урнашкан шул. Бу исем шуңа ишарәле.

Идел буе Болгары зур дәүләт булган һәм хәзерге вакытта аларның варислары – Идел-Урал татарлары яши торган җирләрне биләп торган. Болгарларның археология истәлекләре (һәйкәлләре) нигездә Татарстан территориясендә, күрше Чувашстанның көньяк-көнчыгыш районнарында, Ульян, Самара, Пенза өлкәләрендә табылган. Аерым һәйкәлләр, шул исәптән шактый зур шәһәрлекләр, Әстерхан өлкәсендә һәм Пермь краенда билгеле.

X гасырда бу җирләрдә «әс-сәкалибә» – «төньяк халыклары», ягъни болгарлар, барсиллар (берсула), эсегелләр, суварлар (савирлар), биләрләр һәм бәрәнҗәлар яшәгән, дип яза Ибн Фадлан. Гарәп тарихчылары исә: *«Бу кабиләләр еш кына үзара сугышып торганнар, ә инде читтән берәр дошман килеп чыкса, берләшеп каршы торганнар»*, – дигән хәбәрләр калдырган. X йөз ахырында бердәм болгар халкы оеша, элеккеге кабилә исемнәре онытыла. Яңа дин, этносәяси процессларда үзенең берләштерүче ролен күрсәтеп, күпсанлы кабиләләрне бер хаким тирәсенә туплый алды.



*Р. Загидуллин. Вспашка (булгары X века). 2008*
*Р.Г. Заһидуллин. Ашлык басуын сөрү. (X гасыр болгарлары). 2000*

На этой территории в X веке обитали различные племена, которые ибн Фадлан называл «ас-сакалиба» – «народами Севера»: булгары, барсилы (берсула), эсегелы, сувары (савиры), билеры и баранджары. Эти племена, как писали арабские историки, «находились в войне друг с другом, когда же появлялся враг, становились друзьями». Многочисленные племена объединились вокруг единого правителя, и в этом этнополитическом процессе проявила свою консолидирующую роль новая религия.



*Ф.Х. Якупов. Мастер Музей Болгарской цивилизации, Болгар*

*Ф.Х. Якупов. Һөнәрче. © Болгар цивилизациясе музее. Болгар*

Волжская Булгария стала самым ранним и северным мусульманским анклавом мира. Сам факт проникновения ислама так далеко на север является событием мирового масштаба. Булгарское государство, находившееся на невообразимом по тем временам расстоянии от центров ислама, в короткий исторический срок стало одним из ярких образцов средневековой культуры эпохи мусульманского ренессанса. До настоящего времени это определило характер веры, обычаев, традиций, социальных и нравственных норм жизни, в целом культуры и духовности в этом геокультурном регионе. Посольство Багдадского халифата, вошедшего во Всемирную историю с именем Ибн Фадлана, способствовало не только официальному принятию ислама, но и дипломатическому признанию Волжской Болгарии в качестве мусульманского государства. В регионе Волго-Уралья стремительно изменилась этноконфессиональная ситуация, на тысячелетия определив его своеобразие, которое отразилось на всех сферах жизни – экономике, культуре, науке, образовании, духовной жизни. А путевые записки Ибн Фад-



*Остатки металлургического горна, выявленные во время археологических раскопок в Болгаре в 1949 году. Рисунок Д.И. Архангельского*

*Болгарда 1949 елгы казылмаларда табылган тимер коюю миче. Д.И. Архангельский рәсеме*



*Булгарский плуг. Реконструкция*
*Болгар сабаны. График реконструкция*

Идел буе Болгары дөньяның иң борынгы саналган, ягъни элгәреге һәм иң төньяк мөселман анклавына әверелә. Ислам диненең төньякка шулай ерак үтеп керү факты үзе дөньякүләм масштабындагы вакыйга булып тора. Ул чордагы Ислам цивилизациясе үзәкләреннән күз алдына да китерә алмаслык ераклыкта урнашкан Болгар дәүләте кыска гына вакыт эчендә мөселман ренессансы чорындагы урта гасыр мәдәниятенең иң күренекле үрнәкләренең берсенә әйләнә. Бүгенге көнгә кадәр бу геомәдәни төбәк диннең, гореф-гадәтләрнең, традицияләрнең, яшәештәге социаль һәм әхлакый нормаларның, гомумән, мәдәниятнең һәм рухи халәтнең табигатен билгеләде. Бөтендөнья тарихына Ибн Фадлан исеме белән кергән Багдад хәлифәлеге илчелеге Ислам динен рәсми кабул итүгә генә түгел, ә бәлки Идел буе Болгарын мөселман дәүләте буларак дипломатик тануга да ярдәм иткәндер. Идел-Урал төбәгендәге этноконфессиональ вәзгыять, гасырларга үзенең үзенчәлеген такъ дим итеп, бик тиз үзгәрә, ул тормышның барлык өлкәләрендә – икътисадта, мәдәнияттә, фәндә, мәгарифтә, рухи тормышта чагылыш таба. Ә Ибн Фадланның юл язмалары татар, урыс, алман, француз, инглиз һ.б. телләрдә сәнгать әсәрләрендә, дөнья кинематографиясендә һәм мәдәниятнең башка өлкәләрендә күпсанлы басмаларда чагылыш тапкан урта гасыр мөселман әдәбиятының «Рисалә» жанрындагы шедеврлары булып тора. Идел Буе Болгарының күп гасырлык мәдәни мирасының уникаль үзенчәлеге гасырлар дәвамында төрки, Көнчыгыш,



*Кузнечные инструменты.*
*Графическая реконструкция*
*Тимерче кораллары.*
*График реконструкция*



*Железные косы и серп. Билярское городище. X – начало XIII века (История татар, т. 2, см. вкладыш после с. 208)*
*Тимер чалгылар һәм урак. Биләр шәһәрлеге. X – XIII гасыр башы. «История татар. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь» (Казань, 2006) китабыннан алынган рәсем*



*Кузница в Билярском городище. Графическая реконструкция (по А.Х. Халикову и Ю.А. Семыкину)*

*Биләр шәһәрлегендә тимерче алачыгы. Реконструкция. (А.Х. Халиков һәм Ю.А. Семыкин буенча)*

лана, составленные им, являются шедевром средневековой мусульманской литературы в жанре «Рисаля», переведенного на татарский, русский, немецкий, французский, английский и др. языки, воплощенный в произведениях искусства, в мировом кинематографе и других сферах культуры.

Уникальное своеобразие многовекового культурного наследия Волжской Булгарии основано на плодотворном взаимовлиянии в течении столетий тюркских, восточных, поволжско-финнских, европейских традиций. Эти стилистические особенности городской архитектуры находились во взаимодействии друг с другом и отражают разнообразное влияние на протяжении длительного периода времени. Памятники булгар являются наглядным примером творческого и плодотворного использования разнообразных строительных традиций, которые были талантливо адаптированы булгарскими архитекторами к местным условиям. Воплощенные в камне их замыслы – здания мечетей, минаретов, мавзолеев и бань – не только определили облик булгаро-татарской урбанистической культуры, но также значительно повлияли на градостроительную культуру Казанского ханства, а в дальнейшем и Российского государства.

Население Волжской Булгарии занималось в основном земледелием. Арабский географ начала X века ибн Русте писал: *«Болгары – народ земледельческий и возделывают всякого*



*Каменные литейные формы. Билярское городище. X – начало XIII века (История татар, т. 2, см. вкладыш после с. 208).*

*Таштан ясалган кою формалары. Биләр шәһәрлеге. X – XIII гасыр башы. «История татар. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь» (Казань, 2006) китабыннан алынган рәсем*



*Гривна и два браслета. Серебро. X – начало XIII века (История татар, т. 2, см. вкладыш после с. 208)*

*Муенса һәм беләзекләр. Көмеш. X гасыр ахыры – XIII гасыр башы. «История татар. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь» (Казань, 2006) китабыннан алынган рәсем*



*Фрагмент булгарской височной подвески, скань, зернь. Музей истории государственности татарского народа и РТ ГИАиХМЗ «Казанский Кремль». Предположительное место находки – Билярское городище*

*Болгар чигә асылмасы өзеге, скань, зернь. Татар халкы дәүләтчелеге тарихы һәм ТР музее (Казан Кремле дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы). Табылу урыны, фараз буенча – Биляр шәһәрлеге*

*Височное кольцо-уточка из Мокрокурналинского клада Волжская Булгария. XI–XII века. Национальный музей Республики Татарстан*



*Юеш Көрнәле хәзинәсеннән божра эчендәге үрдәк рәвешле чигә алкасы. XI–XII гасырлар. © Татарстан Республикасы Милли музее. Казан*



*Височная подвеска из Кожаевского клада Конец XI – начало XII века Золото; литьё, ковка, пайка, зернь, обкладка основы золотой фольгой. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Кожаевка хәзинәсеннән чыккан чигә асылмасы. XI гасыр ахыры – XII гасыр башы. Коюю, чүкү, ябыштыру, бөртекләү, алтын фольга белән каплау ысуллары кулланылган © Болгар дәүләт тарих- архитектура музей-тыюлыгы*



*Бусы и подвески. Стекло, янтарь, сердолик, халцедон, гешир, кашин. Билярское городище. X – начало XIII века (История татар, т. 2, см. вкладыш после с. 208)*

*Муенса төймәләре һәм асма бизәкләр. Пыяла, гәрәбә, сердолик, халцедон, гешир, кашин. Биләр шәһәрлеге. X гасыр ахыры – XIII гасыр башы. «История татар. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь» (Казань, 2006) китабыннан алынган рәсем*



*Гребень односторонний. Волжская Булгария. XII век. Кость. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Чәч тарагы. Сөяк. Идел Болгары. XII гаыр. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



*Татарские сапоги «ичиги», выполненные в традициях булгарского кожевенного ремесла. Работа современных мастеров*

*Болгар һөнәрчеләренең тире эшкәртү традицияләренә нигезләнеп эшәнгән татар читекләре. Бүгенге һөнәрчеләр эше*

Идел буе фин-угыр, Европа һәм урыс традицияләренең үзара нәтиҗәле йогынтысы белән бәйле. Шәһәр архитектурасының әлеге стилистик үзенчәлекләре бер-берсе белән үзара бәйләнештә булган һәм озак вакыт дәвамында кичергән төрле йогынтыларны чагылдыра. Болгар һәйкәлләре төрле төзелеш традицияләрен иҗади һәм нәтиҗәле куллануның ачык мисалы, аларны Болгар архитекторлары оста итеп җирле шартларга яраклаштырганнар. Аларның таштан (мәчет, манара, мавзолей һәм мунча биналары) тормышка ашырылган идеяләре болгар-татар урбанистика йөзен билгеләп кенә калмыйча, Казан ханлыгының, соңрак Россия дәүләтенең шәһәр төзелеше мәдәниятенә дә зур йогынты ясый.

Болгар халкы, башлыча авылларда яшәп, игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән. Гарәп географы Ибн Рөстә: *«Болгарлар – нигездә игенчелек белән көн күрүче халык, бодай, арпа, тары һ.б. төрле ашлык иккәннәр»*, – дип язган. Халык икмәккә кытлык кичермәгән, моннан тыш, ашлык экспортның иң мөһим маддәләренең берсе булган. 1024 елда, Суздаль җирендә башланган ачлык вакытында, дип хәбәр итә рус елъязмачысы, *«болгарлар ашлык алып килделәр, һәм халык ачлыктан котылды» («болгары привезоша жито и тако ожиша»).* Корылыклы 1229 елда *«болгарлар Идел буйлап бөтен рус шәһәрләренә ашлык ташыдылар һәм саттылар, һәм шуның белән зур ярдәм иттеләр» («болгары возили жито по Волге во все грады русские и продавали, и тем великую помощь сделали»)..*

Шәһәрләрдә һөнәрчелек үсә. Әйдәп баручы тармаклар – кара металлургия һәм металл эшкәртү – теләсә кайсы җәмгыятьнең икътисади көче, нигезе. Тимерчелек эшендә билгеле бер хезмәт бүленеше булган, ягъни мәсәлән, бер остаханәдә авыл хуҗалыгы кораллары җитештергәннәр, икенчеләрендә коралчылар эшләгән, өченчеләре көндәлек тормышта кирәкле көнкүреш әйберләре ясау белән мәшгуль булган. Төсле металл эшкәртү буенча һөнәрчеләр продукциясе халык арасында аеруча зур ихтыяҗга ия була. Зәркәнчелек югары дәрәҗәгә ирешә. Зәркәнчеләр кыйммәтле металл эшкәртүнең катлаулы алымнарын белгәннәр. Алар, мәсәлән, хатын-кызлар өчен бизәнү әйберләре ясаганда, бик нечкә алтын-көмеш җепләрдән үреп ясау (филигрань, скань) һәм бөртекләү (зернь) техникасын еш кулланганнар. Ювелир һөнәренең искиткеч үрнәге булып алтын боҗра эченә үрдәк сыны урнаштырылган һәм шул боҗрага нечкә чылбыр белән имән чикләвеге рәвешендәге өч төймә ялганган чигә алкалары санала.

Болгар чүлмәкчеләренең уңышларын шәһәр һәм авыл җирлекләрендә археологлар тарафыннан ачылган югары җитештерүчәнле савыт-саба яндыру мичләре генә түгел, ә Көнчыгыш Европаның барлык төбәкләрендә бу савыт-сабаларның киң таралу факты да күрсәтә. Рус кенәзлекләрендәге шәһәрләрнең барысында да диярлек археологик казылмалардан



*Глиняные тигли, железные ножницы и молотки. Билярское городище. X – начало XIII века (История татар, т. 2, см. вкладыш после с. 208)*

*Эретелгән төсле металл салу өчен кулланыла торган балчык савытлар (тигельләр), тимер кайчы һәм чүкечләр. Биләр шәһәрлеге. X – XIII гасыр башы. «История татар. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь» (Казань, 2006) китабыннан алынган рәсем*

*рода зерновой хлеб, как-то: пшеницу, ячмень, просо и другие»*. Судя по всему, народ не испытывал недостатка в хлебе, более того, зерновой хлеб был одной из важнейших статей экспорта. В 1024 году, во время голода в Суздальской земле, как сообщает «Повесть временных лет», русские отправились в «Болгары и привезоша жито и тако ожиша». В засушливом 1229 году «болгары возили жито по Волге во все грады русские и продавали, и тем великую помощь сделали».

В городах развивались ремесла. Ведущими отраслями были чёрная металлургия и металлообработка – основа экономической мощи любого общества. В кузнечном деле существовала определённая специализация: в одних мастерских производили сельскохозяйственные орудия, в других работали оружейники, третьи были заняты изготовлением бытовых предметов, необходимых в повседневной жизни. Широким спросом у населения пользовалась продукция ремесленников по обработке цветных металлов. Высокого уровня достигло ювелирное ремесло. Ювелиры знали сложнейшие приёмы обработки драгоценных металлов. Они владели, например, техникой скани (филиграни) и зерни. Великолепным образцом ювелирного ремесла по праву считаются височные подвески в виде кольца с ажурной фигуркой уточки в центре и тремя привесками-бусами на тонких цепочках.



*Замок бронзовый в виде барса Билярское городище. X – начало XIII века*

*Барс сурәтле бронза йозак. Биләр шәһәрлеге. X – XIII гасыр башы*



*Бронзовая поясная пряжка. Билярское городище. X – начало XIII века*

*Бил каешы прәшкәсе. Бронза. Биләр шәһәрлеге. X – XIII гасыр башы*

Успехи булгарского гончарства



*Горшковидный сосуд. Билярское городище. X – начало XIII века (История татар, т. 2, см. вкладыш после с. 208)*

*Тоткалы чүлмәк. Биләр шәһәрлеге. X – XIII гасыр 57 башы. «История татар. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь» (Казань, 2006) китабыннан алынган рәсем*

яхшы сыйфатлы болгар керамикасы табыла.

Болгар шәһәрләрендә пыяла әйберләр җитештерү XI гасырда башлана. Биләрдә уникаль һөнәрчелек комплексы – пыяла савытлар ясау остаханәсе ачыла. Әлеге һөнәрчелекнең элитар, бары тик эре шәһәрләрдәге җитештерү үзәкләрендә генә барлыкка килү мөмкинлеген ассызыклап үтәргә кирәк. Бу төр җитештерүне үзләштерү факты, тулаем алганда, ил икътисады үсешенең гомуми дәрәҗәсен дә ачык күрсәтеп тора.

Болгар шәһәрләрендә шулай ук күнчелек һөнәре дә үсеш ала. Көнчыгыш һәм Көнбатышның күп кенә илләрендә «болгари» дип аталган югары сортлы тире эшләнмәләре бик кыйммәт бәяләнгән.

Урта гасыр сәяхәтчеләре Идел буе Болгарын «шәһәрләр иле» дип атаганнар. Шул ук вакытта Болгар дәүләтенең «сәүдәгәрләр иле» дигән даны да булган. Сүз дә юк, Болгар икътисадының нигезен авыл хуҗалыгы (игенчелек, терлекчелек) һәм һөнәрчелек тәшкил иткән. Әмма хуҗалыкның әлеге тармакларында җитештерелгән продукция, беренче чиратта, халыкның үз ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә киткән, ягъни



*Миски и кувшины. Билярское городище. X – начало XIII века (История татар, т. 2, см. вкладыш после с. 208)*

*Җамаяклар һәм кувшиннар. X – XIII гасыр башы. «История татар. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь» (Казань, 2006) китабыннан алынган рәсем*

товар эчке базарга чыгарылган. Бер яктан, шәһәр белән авыл, икенче яктан, илнең төрле төбәкләре арасында җанлы сәүдә барган. Ә дәүләт казнасы эчке сәүдә түгел, башлыча тышкы сәүдә хисабына баеган.

Моның чыннан да шулай икәнен раслау өчен язма чыганакларга



*Трипод с зооморфной ручкой. Билярское городище. XII – начало XIII века (История татар, т. 2, см. вкладыш после с. 208)*

*Зооморф тоткалы өчаяк. Биләр шәһәрлеге. XII гасыр. «История татар. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь» (Казань, 2006) китабыннан алынган рәсем*

наглядно демонстрируют не только десятки высокопроизводительных горнов для обжига посуды, открытых



*А.А. Пашин. Гончар. 2013*
*А.Л. Пашин. Чүлмәкче. 2013*

археологами на городских и сельских поселениях, но и сам факт чрезвычайно широкого распространения этой посуды на обширных территориях Восточной Европы.

Начало производства стеклянных изделий в булгарских городах относится к XI веку. В Биляре выявлены остатки уникального производственного комплекса – мастерской алхимика и стеклодува. Следует подчеркнуть исключительно городской, элитарный, характер стеклоделия. Оно могло возникнуть только в крупных производственных центрах с богатыми ремесленными традициями. Факт освоения этого вида производства булгарами является ярчайшим показателем общего высокого уровня развития экономики страны в целом.

В булгарских городах развивались также косторезное ремесло и кожевенное дело. Во многих странах Востока и Запада чрезвычайно высоко ценился особый сорт тонко обработанной кожи, называемый «булгари». Под 985 годом «Повесть временных лет» сообщает о булгарских воинах, которые «суть вси в сапозех».

Высокоразвитые ремесла способствовали расширению торговли. По Великому Волжскому пути плыли торговые суда, направляющиеся в Северо-Восточную Русь, в Хазарию (Итиль), Саксин, Крым и Кавказ, «Пушной путь» по Каме связывал булгарских торговцев с народами Урала и Сибири. Купеческие караваны двигались по пути из Болгара в Киев, подробно описанному в сочинении ал-Идриси (1153), и по другим хорошо известным сухопутным магистралям, находившимся под контролем и охраной государства. Тесное сотрудничество



*Гончарный сосуд. Булгары. XII–XIII века. Керамика. Кожаевское IV селище. Болгарский государственный историко- архитектурный музей-заповедник*

*Тар авызлы һәм тоткалы балчык савыт. XII–XIII гасырлар. Кожаевка IV авыллыгы. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*

мөрәҗәгать итик. Игътибарыгызны бер нәрсәгә юнәлтәсе килә: безнең көннәргә кадәр килеп җиткән язма чыганакларның барысы да чит ил укымышлылары тарафыннан язылган. Чит ил кешеләре ни өчен Болгар белән кызыксынганнар икән, дисезме? Болгар сәүдә иле булганга. Элек тә, хәзер дә шулай инде ул – һәр дәүләт үзендә җитештерелгән товарларның бер өлешен чит илгә чыгарып, кыйммәтрәк бәягә сатарга тырышкан. Дөнья базарына чыгу өчен конкуренция шул заманнарда ук булган. Идел буе Болгары (Идел Болгарстаны) исемле яңа дәүләт барлыкка килгәч, бирегә дөньяның төрле почмакларыннан, бигрәк тә Шәрык илләреннән, сәүдәгәрләр агыла башлый. Географларның энциклопедик язмаларында Болгар һәм аның халкы турында белешмәләр бирелә. Алай гына да түгел, Болгарны дөнья карталарында күрсәтәләр. Бу җәһәттән гарәп географы әл-Идрисинең Болгар – Киев сүдә юлының картасы урнаштырылган 1154 елгы «Сәяхәткә сусаганнарга күңел ачу» исемле хезмәтен искә төшереп үтәргә була.

Идел буе Болгары геополитик яктан искиткеч уңай урында – Бөек Ефәк юлының төньяк тармагы булган Балтыйк – Идел юлы белән Чулман юлы – кыйммәтле мех юлы – кисешкән төбәктә калкып чыга. Болгар ханнары аның шушы геополитик өстенлегеннән бик оста файдаланалар: Идел буйлап кыйммәтле товарлар төяп килгән шәрык сүдәгәрләрен Болгарда туктаталар, тагын да төньяккарак җибәрмиләр; төньяктан, ягъни Новгород, Ладога якларыннан һәм Балтыйк, Скандинавия илләреннән килгән сәүдә корабларына исә Болгардан түбәнгә йөзәргә рөхсәт итмиләр. Шулай итеп, чит ил сәүдәгәрләре бер-берсе белән Болгар җирендә очрашырга мәҗбүр ителәләр. Ризасызлык күрсәтүче булмагандыр, чөнки тыныч һәм ике якка да файдалы сәүдә өчен биредә бөтен шартлар тудырылган була.

Багдад илчелеге сәркатибе Әхмәт ибн Фадлан язмаларына караганда, сәүдә корабларын болгар ханы шәхсән үзе каршы ала торган була. Һәр товарның уннан бер өлешен ул, сәүдә практикасында кабул ителгән таможня кагыйдәләре буенча, дәүләт казнасына озатып барган. Аңлашыла ки, чит ил сәүдәгәрләреннән тотып калына торган әлеге таможня салымының гомуми күләме сәүдәгәрләр санына һәм төяп килгән товарлар күләменә бәйле булган. Шул заман кешеләре, дәүләт казнасында тупланган байлыкның төп өлешен сәүдәдән кергән дисәтинә тәшкил итә, дип язганнар икән, димәк, Идел буе Болгарының Биләр, Сувар, Җүкәтау ише эре шәһәрләрендә җәен-көзен үткәрелә торган ярминкәләрнең ил тормышындагы роле зур булгандыр, дип уйларга кирәк.

Болгар ярминкәләре дигәннән. Күренекле археолог һәм тарихчы академик Валентин Янин, нумизматика материалларына таянып: *«Болгар VIII–IX гасырлардан ук Рус дәүләтенең сәүдә дөньясындагы көнчыгыш*



*Чашечки и коромысло торговых весов. Билярское городище. X – начало XIII века*

*Бронзадан эшләнгән үлчәү детальләре. Биләр шәһәрлеге. X – XIII гасыр башы. «История татар. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь» (Казань, 2006) китабыннан алынган рәсем*

Волжской Булгарии с Киевской Русью, а позже – с древнерусскими княжествами в области торговли засвидетельствовано специальными договорами, заключёнными между ними в 985, 1006 и 1229 гг. Более оживлёнными и разносторонними были связи булгар с мусульманскими странами Востока.

Сведения о конкретных товарах булгарского экспорта и импорта можно найти в сочинениях восточных авторов. Ибн Фадлан, например, писал о юрте булгарского правителя, устланной армянскими коврами, и троне, покрытом византийской парчой. О поступлении в Булгарию дорогих тканей и ковров из Джурджана, Табаристана, Армении, Азербайджана и Византии сообщают и другие средневековые писатели. Из Самарканда поступала писчая бумага. Большим спросом во все времена пользовались предметы вооружения. Как отмечал ибн Фадлан, булгарские мечи «суть широкие волнообразные клинки франкской работы». По словам ал-Гарнати, купцы привозят высококачественные мечи из мусульманских стран – их «делают в Зенджане, и в Абхаре, и Тебризе, и Исфахане в виде клинков».

По сведениям ал-Масуди, из земли буртасов[4] *«вывозят меха чёрных и красных лисиц, которые и называются буртасскими. Эти меха, особенно чёрные, иногда стоят больше 100 динаров за штуку, красные дешевле. Арабские и персидские цари считают эти чёрные меха выше куньего, собольего и другого меха и делают из них шапки, кафтаны и шубы, так что почти нет царя, не имеющего шубы или кафтана с подкладкой из мехов чёрных лисиц»*. Широкий ассортимент товаров, вывозимых из Булгарии в Хорезм и другие страны, перечисляет арабский географ второй половины X века ал-Мукаддаси: *«Меха: собольи, беличьи, горностаевы, куньи и лесных куниц, лисьи, бобровые; зайцы, козьи шкуры, воск, стрелы, крупная рыба, шапки, белужий клей, рыбьи зубы, бобровая струя, янтарь, юфть, мёд, орехи, барсы (или гончие собаки), мечи, кольчуги, берёзовый лес, славянские невольники, овцы, рогатый скот»*. Об импорте монет мусульманской чеканки сообщает ибн Русте: *«Белые круглые дирхемы привозят к ним из*

[4] Буртасы – близкородственный булгарам тюркский народ, населявший земли Верхнего Посурья и Примокшанья (совр. Пензенская обл.).



*Фрагменты поливной посуды. Билярское городище. XII – начало XIII века*

*Глазурьланган савыт- саба фрагментлары. Биләр шәһәрлеге. XII–XIII гасыр башы*

*капкасы ролен үти башлый»*, – дип язган иде. Ягъни мәсәлән, русларга Шәрык илләреннән килгән товарлар Болгар аша үтеп кергән булып чыга. Бу фикер белән килешмичә булмый, әлбәттә, чөнки ул археология материаллары белән дә раслана.

Шул заман язучылары Ибн Рөстә, әл-Балхи, әл-Мәсгуди, әл-Мөкаддәси Болгардан Хәрәземгә һәм башка Шәрык илләренә чыгарыла торган товарларны санап китәләр. Бу исемлектә кыйммәтле җәнлек (кеш, тиен, сусар, ас, кызыл һәм кара төлке) һәм йорт хайваннары (кәҗә, сарык) тиреләре, яхшы сыйфатлы күн («болгари»), күннән һәм мехтан тегелгән әйберләр (бүрек, тун, кафтан, аяк киемнәре), бал, балавыз, урман чикләвеге, эре елга балыгы, каен агачы, ук очлары, кылыч, көбә күлмәк (кольчуга), сарык, эре мөгезле хайваннар, славян коллары ише товарлар бар.



*Фаянсовая чаша с человеческими личинами. Иран. XII век. Билярское городище. Раскопки А. Халикова, 1978. Археологический музей Казанского университета*

*Кеше йөзләре белән каймаланган фаянс касә. Иран. XI гасыр. Биләр шәһәрлеге. А.Х. Халиков казылмаларыннан. 1978. © Казан университетының археология музее*

Болгардан чыккан экспорт товарларының исемлеген археологик материаллар нигезендә тагын да тулыландырырга мөмкин. Киев



*Мастерская стеклодела. Графическая реконструкция (по О. Куцукерману)*

*Пыяла ясау һөнәрханәсе. График реконструкция. (О. Куцукерман буенча)*

*стран мусульманских путём мены за их товары»*.

Археологические находки расширяют наши знания о внешнеторговых контактах домонгольских булгар. Предметы булгарского экспорта (иногда даже следы проживания булгарских купцов) обнаружены в древнерусских городах Киеве, Старой Рязани, Муроме, Городце, Москве, Суздале, Владимире, Серенске, Ярополче Залесском, Ростове Великом, Новгороде, в других городах и их округах. Отдельные находки, в том числе и монеты булгарской чеканки, известны в Псковской и Новгородской землях, Белоруссии, Украине и Молдове, в странах Прибалтики, Скандинавии, Венгрии и Великобритании. Высококачественная гончарная посуда, ювелирные украшения, бронзовые замочки в виде фигурок животных – наиболее часто встречаемые булгарские изделия на древнерусских землях.

Восточный импорт в археологических коллекциях представлен большим количеством материалов, отражающих торговые связи Булгарии со Средней Азией, Ближним Востоком, Византией и Закавказьем. Это, в основном, находки монет, фаянсовой посуды с люстровой росписью, поливной керамики, сфероконусов, стеклянных сосудов, изделий из цветного металла. В перечне вышеуказанных товаров уникальной является богато декорированная фаянсовая чаша из Биляра – изделие иранских мастеров XI столетия. Интересны коллекции грузинского оконного и посудного стекла, пробирных камней для определения пробы золота. Связи с Византией и её провинциями отражают находки стеклянных браслетов, поливной и стеклянной посуды. Амфоры с округлым дном и грушевидным туловом, служившие тарой для перевозки оливкового масла и вин, изготовлены в керамических мастерских Таврики и Херсона. Среди находок из раскопок имеются обломки западноевропейского витражного стекла. Такие изделия встречаются также во Владимире и Суздале, куда они попали через Волжскую Булгарию.

* * *

Волжская Булгария установила тесные и всё более расширяющиеся контакты с соседними народами Поволжья, Приуралья и далёкого Севера. В орбиту культурно-экономических и политических взаимоотношений вошли Киевская Русь и древнерусские княжества, Хазарский каганат, государства Средней Азии и арабского Востока.

Русские летописцы приводят сведения о поездке булгар в Киев в 986 г. и ответном визите делегации князя Владимира в Булгарию, когда решался вопрос о выборе веры. Под 990 г. документирована миссионерская деятельность среди булгар «Володимера философа, нарицаемого Марка Македонянина». В результате «того же лета придоша из Болгар ко [князю] Володимеру в Киев четыре князи и просветишася божественным крещением».

Торгово-экономические и дипломатические контакты нередко нару-

Русеның, соңрак рус кенәзлекләренең Киев, Новгород, Псков, Суздаль, Владимир, Рязань, Муром, Мәскәү, Ярополч Залесский, Ростов Великий, Түбән Новгород, Городец һәм башка эреле-ваклы шәһәрләрендә, Белоруссия, Украина, Молдова җирләрендә, Балтыйк буе һәм Скандинавия ил-



*И.К. Ахмадеев. Торговля булгар с северными племенами Из цикла «Ветры древних Булгар». 2003 Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*И.К. Әхмәдиев. Болгарларның Төньяк халыклары белән сәүдәсе. «Изге Болгар җилләре» циклыннан. 2003. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



***Неизвестный художник XIX века. По оригиналу XVIII века. Портрет В.Н. Татищева***

***В.Н. Татищев портреты. XIX гасырның билгесез рәссамы. XVIII гасыр оригиналы буенча ясалган***

шались военными столкновениями. В научной литературе обычно подчёркивается воинственность булгар причинявших беспокойство своими походами на древнерусские города и сёла «немалое зло их мирным жителям». Однако ещё В.Н. Татищев считал мирные связи определяющими в русско-булгарских взаимоотношениях: *«Болгоры, хотя некогда с русскими воевались, однако ж видно, что немного о том прилежали и не искали чужаго преобрести, но своё паче засчисчать старались <…> В плодах земных они преизобиловали, что неоднократно Русию во времяна недородов житами довольствовали, и более о ремёслах и купечестве прилежали»*[5]. Его слова подтверждают русские летописи. По их данным, в X – начале XIII в. киевские и владимиро-суздальские князья совершили на булгар 11 военных походов. Ответных походов было четыре.

Говоря о международных связях Волжской Булгарии с Востоком, хочется напомнить оригинальное известие персидского историка XII столетия Абу-л Хасана Бейхаки о посылке булгарским эмиром Абу Исхаком Ибрахимом ибн Мухаммадом денег и подарков в 415 г. по хиджре (1024/1025) в в Хорасан на сооружение мечетей в городах Себзеваре и Хосровджерде[6]. Скудность письменных источников вовсе не говорит об эпизодических связях булгар с Востоком. Влияние Востока чувствуется исключительно во всех областях культуры наших предков.

* * *

Город и городская культура – важнейшая составная часть мусульманской цивилизации. Расцвет караванной, речной и морской торговли в VII–VIII веках сопровождался возникновением на торговых путях городов с их своеобразной архитектурой, рыночными площадями, караван-сараями, банями и другими общественными сооружениями. Страны Ближнего Востока и Средней Азии (в частности, Хорезм) всегда отличались высокой градостроительной культурой. Эта культура через

[5] Татищев В.Н. История Российская. Т. 1. М.: Изд-во АН СССР, 1962. С. 269.

[6] Заходер Б.Н. Каспийский свод сведений о Восточной Европе. Т. II. М.: Вост. лит-ра, 1967. С. 46.

ләрендә, Венгрия һәм Бөекбританиядә болгар осталары тарафыннан ясалган югары сыйфатлы савыт-саба, барс һәм ат фигуралары рәвешендә ясалган бронза йозаклар, сөяктән эшләнгән камчы тоткалары, тараклар, алтын-көмеш бизәнү әйберләре һәм, әлбәттә инде, Болгарда сугылган көмеш акчалар табыла.

Шул ук вакытта болгар шәһәрләрендә башлыча Русьтан һәм Шәрык илләреннән, Кавказдан килгән әйберләр очрый. Урта Азия якларыннан Болгарга ефәк тукыма, фарфор, фаянс, пыяла савыт-саба, ювелир сәнгатендә кулланыла торган асылташлар, кипкән җимеш, тәмләткечләрише төрле экзотик товарлар гына түгел, кәгазь, дини һәм дөньяви эчтәлекле китаплар да килгән. Кыскасы, сәүдә гөрләп торган.

Болгарда гына түгел, барлык Европа һәм Азия шәһәрләрендә дә иң эре базарлар гадәттә шәһәр үзәгендә, мөселман илләрендә – мәчет, христиан илләрендә чиркәү тирәсендәге мәйданда, ягъни халык күп йөри торган җирдә урнашкан була.

* * *

Идел буе Болгары әле Җәгъфәр хан вакытында ук үзенең күршеләре – Идел-Урал һәм төньяктарак урнашкан өлкә халыклары белән тыгыз икътисади-мәдәни бәйләнешләр урнаштыра. Шул ук вакытта Киев Русе һәм борынгы Русь кенәзлекләре, Хәзәр каһанаты, Урта Азия һәм башка Шәрык илләре дә болгар ханнарының тышкы сәясәтендә мөһим урын алып торалар.

Рус елъязмаларында болгар ханының 986 елда Киевкә тулы бер делегация җибәрүе турында хәбәр бар. Владимир кенәзнең нинди дин кабул итәргә белмичә аптырап йөргән чагы була бу. Болгар делегациясен кабул итәләр, Владимир аларны кызыксынып тыңлый һәм Болгарга, Ислам динен һәм аның йолаларын җентекләп күреп-өйрәнеп кайтсыннар дип, үзенең делегациясен җибәрә. Безнең дин кайбер яклары белән ошап җитми Киев илчеләренә. Алай гына да түгел, 990 елда, инде алар православие динен кабул иткәч, Болгарга Марк Македонянин атлы бер миссионерның килүе турында да билгеле.

Әлбәттә, тыныч хезмәттәшлек сирәк булса да, хәрби бәрелешләр аркасында бозылып та куя. Рәсми тарих фәнендә, хәтта мәктәп дәреслекләрендә дә болгарларны сугышчан халык итеп күрсәтергә тырышалар. Имеш, алар үзләренең өзлексез яулары белән рус күршеләрен һәрдаим борчып торганнар, шәһәр-авылларын яндырып, аларга зур зыян салганнар («причиняли немало зло их мирным жителям»). Ә менә XVIII гасырның атаклы тарихчысы Василий Никитич Татищев икенчерәк төрле фикердә һәм без ул фикер чынбарлыкны чагылдыра дип саныйбыз: *«Болгары, хотя некогда с русскими воевались, однако ж видно, что немного о том прилежали и не искали чужаго преобрести, но своё паче засчисчать старались... В плодах земных они преизобиловали,*

приглашённых мастеров-строителей внедрялась и в Булгарии. Тому свидетельство – руинированные остатки кирпичных и белокаменных зданий – мечетей и общественных бань в Биляре, Суваре, Елабуге, Муромском городке и других булгарских городах.

***Город Болгар*** занимал в жизни государства исключительное положение прежде всего благодаря роли, которую он играл в международной торговле с народами Севера и Юга, Запада и Востока. В летний сезон ярмарок, когда практически каждый день в город прибывали торговые корабли по Итилю[7] и караваны верблюдов по сухопутной магистрали, их встречал сам «правитель» (эмир), как именовал Джа'фара ибн-Фадлан. Он лично принимал привезённые товары – брал себе, т. е. в государственную казну, их десятую часть.

После визита Багдадского посольства, официально признавшего Булгарию самой северной страной ислама, город приобрёл статус духовного центра мусульман Поволжья и Приуралья.

***Болгар*** – древнейший город Волго-Уралья России. Болгарское городище с сохранившимися валами и рвами располагается в Европейской части России на левом берегу Волги в 40 км южнее от места слияния ее с Камой и занимает край коренной волжской террасы, примыкает с востока к современному городу Болгар, административному центру Спасского района Республики Татарстан. Место расположения его было обжито первобытным населением края с незапамятных времён.

За более чем 150-летнюю историю археологического изучения Болгарского городища накоплен значительный источниковедческий материал по его истории. С 1864 года, когда В.Г. Тизенгаузен произвел первые разведывательные раскопки, начались планомерные исследования, продолжавшиеся в конце XIX – начале XX в., затем – в 1930–40-е гг. под руководством А.П. Смирнова, а также археологические изыскания, проводившиеся вплоть до начала XXI века учеными Казани – А.Х. Халиковым, З.А. Акчуриной, А.М. Ефимовой, Т.А. Хлебниковой, О.С. Хованской, Н.Ф. Калининым, М.Д. Полубояриновой, Н.А. Кокориной, Л.А. Беляевым, П.Н. Старостиным, Р.Ф. Шарифуллиным, В.С. Барановым, В.Ю. Ковалем, И.И. Елкиной, Р.Р. Валеевым, Д.Ю. Бадеевым, С.Г. Бочаровым, И.В. Волковым и другими, которые позволили изучить прошлое города Болгар X – начала XV века и предболгарских памятников V–VII вв. н. э. Эти значимые работы проводившиеся без перерыва многие десятилетия продолжаются и сегодня, что подкрепляет полученные ранее знания новыми фактами и создает новые об истории и культуре этого города.

Болгар в период своего возникновения размещался на стрелке мыса высокой волжской террасы. Еще до

[7] Итиль, по представлениям восточных географов: р. Белая, далее – Кама от устья Белой до впадения её в Волгу и далее – Волга до впадения её в Каспий.

*что неоднократно Русию во времяна недородов житами довольствовали, и более о ремёслах и купечестве прилежали»*[2]. Бу сүзләрне рус елъязмасындагы хәбәрләр дә раслый. Ул язмаларга караганда, X – XIII йөз башларында, ягъни монгол яуларына кадәр, рус кенәзләре Болгар җиренә 11 тапкыр яу чабалар. Елъязмаларда болгарлар ягыннан 4 яу теркәлгән.

Идел буе Болгарының Шәрык илләре белән бәйләнешләре турында сөйләгәндә, XII гасырда яшәгән фарсы тарихчысы Әбү-л Хәсән Бәйхакиның бер оригиналь хәбәрен искә төшереп үтәргә кирәктер. Ул болгар әмире Әбү Исхак Ибраһим ибн Мөхәммәтнең һиҗри буенча 415 елда (1024/1025) Хөрәсән патшасына Сәбзевар һәм Хөсрәүҗард шәһәрләрендә мәчет төзү өчен акча һәм бүләкләр җибәрүе турында яза[3].

Әлбәттә, язма чыганакларның ярлылыгы Идел буе Болгары белән Шәрык илләре арасындагы мөнәсәбәтләр эпизодик характерда гына булган икән, дип уйларга нигез бирми. Болгар бабаларыбызның мәдәни һәм матди тормышында югары дәрәҗәдәге Шәрык мәдәниятенең тәэсире нык сизелә.

* * *

Шәһәр һәм шәһәр мәдәнияте – мөселман цивилизациясенең мөһим өлеше. VII–VIII гасырларда кәрван, елга һәм диңгез сәүдәсенең чәчәк атуы үзенчәлекле архитектурасы, базар мәйданнары, кәрван-сарайлары, мунчалары һәм башка иҗтимагый корылмалары булган шәһәрләрнең нәкъ менә эре сәүдә юлларында барлыкка килүе белән үрелеп барды. Якын Көнчыгыш һәм Урта Азия илләре (аерым алганда, Хәрезем) башка өлкәләрдән һәрвакыт югары үскән шәһәр архитектурасы, төзелеш мәдәнияте белән аерылып торды. Чакырылган төзүчеләр һәм архитекторлар эшчәнлеге аша бу культура Идел буе Болгарына да үтеп керә. Моңа Биләр, Сувар, Алабуга, Муром (Мөрән?) һәм эреле-ваклы башка болгар шәһәрләрендә ачылган мәчет һәм җәмәгать мунчалары калдыклары дәлил булып тора.

***Болгар шәһәре*** дәүләт тормышында аерым урын алып торган. Беренче чиратта, әлбәттә, шул заманның иң алдынгы илләре белән халыкара сәүдәдә уйнаган роле аркасында дип уйлаучылар бар. Алай гына түгел. Багдад илчелеге шәһри Болгарны Ислам дөньясының иң ерактагы төньяк иле дип рәсми рәвештә игълан иткәннән соң, ул халыкара танылу ала һәм Идел-Урал мөселманнарының рухи үзәге статусына ия була.

Болгар Россиянең Идел-Урал төбәгендәге иң борынгы шәһәрләреннән санала. Сакланып калган үрләре һәм чокырлары белән Болгар шәһәрлеге Идел елгасының сул ярында, Кама белән кушылган урыннан 40 километр көньяктарак, Россиянең Европа өлешендә урнашкан һәм төп Идел террасасы кырыен алып тора; көн-

[2] Татищев В.Н. История Российская. Т. 1. М.: Изд-во АН СССР, 1962. С. 269.

[3] Заходер Б.Н. Каспийский свод сведений о Восточной Европе. Т. II. М.: Вост. лит-ра. 1967. С. 46.



*А.М. Радионов. Великие Булгары. Ага-Базар. 1981. Музей Болгарской цивилизации, Болгар*
*А.М. Родионов. Бөек Болгар. Ага-Базар. 1981. © Болгар цивилизациясе музее. Болгар*



*Малый Иерусалимский овраг в Болгаре – место, где найдены следы самого раннего поселения волжских булгар*

*Болгарда Кече Иерусалим чокыры. Нәкъ менә шушы җирдә болгарларның иң элгәреге торулыклары табылган*

чыгышта, хәзерге Татарстан Республикасының Спас районы административ үзәге Болгар шәһәре белән янәшә урнашкан. Аның урнашу урыны борынгы таш гасыры кешеләре тарафыннан, ягъни моннан 8–10 мең еллар чамасы элек үзләштерелә башлый. Болгар шәһәрлеген 150 елдан артык археологик өйрәнү вакытында аның тарихы буенча шактый гына материаллар тупланды. 1864 елдан соң, В.Г. Тизенхаузен беренче эзләнү казу эшләрен үткәргәч, системалы тикшеренүләр башланды, алар XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында, аннары 1930-40 елларда А.П. Смирнов җитәкчелегендә дәвам итте, шулай ук XXI гасыр башына кадәр Казан галимнәре – А.Х. Халиков, З.А. Акчурина, А.М. Ефимова, Т.А. Хлебникова, О.С. Хованская, Н.Ф. Калинин, Н.Д. Полубояринова, А.Ф. Какорина, Л.А. Беляев, П.Н. Старостин, Р.Ф. Шәрифуллин, В.С. Баранов, В.Ю. Коваль, И.И. Елкина, Р.Р. Вәлеев, Д.Ю. Бадеев, С.Г. Бочаров, И.В. Волков һ.б. тарафыннан үткәрелде, бу Болгар шәһәренең X гасырдан XV гасыр башына кадәрге үткәнен һәм V–VII гасырлардагы Болгарга кадәрге һәйкәлләрне өйрәнү мөмкинлеген бирде. Дистәләрчә еллар дәвамында өзлексез башкарылган бу мөһим эшләр бүгенге көндә дә дәвам итә, алар элек алынган ачыш нәтиҗәләрен яңа фактлар белән тулыландыралар һәм болар, үз чиратында, шәһәр тарихын һәм мәдәниятен яңа мәгълүмат белән баета. Болгар үзенең барлыкка килү чорында биек Идел террасасы борынында урнашкан булган. Шәһәр территориясендә антик чорга караган тәңкәләр дә табылды, ләкин беренче ныгытылган торулыкларның барлыкка килүе Имәнкискә археологик культурасы яшәгән чорга карый (V–VII гасырлар), алар Коптелов калкулыгында урнашкан булган. X гасырда болгарлар тарафыннан кирмән шактый киңәйтелә. Болгар эчке чокыры буйлап агач дивар белән әйләндереп алынган була. Ныгытмалар төзү белән бер үк вакытта, якын-тирәдәге киң территориядә дә кешеләр төпләнә. Табылган материаллар буенча, бүгенге көндә бу шәһәр – болгарларның торак калдыклары табылган иң



*Металлургический горн. X век. Найден в центральной части Болгарского городища. 2012*

*Тимер кою миче. X гасыр. Болгар шәһәренең үзәк өлешендә табылган. 2012 елгы казылмалар*

конца IX в., не отличалось крупными размерами. Он достигал тогда около 40 га с неукрепленными пригородами, укрепленная часть города занимала около 7 га. Однако археологическими раскопками последних лет получены новые материалы, свидетельствующие о городском характере поселения с момента его возникновения: обнаружены следы развития чёрной металлургии и кузнечного дела, гончарного и кожевенного производств.

Обнаруженные в культурном слое монеты начала X века и инструменты для их чеканки лишний раз демонстрируют значение Болгара в денежном деле и торговле страны. В этой связи вспоминаются слова академика В.Л. Янина, сказанные им более полувека тому назад, но звучащие и сегодня актуально: *«С конца VIII и до начала XI века Болгар на Волге являлся единственными воротами, через которые осуществлялась торговли Руси с Востоком»*[8].

В городе, где в сезон ярмарок собиралось огромное количество мусульманских купцов из разных стран Востока, была, конечно, и своя ме-

болгар на Коптеловом бугре уже существовали укрепления, сооруженные населением именьковской культуры (V–VII вв.). В X в. крепость была значительно расширена. Вдоль внутреннего рва Болгар был окружен деревянной стеной. Одновременно с созданием укреплений была заселена и обширная территория в непосредственной близости. Полученные материалы указывают, что этот город на сегодня самое раннее известное булгарское поселение, где обнаружены остатки их жилищ с находками, среди которых имеются дирхемы

[8] Янин В.Л. Денежно-весовые системы русского средневековья. Домонгольский период. М.: Изд-во Москов. ун-та, 1956. С. 105.

*Саманилар дирһәме. Х гасыр Наср бин-Әхмәд. Аш-Шаш. 913–936 Болгарда, Кече Иерусалм чокырының уңъяк битләвендә урнашкан элгәреге Болгар авылы хәрабәләрен казыганда табылган. П.Н. Старостин казылмалары. 1988*

*Саманидский дирхем. Х век. Наср бин Ахмед. Аш-шаш. 913–936 Найден при исследовании раннеболгарского поселения на правом берегу Малого Иерусалимского оврага в Болгаре. Раскопки П.Н. Старостина, 1988*



элгәреге (табылдыклар арасында IX гасыр ахыры дирһәмнәре дә бар) ул чакта әллә ни зур булмаган торак пункты. Шул чорда ул бистәләре белән 40 гектарга якын җирне биләп торган, шәһәрнең ныгытылган өлеше якынча 7 гектар. Әмма соңгы еллардагы археологик казулар нәтиҗәсендә әлеге торулыкның шәһәр характерында булуы турында дәлилләүче яңа материаллар табылды: казылмалардан кара металлургия һәм тимерчелек эше, чүлмәк һәм күн җитештерү белән бәйле табылдыклар килеп чыкты.

Х гасыр башында тупланган культура катламында сакланып калган көмеш тәңкәләр һәм шул тәңкәләрне сукканда кулланыла торган инструментлар Болгарның ил сәүдәсендә тоткан әһәмиятен тагын бер кат күрсәтә. Бу уңайдан академик В.Л. Янинның ярты гасыр элек әйткән, һәм бүген дә гадел, дөрес яңгыраган сүзләре искә төшә: *«VIII гасыр азагыннан алып XI гасыр башына кадәр Идел Болгары Русь белән Көнчыгыш сәүдәсендә бердәнбер капка ролен башкарып килгән» («С конца VIII и до начала XI века Болгар на Волге являлся единственными воротами, через которые осуществлялась торговля Руси с Востоком»)*[4].

Ярминкәләр сезонында Көнчыгышның төрле илләреннән күпсанлы мөселман сәүдәгәрләре җыелган шәһәрдә, әлбәттә, аның үз мәчете дә булгандыр. Бу хакта, аерым алганда, Ибн Фадланның без югарыда телгә алган азан алдыннан әйтелә торган камәтне ике тапкыр кабатларга ярамавы турында кисәтүе дә сөйли. Кызганычка каршы, әлеге мәчетнең эзләре табылмаган, хәер, ул эзләрне саклаган борынгы катламнар соңгы еллардагы төзелеш эшләре вакытында юкка чыккандыр инде. Борынгы мәчетнең Алтын Урда чорындагы Җәмигъ мәчете урынында торуы да ихтимал.

Урта гасыр Болгары үзенең төрле халыклары белән аерылып торган. Бу этник төрлелек шул чорның күп чыганакларында искә алына. Мәсәлән, Ибн Фадланны чит ил сәүдәгәрләре – норманнарның гыйбадәт кылу һәм бигрәк тә аларның бер юлбашчысы үлгәч, җеназа, ягъни соңгы юлга озату йоласы – бүләкләр һәм искә алу корбаннары белән көймәдә яндыру күренеше гаҗәпләндергән. XIX гасыр ахырында Балымер авылы

[4] Янин В.Л. Денежно-весовые системы русского средневековья. Домонгольский период. М.: Изд-во Москов. Ун-та, 1956. С. 105.

четь. Об этом свидетельствует, в частности, вышеупомянутое замечание ибн Фадлана о недопустимости двукратной икамы при провозглашении азана с минарета мечети, высказанное им практически на второй день пребывания в Болгаре. К сожалению, следы этой мечети пока не выявлены, что, впрочем, вполне объяснимо – древнейшие слои, содержащие остатки сооружений, обычно уничтожаются при последующих строительных работах. Не исключено, что древнейшая мечеть стояла на месте Соборной мечети золотоордынского времени, остатки которой сохранились до наших дней и представляют собою одну из достопримечательностей города.

Средневековый Болгар выделялся полиэтническим составом населения. Этническое многообразие отмечено во многих источниках того времени. Так, сохранилось описанное Ибн Фадланом моление иноземных купцов-русов норманов и особенно поразивший его обряд похорон одного из их предводителей сожжением его с дарами и поминальными жертвами в ладье. С этими событиями связаны раскопанные в конце XIX в. курганы около с. Балымеры с варяжскими захоронениями, расположенные недалеко от Болгар.

Город посещали многочисленные мусульманские купцы из стран Востока – Мерва, Нишапура, Хорезма и др., древнерусских княжеств, Западной Европы. И каждый из них в этом гостеприимном и радушном городе находил свои торгово-экономические интересы: меха и серебро, ювелирные и кожевенные изделия и многие другие товары. Активное развитие Болгара как крупного международного торгового ярмарочного центра, соединившего Запад и Восток, Север и Юг, являвшегося ключевым центром на северном отрезке Великого Шелкового пути, преемственно перешло в XV в. к Казани.

Занимая исключительно важный район Евразии, расположенный на пересечении торгово-экономических, культурных и политических коммуникаций, с момента возникновения Болгар стал необходимым связующим звеном в цивилизационных контактах между Востоком и Западом, Севером и Югом, оседлыми и кочевыми культурами, между мирами Леса и Степи. Результатом этих процессов стало создание неповторимого облика традиционной культуры, отразившегося в развитии хозяйства, технологий, градостроительства, архитектуры, монументального и прикладного искусства, духовной культуры региона.

***Биляр (Буляр)*** принадлежал к числу городов-гигантов средневековой Евразии. Он был хорошо укреплён – накануне монголо-татарских завоеваний имел пять линий оборонительных стен общей протяжённостью около 40 км. Территория города составляла около 80 га. Во внутреннем городе располагалась ограждённая деревянной стеной резиденция правителя, а за её пределами жили богатые феодалы, торговцы и ремесленники. При помощи аэро-

янында Болгардан ерак түгел табылган варяг каберлекләре белән курганнар шушы вакыйгалар белән бәйле.

Шәһәргә Шәрык илләреннән – Мәрв, Нишапур, Хәрәзем һ.б., рус кенәзлекләреннән, Көнбатыш Европадан күп санлы сәүдәгәрләр килгән. Аларның һәркайсы бу кунакчыл шәһәрдә үзенең сәүдә-икътисадый мәнфәгатьләрен: тире һәм көмеш, зәркән һәм күн әйберләре һәм башка бик күп товарлар тапкан. Актив үсештә булган һәм Көнбатыш һәм Көнчыгышны, Төньяк һәм Көньякны тоташтыручы Болгарның зур халыкара сәүдә ярминкә мәркәзе һәм Бөек Ефәк юлының төньяк өлешендәге төп үзәк роле XV гасырда Казанга күчә.

Евразиянең сәүдә-икътисади, мәдәни һәм сәяси коммуникацияләре кисешкән урында урнашкан аеруча мөһим төбәкне биләүче Болгар, барлыкка килгәннән бирле, Көнчыгыш һәм Көнбатыш, Төньяк һәм Көньяк, утрак һәм күчмә мәдәниятләр, Урман һәм Дала дөньялары арасындагы цивилизация элемтәләрендә тоташтыручы мөһим звенога әйләнде. Әлеге процессларның нәтиҗәсе – традицион мәдәниятнең кабатланмас йөзе барлыкка килүе. Ул хуҗалык, технологияләр, шәһәр төзелеше, архитектура, монументаль һәм гамәли сәнгать, төбәкнең рухи мәдәнияте үсешендә чагыла.

***Биләр*** – Идел буе Болгарының иң зур шәһәре. Шәһәрнең мәйданы якынча 80 гектар тәшкил иткән. Аның рус елъязмаларында теркәлеп калган атамасы – Олуг шәһәр (Великий город). Олуг шәһәргә нисбәтле язмалар шул елъязмалар сакланып калган.

1164 нче елда Владимир-Суздаль кенәзе Ярослав һәм Муром кенәзе Юрий Болгар иленә яу чаба. *«Урыслар болгарларны җиңделәр, әләмнәрен кулга төшерделәр, болгар ханы үзенең дружинасы белән Олуг шәһәргә кереп бикләнде, ә урыслар, кайтышлый, болгарларның Ибраһим (Бряхимов) шәһәрен һәм тагын берничә шәһәрне сугышып алдылар»*, – дип хәбәр итә Лаврентий елъязмасы.

1183 нче елда Владимир кенәзе Всеволод Зур Оя Болгар иленә яу оештыра. Аның күпсанлы гаскәре Киев, Чернигов, Переяславль, Смоленск, Муром һәм Рязань җирләреннән килгән хәрби дружинаны берләштерә. Бу гаскәр, Идел буйлап төшеп, Кама ягына керә, ике көн буена Тухчин шәһәрен камап торганнан соң, өченче көнне Олуг шәһәргә юнәлә. Ул Олуг шәһәрне ун көн буе камалышта тота, әмма шәһәр халкы бирешми. Шуннан соң ул, болгарлар белән солых төзеп, кире кайтып китәргә мәҗбүр була.

1220 нче елда рус елъязмачылары Святослав исемле кенәзнең Ашлы (Ошель) шәһәренә ясаган һөҗүме турында язалар. Әлеге яу вакытында Ашлы бик нык җимертелә, яндырыла. Бу хәбәр Олуг шәһәргә соңлап кына килеп җитә һәм шуңа күрә болгар патшасы тарафыннан җибәрелгән ярдәм дә нәтиҗәле булмый.

Биләр-Олуг шәһәр турында урыс елъязмаларында тагын ике хәбәр бар



*Ф.Г. Халиков. Биляр. Реконструкция застройки*
*Ф.Г. Халиков. Биләр. Борынгы күренешен күзаллау*

фотосъёмок здесь зафиксированы следы более 30 кирпичных зданий, намечены древние улицы, площади, водоёмы.

В центре города располагалась Соборная мечеть. Она состояла из двух частей – деревянной и белокаменной, с большим отдельно стоящим минаретом. Внутри белокаменной части прослежены остатки 24 колонн, расположенных симметрично в шесть рядов. Фасадная часть здания была красиво оформлена пилястровыми выступами-полуколоннами.

Рядом с мечетью стояло кирпичное здание. В основании его фундамента имеется антисейсмическая подушка из сырцовых кирпичей, характерная для архитектурной традиции Ближнего Востока и Средней Азии. Функциональное назначение здания окончательно не выяснено. Оно может оказаться жилым домом высшего духовного лица, например, имама рядом расположенной мечети, или общественной баней, на что намекает подпольная отопительная система, характерная для такого рода сооружений.

Напротив мечети, с восточной стороны, в первой половине X столетия возникло небольшое мусульманское

һәм аларның икесе дә монгол яуларына нисбәтле.

Болгарлар тарафыннан 1223 нче һәм 1229 нчы елгы җиңелүләрдән соң, монголлар 1232 нче елда янәдән Болгар иленә үтеп керәләр, әмма *«Олуг шәһәргә килеп җитә алмыйча, кышларга мәҗбүр булалар»*.

Соңгы мәртәбә Олуг шәһәр рус елъязмаларында 1236 елгы канлы вакыйгалар уңаеннан телгә алына.

Биләр археологик экспедициясе тарафыннан шәһәрлектә архитектура истәлекләре ачылды, әллә никадәр йорт һәм хуҗалык корылмалары, яхшы гына сакланган коелар, төрле һөнәр ияләренең остаханәләре, саклану ныгытмалары казып тикшерелде.

Эчке шәһәрдә тикшерелгән гади генә агач йортлар арасында иң кызыклысы – XII гасыр ахырларына караган һөнәрче остаханәсе. Биредә патша һәм бай түрәләр заказы белән кыйммәтле бизәнү әйберләре ясаучы бер оста яшәгән. Бу йорт урынын казыган вакытта 6 килограммнан артык эшкәртелмәгән гәрәбә кисәкләре, алтын-көмештән, сөяктән һәм гәрәбәдән ясалган бизәнү әйберләре, пыяла савыт ватыклары, үлчәү тәлинкәләре һәм герләре табылды. Сирәк очрый торган әйберләр исемлегендә 1222–1224 нче елларда хакимлек иткән Новгород кенәзе Всеволод Юрьевичның кургаштан коелган мөһере бар. Бу мөһер 1183 нче елда Олуг шәһәргә һөҗүм оештырган Всеволод Зур Ояның үзенеке дә булуы мөмкин дип фаразлана. Биредә яшәгән һөнәрче килеп чыгышы буенча болгар түгел, ә урыс кешесе булган.

Тышкы шәһәрдә башлыча уртакул һәм ярлы һөнәрчеләр, вак сәүдәгәрләр, әле җирдән-авылдан аерылып җитмәгән кичәге игенчеләр, терлекчеләр көн күргән. Чүлмәкчеләрнең остаханәләре, савыт-саба яндыру мичләре урнашкан бистә 3 гектарга якын җирне биләп торган! Казу эшләре вакытында табып тикшерелгән ике катлы чүлмәк яндыру мичләре үзләренең камиллеге белән аерылып торалар.

Тышкы шәһәрдән эчке шәһәргә үтә торган Көнчыгыш капкасы тирәсендә шартлы рәвештә «кәрван-сарай» дип аталган зур гына кирпеч бина калдыклары сакланган. Гомуми мәйданы 240 квадрат метр чамасы (16×15 м). Бүлмәләре идән астындагы каналлар буйлап килүче кайнар һава белән җылытылган. Бина X гасыр ахырында төзелгән. Әле күптән түгел генә, биредә чит илләрдән сату-алу эшләре белән килгән сәүдәгәрләр өчен кунакханә урнашкан, дип фаразлана иде. Чынлыкта исә бу бина кәрван-сарай комплексына караган мунча булган.

Биләрдә, 1973 елгы аэрофото материалларына таянып, 30 дан артык кирпеч бина урыны ачыкланган. Әлеге тарихи һәйкәлдә казу эшләре дәвам итә.

***Сувар*** Болгар иленең иң атаклы тарихи һәйкәлләре исемлегендә урын алган, шуңа күрә аны еш кына шәһри Болгар белән янәшә куеп телгә алалар. Ул хәзерге Спас районының Кузнечиха авылыннан дүрт чакрым ераклыкта урнашкан. Харәбәләре



*Р.М. Вахитов. Медресе. 1998*
*Р.М. Вахитов. Мәдрәсә. 1998*

кладбище. Расположение его в центральной части города, прямо перед мечетью, наличие наземных погребальных сооружений в виде тюрбе, сложенных из хорошо обожжённых кирпичей, парных захоронений в них (семейных склепов) – указывают на социальную привилегированность погребённых.

В центральной части Биляра исследованы жилища рядовых горожан и хозяйственные постройки вокруг них. В амбарах-клетях выявлены большие скопления (иногда до 50 килограммов) обугленных зёрен пшеницы, проса, гороха, ячменя, в погребах – зёрна и семена малины, яблока, других фруктовых культур, косточки вишни и лесного ореха, скопления яичной скорлупы, костей и чешуи рыб.

Внешний город был заселён ремесленниками и мелкими торговцами, но здесь же находились усадьбы состоятельных горожан и караван-сараи для приезжих купцов. Следы ремесленного производства выявлены как во внутреннем, так и во внешнем городе.

К числу исторически известных городов, свидетельствующих о богатой и многогранной истории некогда процветавшего средневекового культурного пространства волжских

4,5 чакрым озынлыктагы балчык үрләрдән һәм тирән чокырлардан торган ныгытмалар белән уратып алынган турыпочмаклы шәһәрлектән гыйбарәт. Борынгы кала 90 гектар мәйданны биләгән. Баштан ук ул сувар-савир исемле эре кабилә берләшмәсенең – Сувар билегенең (әмирлегенең) үзәге, башкаласы сыйфатында төзелә. Шуңа күрә дә биредә Шәрык илләреннән килгән сәүдәгәрләр, сәяхәтчеләр еш булганнар. Суварны алар үзләренең язмаларында телгә алалар. Мәсәлән, гарәп географы әл-Балхи хезмәтендә, Сувар – зур шәһәр, аның үзәк мәйданында Җәмигъ мәчете урнашкан, халык саны 10 меңгә җитә, дигән хәбәр бар. Моңа охшаш юлларны әл-Җәйхани, әл-Истахри язмаларыннан да табарга мөмкин.



*Сувар. Графическая реконструкция оборонительной линии города (по А.П. Смирнову)*

*Сувар шәһәренең саклану корылмалары. Реконструкция (А.П. Смирнов буенча)*

Шунысы гаҗәп: Болгар иленә 1135 елда ерак Андалузиядән (Испаниядән) килеп, озак кына торып киткән Әбү Хәмид әл-Гарнати үзенең китабында, нишләптер, Суварны телгә дә алмый. Рус елъязмаларында да аның турында бер кәлимә сүз юк.

Сувар билегенең X йөздәге сәяси тормышын өйрәнүдә нумизматика материаллары да мөһим роль уйный. Галимнәр болгар акчалары арасыннан Сувар әмирләре Талиб ибн Әхмәт һәм Мөэмин ибн Әхмәт тарафыннан 948–976 елларда сугылган көмеш тәңкәләрне аерып алдылар. Нумизматика материаллары күрсәткәнчә, Сувар X йөз ахырына кадәр мөстәкыйль, ягъни Болгарга буйсынмыйча яшәүче суверен билек (әмирлек) булган.

Шәһәр ныгытмалары биек үрләр өстендә 4×5 метр үлчәмдәге бураларны бер-берсенә ялгап төзелгән стеналар рәвешендә булган. Араларын 100–120 метр калдырып, биек башнялар корылган. Бу ныгытмаларның буеннан буена, тышкы яктан, тирәнлеге 5 метрга җитә торган чокыр казылып, төбенә очлы казыклар кагып куелган. Шәһәрлекнең үзәгендә кирпеч бина калдыклары («Сувар сарае») һәм аның белән бәйле корылмалар тикшерелә; саклау ныгытмалары конструкцияләре ачыклана, шәһәрнең ике некрополендә мөселман каберлекләре өйрәнелә.

***Ашлы*** – Иделнең уң як ярында урнашкан Болгар шәһәре. Хәзерге вакытта аның археологик калдыклары Татарстанның Тәтеш районы Богдашкино авылыннан төньякта ур-

булгар, принадлежит и ***Сувар***, остатки которого находятся в 70 км к западу от Болгара. Богатый и цветущий город с населением 10 тысяч человек (по сведениям ал-Балхи) имел соборную мечеть и даже чеканил свои монеты. Достоверно определены монеты двух суварских эмиров – Талиба ибн Ахмеда и Мумина ибн Ахмеда, чеканенные в 948–976 годах. Основываясь на этих данных полагают, что Сувар с момента своего возникновения являлся столицей обособленного княжества, потерявшего самостоятельность лишь в конце X столетия.

Остатки Сувара представляют собой городище площадью около 90 га, окружённое мощными валами и рвами протяжённостью около 4,5 км. В центре городища исследовались остатки кирпичного здания («суварский дворец») и связанных с ним сооружений; тщательно выявлялись конструкции оборонительных укреплений, изучались мусульманские захоронения на двух городских некрополях.

***Ошель*** – булгарский город, расположенный на правом берегу Волги. В настоящее время его археологические остатки локализуют на месте городища площадью около 77 га, расположенного к северу от села Богдашкино Тетюшского района РТ. Ошель единственный раз упоминается в русских летописях под 1220 годом в связи с походом владимиро-суздальского князя Святослава на волжских булгар, когда он был взят штурмом и сожжён дотла. Древний город ждёт своих исследователей.

***Муромский городок*** – крупнейший после Биляра памятник археологии домонгольских булгар. Он расположен на Самарской Луке, южной границе государства. Площадь города достигает 400 га. Раскопками выявлены руины четырёх кирпичных зданий, бревенчатые и глинобитные жилища рядовых горожан, производственные сооружения, в том числе несколько медеплавильных печей,



*Муромский городок. Реконструкция застройки*
*Муром (Мөрэн?) шәһәре. График реконструкция*

нашкан 77 гектар мәйданлы шәһәрлек урынында дип фаразлана. Ашлы рус елъязмаларында, Владимир-Суздаль кенәзенең Идел болгарларына 1220 елда чапкан яуларына бәйле рәвештә, беренче һәм соңгы тапкыр телгә алына. Бу һөҗүм вакытында Ашлыны бик каты талыйлар, яндыралар һәм җимерәләр. Шәһәр яңадан торгызылмый.

Шәһәр археологик яктан өйрәнелмәгән диярлек. Ул үзенең тикшерүчеләрен көтә.

***Муром шәһәрлеге*** – Биләрдән соң болгар тарихының монголларга кадәрге чорга караган иң зур археология һәйкәле. Ул Самара өлкәседә, Болгар дәүләтенең көньяк чигендә урнашкан. Шәһәрнең мәйданы 400 гектардан артыграк. Тарихи исеме билгеле түгел. Мөрән булмадымы икән? дип уйлаучылар бар (А.Х. Халиков), әмма тәгаенләп әйтүе кыен. Археологик казу эшләре вакытында дүрт кирпеч бинаның харәбәләре, гади шәһәр кешеләренең торак йортлары, җитештерү корылмалары (һөнәрчелек остаханәләре), шул исәптән берничә бакыр эретү һәм чүлмәк яндыру мичләре, тимерче алачыклары тикшерелде. Муром шәһәрлеге – бай шәһәр, болгарларның хәзерге Самара төбәгендә яшәгән зур гына бер төркеме өчен административ үзәк булып хезмәт иткән. Монгол явы вакытында яндырыла һәм яңадан торгызылмый.

Идел буе Болгарының шактый зур шәһәрләре исемлегенә шулай ук X–XI гасыр чигендә, дәүләтнең төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләрендәге форпостлар, Кашан, Кирмән, Алабуга һәм тарихи исемнәре язма чыганакларда телгә алынмаган башка шәһәрләр керә. Болгар дәүләте чикләреннән тышта, Иделнең түбән агымы төбәгендә, кыпчаклар яши торган өлкәдә, урта гасыр сәяхәтчеләре ***Саксин*** дигән шәһәрне еш телгә алалар. Әбү Хәмид әл-Гарнати, мәсәлән, шул Саксинда күп төрле халыклар, алар арасында сәүдәгәрләр, дәрәҗәле мөселман укымышлылары яшәүләрен сөйли. *«Шәһәрнең нәкъ уртасында,* – ди ул, – *болгар кешеләренең әмире тора, аларның үз Җәмигъ мәчете бар, анда җомга намазы укыйлар, аның тирәсендә болгарлар яши. Ул халыклардан һәркайсының үз казыйлары, фәкыйһләре, хатиблары бар»*[5].

Идел болгарларының хәзерге Пермь өлкәсендә ***Афкула*** исемле шәһәре билгеле. Аның харәбәләре (Рождественск шәһәрлеге) соңгы елларда археологлар тарафыннан яхшы өйрәнелде. Шәһәр янында мөселман зираты урнашкан. Афкула борынгы коми-пермяклар җирендә болгарларның сәүдә факториясе ролен үтәгән. Биредә, әлбәттә, һөнәрчеләр дә яшәгән. Шәһәрнең бер почмагында болгарларның чүлмәк яндыру мичләре казып тикшерелгән.

*«Болгарлар – шәһәр төзелешендә дан яулаган халык»*, дип язуы белән «рус тарихының атасы»

[5] Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.) / Публикация О.Г. Большакова, А.Л. Монгайта. М.: Изд-во «Вост. лит-ра», 1971. С. 27.




*Болгарский поэт Кул Гали*
*Скульптурный портрет Б. Урманче*

*Б.И. Урманче. Болгар шагыйре Кол Гали. 1965*
*© Татарстан Республикасы Милли музее. Казан*

гончарные горны, кузницы. Новые исследования характеризуют памятник как один из крупнейших городов домонгольской Булгарии, погибший во время монгольского нашествия 1236 г.

К числу значительных городов Волжской Булгарии относятся также Казань и Елабуга, возникшие на рубеже X–XI вв. как форпосты-крепости на северной и северо-восточной границах государства, Кашан, Керменчук и десятки других, названия которых не сохранились в источниках.

Прав был один из первых русских историков В.Н. Татищев, писавший, что «булгары – народ, в строении градов преславный».

* * *

С принятием ислама в Волжской Булгарии произошли кардинальные изменения в сфере идеологии и культуры. Примечательно, что в литературе закрепился северный облик описания региона в мусульманской культуре, представленный с учетом климатических особенностей этой зоны в символическом образе – ислам на снегу. Сложилась качественно новая мусульманская культура, сочетающая традиции мусульманского градостроительства и местные особенности, обусловленные и природными условиями. Архитектура и система просвещения, наука и литература, метрология и система счёта, календарь и счёт времени, одежда, обряды и обычаи, другие стороны материальной и духовной культуры населения – все они пронизаны мусульманскими традициями и свидетельствуют о глубоком проникновении ислама во все сферы жизни населения.

Ислам – религия с развитой письменной культурой, с богатейшей литературой философского и религиозного содержания. С принятием новой религии арабская письменность проникла и в Волжскую Булгарию, она полностью вытеснила старую тюркскую рунику и практически до 1927 года – в течение более тысячи лет! – исправно служила татарской культуре. Грамотность была уделом не только аристократии; читать и писать умели и простые горожане. Не удивительно, что татары, потомки булгар, и в конце XIX века отличались среди

Василий Татищев, һичшиксез, хаклы була.

* * *

Ислам динен кабул итү белән Идел буе Болгары, үзенең мәдәни дөньясында, идеологиясендә кискен үзгәрешләр кичереп, Ислам таралуның иң төньяк төбәгенә әверелә.

Мөселман мәдәниятендә илнең төньяк образы буларак әдәбиятта чагылыш табуы юкка түгел, чөнки төбәкнең климат үзенчәлекләрен исәпкә алсак, күз алдына карда гәүдәләнгән Ислам символик күренеше килеп баса. Мөселман шәһәр төзелеше традицияләрен һәм шушы төбәккә хас үзенчәлекле табигать шартларын берләштергән, моңарчы булмаган-күрелмәгән бөтенләй яңа мөселман мәдәнияте барлыкка килә. Архитектура һәм мәгариф системасы, әдәбият һәм фән, метрология һәм санау системасы, календарь, гореф-гадәтләр һәм йолалар, киемнәр, халыкның рухи һәм матди мәдәнияте – барысы да тирән үзгәреш кичерә һәм бу үзгәрешләр мөселман кануннарының, тәртип һәм кагыйдәләренең яшәешнең бөтен өлкәләренә тирән үтеп керүе турында сөйли.

Ислам – югары үскән язмачылык традицияләре, тирән фәлсәфә белән сугарылган бай әдәбияты булган дин. Яңа дин кабул ителгәннән соң, болгарларга тиз арада гарәп язуы үтеп керә һәм ул, гарәп графикасы, борынгы руниканы кысып чыгарып, болгар-татар мәдәниятенә 1927 елга кадәр – мең елдан артыграк дәвер буена! – хезмәт итә.

Болгарларда укый-яза белү – грамоталылык югары катлау кешеләре, байлар арасында гына таралган нәрсә түгел. Гади халык та, бигрәк тә шәһәр халкы, белемле булган. Болгарларның варислары булган татарларның хәтта Россия империясе составында да, XIX гасыр ахырында, башка милләт вәкилләренә караганда күпкә мәгърифәтле булуы бер дә гаҗәеп хәл түгел.

Болгар иле, беренче чиратта, мөселман Көнчыгышы илләре белән халыкара икътисади һәм мәдәни мөнәсәбәтләр урнаштыра. Тора-бара гарәп теле, болгар теле белән беррәттән болгар фәне һәм дипломатик язышу теленә әверелә, ә фарсы теле, Идел буе төрки теле белән беррәттән болгар шигърияте теле булып китә. Көнчыгыш илләре белән сәүдә һәм икътисади элемтәләрнең ныгуы Болгар мәгариф системасында да гарәп язуының киң таралуына китерә. Идел буе Болгарында һәм Алтын Урдада төп язу материалы ерак Кытайдан һәм Сәмәркандтан китерелгән кәгазь булган.

Ислам һәм аның тәгълиматы, өйрәтмәләре уку-язуны яхшы белгән кешеләргә исәпләнгән, Коръәнне һәм мөселман хокукын яхшы үзләштергән затларга мохтаҗ булган. Шуңа күрә, яңа дингә көчү белән, шәһәр-авылларда мәчетләр ачыла, ә мәчетләр үзләренең мәктәп-мәдрәсәләрен булдыру ягын карыйлар. Ул мәдрәсәләрдә, беренче чиратта, әлбәттә, дин әһелләре әзерлиләр, әмма, дини предметлардан



***Рукописный список XIX века поэмы Кул Гали «Кыйсса-и Йосыф» («Сказание о Йусуфе»)***
***Кол Гали. «Кыйсса-и Йосыф» поэмасының XIX гасыр кульязмасы***

других народов Российской империи высокой степенью грамотности.

Волжская Болгария активно выстраивала международные экономические и культурные связи – прежде всего со странами мусульманского Востока. Постепенно арабский язык наряду с болгарским становится языком болгарской науки и дипломатической переписки, а фарси (персидский) наряду с поволжским тюрки – языком болгарской поэзии. Усиление торговых и экономических связей со странами Востока привело к распространению арабской письменности и в системе образования. Основным материалом письменности в Волжской Болгарии и Золотой Орде служила бумага, привозимая из далекого Китая и Самарканда.

Ислам и его учение требовали просвещённых людей, знатоков Корана и мусульманского права. Вместе с новым учением при мечетях появились образовательные центры – мектебе и медресе. В них обучали чтению и письму, готовили главным образом религиозных служителей, но кроме богословских предметов преподавали также основы математики, географии, истории, астрономии, медицины, необходимые в повседневной жизни. Создавались условия для продолжения обучения способной молодёжи в крупнейших культурных центрах Востока: Бухаре, Мерве, Мосуле, Багдаде и др.

Ислам придал новый импульс ускоренному развитию болгарской науки и культуры в целом. На рубеже XI–XII вв. в Болгарии жил ученый – историк, главный судья Якуб ибн Нугман, автор книги «История Болгарии», которую высоко оценил арабский путешественник из Испании, географ Абу-Хамид аль Гарнати (аль Андалуси), посетивший великий город в 1135 г. Болгаро-татарская просвещенность пользовалась настолько высоким авторитетом и признанием, что ученый Ходжа Ахмед Болгари в XI в. был назначен на пост учителя и наставника одного из могущественных монархов мира – султана Махмуда Газневи, подчинившего Среднюю Азию и Иран. Недаром Болгарию называли «царством разума» и «золотым троном Востока». Переехав из Болгарии в Афганистан, Ходжа Ахмед Болгари врачевал в городе Газни. Он прославился своими философскими и историческими

башка, көндәлек тормышта кирәк булган математика, тыйб (медицина), тарих, география, астрономия кебек дөньяви фәннәрне дә укыталар. Сәләтле яшьләрне гадәттә белем эстәргә Шәрыкның Бохара, Мәрв, Багдадише эре фән һәм мәдәният үзәкләренә җибәрә торган булалар.

Ислам дине Болгар фәнен һәм мәдәниятен үстерүгә яңа этәргеч булды. XI–XII гасырларда яшәгән Йакуб ибн Ногман исеме безгә Андалусиядән (Көньяк Испания) Болгарга килгән сәүдәгәр һәм сәяхәтче Әбү Хәмид әл-Гарнатиның 1155 елда язылган бер әсәре аша билгеле. Ул 1135 елда Болгарда булып китә. Йакуб ибн Ногманның «Болгар тарихы» әсәрен ул үзе укыган. Моңа кадәр инде без Шәрык илләрендә заманында бик популяр булган Хуҗа Әхмәт Болгари исемле бер легендар табипны белә идек. Ул – атаклы солтан Мәхмүт Газнәвинең (967–1030) укытучысы. Әхмәт Болгари «Әл-җәмигъ», «Әт-тарика», «Әл-фәваид» исемле әсәрләре белән бөтен Көнчыгыш илләрендә танылган олы галим булган. Шунысы гаҗәп, Әхмәт Болгариның исеме әле бүген дә онытылмаган: 1971 елда Әфганстанда аның кабере өстенә ак мәрмәрдән мавзолей – төрбә салып куйганнар.

Урта гасыр язма чыганакларында фәннең төрле тармакларында эшли торган, мөселман дөньясында дан-шөһрәт казанган болгар галимнәренең исемнәре сакланып калган. Мәсәлән, күптән түгел безгә фармакология өлкәсендә атаклы белгеч *Таҗетдин ибн Юныс әл-Болгари*ның «Олы тирйак» («Агулануга каршы дару») исемле кулъязмасы билгеле булды. 1220–1221 елларда язылган бу хезмәт Тәһранда, Иранның Сенат китапханәсендә саклана.

Идел буе Болгарында иң популяр һәм, аңлашыла ки, иң күп укыла торган әсәрләр – дини трактатлар. Шәрык илләрендә болгар галимнәре *Борһанетдин әл-Болгари* һәм *Әбү-Хәмид ибн Идрис әл-Болгари*ның дини-дидактик характердагы фәлсәфи әсәрләрен яхшы белгәннәр.

*Сөләйман ибн Дауд ас-Саксини ас-Сувари* атлы болгар галименең һәм ул язган кайбер әсәрләрнең исеме әле Шиһабетдин Мәрҗанигә үк билгеле булган. Күптән түгел Стамбулның Сөләймания китапханәсендә аның суфичылык фәлсәфәсенә багышланган сигез кулъязмасы табылды. Алар арасында эшләнеше ягыннан иң камиле һәм кызыклысы – «Зүһрәт әр-рийад вә нөзһәт әл-колүб әл-ми-




***Памятный камень, посвящённый Кул Гали на Аллее поэтов и учёных в Музейном парке Болгара***

***Кол Галигә багышланган истәлек ташы Болгар, Музей паркы, шагыйрьләр һәм галимнәр аллеясы.***

трактатами. Среди них наибольшей известностью пользовались «Тарихател Болгария» («История Болгарии»), «Фэнандел Болгария» («Наука в Болгарии»), «Жэмигыль Болгария» («Философия Болгарии»). В 1971 г. над его могилой был построен мавзолей (дюрбе) из белого мрамора. Высокий уровень мусульманской городской культуры обусловил активную деятельность и других педагогов, ученых. Во второй половине XI – начале XII в. здесь жил и творил философ и историк Хамид бин Идриси аль-Болгари, в первой половине XII в. – историк Якуб бин Нугман аль-Болгари, богослов Сулейман бин Давуд аль-Саксини (XI–XII вв.), фармакологи Ходжа аль-Болгари (XI–XII вв.), братья Таджддин и Хасан бин Юныс (XIII в.). Имя и названия некоторых произведений булгарского учёного Сулаймана ибн Дауда ас-Саксини ас-Сувари (XII в.) были запечатлены в трудах Шигабутдина Марджани. Недавно в библиотеке Сулеймания в Стамбуле удалось обнаружить восемь рукописей с его сочинениями по философии суфизма. Наиболее интересным и совершенным из них является «Зухрат ар-рийад ва нузхат ал-кулуб ал-мирад» – «Красота садов и утешение страдающих сердец». В первой половине XIV в. жил известный мусульманский законовед Бурхан-ад-дин Ибрахим альХанафи, автор книги «Основы дискуссий».

Основоположником булгаро-татарской письменной литературы по праву считается Кул Гали (ок. 1183–1236). Его поэма «Кысса-и Йусуф», где творчески использован библейско-коранический сюжет о Иосифе Прекрасном и жене Потифара Пентефрии, является жемчужиной булгарской литературы. В поэме отражена многовековая вера простого народа в хорошего царя и мечты об идеальном обществе. «Кысса-и Йусуф» – классическое произведение мусульманской культуры, которому присущи переплетения идей гуманизма с философией суфизма. Приверженность поэта к идеям суфизма нашла отражение и в его имени с излюбленной приставкой суфиев *кул/кол* – «раб (Божий)».

В Великом Болгаре несли свет знаний многочисленные исламские учебные заведения, в мечетях проповедовали знаменитые богословы, философы, мыслители писали научные трактаты, а поэты создавали свои замечательные произведения. И сегодня далеко за пределами России известны имена болгарских ученых по медицине, астрономии, математике, другим наукам. Сведения о передвижении религиозных проповедников-суфиев, указания на происхождение целого ряда видных богословов, правоведов и медиков из городов Волжской Булгарии, достигших признания во всем мусульманском мире, отмечены в трактатах авторов разных стран. К сожалению, из многих ярких имен булгарских деятелей культуры сохранились свидетельства только о немногих средневековых ученых и писателях.

рад» («Авыру күңелләрне сөендерүче бакча чәчәге») исемле әсәр. XIV йөзнең беренче яртысында танылган канун белгече, «Фикер алышу нигезләре» китабы авторы Борһан-эд-Дин Ибраһим әл-Хәнәфи яшәгән.

*Кол Гали* (1183–1236?) хаклы рәвештә болгар-татар язма әдәбиятына нигез салучы булып санала. Ул, «Кыйсса-и Йосыф» поэмасын язганда, Фирдәүсинең «Йосыф вә Зөләйха» исемле әсәрен, шул заманның башка шагыйрьләре әсәрләрен иҗади кулланган. Кол Галинең әлеге поэмасы монголларга кадәрге чордагы болгар әдәбиятының йөзек кашы булып тора.

Поэманың нигезендә Якын Көнчыгыш халыкларының мифологиясендә тирән тамыр җәйгән гүзәл Йосыф турындагы «Тәүрат» риваяте ята. Җәмгыятьнең түбән катлавыннан чыккан һәм башыннан үткән сынаулардан соң, Мисыр җиренең хакименә әверелгән егет турында бәян итеп, Кол Гали идеаль дәүләт һәм идеаль идарәче образын сурәтли. Шагыйрь илнең һәм халыкның иминлеген хакимнең әхлакый камиллегендә, тирән акылында, гаделлегендә, тигезлектә күрә. Моның белән шагыйрь гади халыкның гасырлардан килгән хыялын чагылдыра. Кол Гали кешеләрне сугыш-талашсыз, үзара тату яшәргә, изгелек кылырга, шәфкатьле булырга өнди. Шагыйрь уенча, гаилә мөнәсәбәтләре мәхәббәткә, тугрылыкка гына нигезләнергә мөмкин. Зөләйха нәкъ менә шундый хатын-кыз булып гәүдәләнә.

Поэманың бай эчтәлеге, гуманлы юнәлеше, тирән хисләр белән сугарылганлыгы һәм йөгерек теле аны урта гасырлар шигъриятенең иң популяр әсәре итә. Аның образлары бик күп буын татар шагыйрьләре өчен илһам чыганагына әверелә.

Бөек Болгарда белемне күп санлы ислам уку йортларында алып булган, мәчетләрдә мәшһүр дин белгечләре үгет-нәсихәт сөйләгәннәр, фәлсәфәчеләр, фикер ияләре фәнни трактатлар язганнар, ә шагыйрьләр үзләренең әсәрләрен иҗат иткәннәр. Бүген дә чит илләрдә болгар галимнәренең медицина, астрономия, математика һәм башка фәннәр өлкәсендәге хезмәтләре киң танылу алган. Дингә өндәүче суфиларның сәфәр кылулары, бөтен мөселман дөньясында танылган Идел буе Болгары шәһәрләреннән күп кенә күренекле дин, хокук белгечләренең һәм медикларның килеп чыгышы турындагы мәгълүматлар төрле илләр авторларының трактатларында билгеләп үтелә.






*Книга Кул Гали «Кысса и Йусуф» в экспозиции Музея Болгарской цивилизации*

*Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» китабы. © Болгар цивилизациясе музее. Болгар*

# ГЛАВА 2

# ГОРОД БОЛГАР И МУСУЛЬМАНСКАЯ КУЛЬТУРА ЗОЛОТОЙ ОРДЫ

## Ислам на Волге в золотоордынское время

Начало XIII столетия ознаменовано эпохальными событиями в истории народов Евразии. Монголо-татарские завоевания, начатые Чингис-ханом в 1207 году с целью создания империи «мира и благоденствия», продолжил в европейской части континента его внук Бату-хан. Он же завершил эти завоевания, покорив обширные земли, которые были включены в состав своих владений – нового государства Улус Джучи, более известного под названием Золотая Орда.

Улус Джучи периода расцвета занимал значительные пространства Азии и Европы. Северные владения его включали земли Волжской Булгарии и соседних с ней территорий расселения мордвы, чувашей, марийцев, удмуртов, башкир. Эти области были заселены разнородными племенами и народами. Среди них были кыпчаки (половцы), саксины, булгары, буртасы, русы, башкиры,



*Бату-хан. Копия рисунка из китайского манускрипта «История первых четырёх ханов из дома Чингиза». Конец XIII века*

*Бату-хан. «Чыңгыз йортында беренче дүрт хан» исемле кытай кульъязмасындагы рәсем*

# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

# БОЛГАР ШӘҺӘРЕ ҺӘМ АЛТЫН УРДАНЫҢ МӨСЕЛМАН МӘДӘНИЯТЕ

## Алтын Урда чорында Идел буенда Ислам дине

XIII гасыр башы Евразия халыклары тарихында аларның киләчәк язмышларын билгели торган эпохаль характердагы вакыйгалары белән аерылып тора. 1207 елда Чыңгыз хан тарафыннан дөньяда «иминлек һәм бай тормыш» империясен булдыру максатыннан башланган яуларны континентның Европа өлешендә аның оныгы Батый хан дәвам итә. Ул бу яуларны 1242 елда тәмамлый, күп җирләрне басып алып, аларны үз биләмәләре составына – рәсми рәвештә Җучи Олысы дип аталган яңа дәүләт составына кертә. Әлеге дәүләтне гадәттә Алтын Урда дип йөртәләр.

Җучи Олысы үзенең чәчәк ату чорында Азия һәм Европа территориясенең яртысын диярлек биләп торган. Аның төньяк биләмәләре Болгарстанның элеккеге җирләрен һәм болгарларның күршеләре булган мордва, чуаш, мари, удмурт, башкорт яшәгән территорияләрне үз эченә ала. Гомумән алганда исә, Җучи Олысында, югарыда санап үтелгәннәрдән башка, төрле телләрдә сөйләшүче кыпчаклар, саксиннар, бортаслар, руслар, шулай ук Идел буе, Кавказ, Себер һәм Урта Азиянең күп санлы халыклары яшәгән. Хәйран гана этник төркемнәр – Ислам, кайберләре – мәҗүсиләр, ша-




*Территории, подвластные Золотой Орде во второй половине XIII века*

*XIII йөзнең икенче яртысында Алтын Урда кул астындагы җирләр*



*Р.Г. Шамсутдинов. Берке-хан*
*Р.Г. Шәмсетдинов. Бәркә-хан*

мордва, а также многоплеменное население Поволжья, Кавказа, Сибири и Средней Азии – представители тюркоязычных, ираноязычных, финно-угорских, кавказских и славянских народов. Некоторые из них исповедовали ислам, другие – христианство. Было много язычников. Среди монголов и татар были распространены шаманизм и христианство несторианского толка.

После завоевательных походов чингизиды/джучиды проводили политику веротерпимости, что соответствовало предписаниям «Ясы» – законам Чингиз-хана. Сам Бату-хан, по словам персидского историка Джувейни, «не придерживался ни одной из религий и не питал склонности к познанию Аллаха».

Берке-хан (1257–1266), пришедший к власти после Бату (1227–1256), стал первым правителем Золотой Орды, принявшим ислам. К такому решению, вероятно, подтолкнуло влияние на него суфийских общин Хорезма, доверительные беседы его с мусульманскими учёными на религиозные темы. Однако при Берке-хане не произошло массового распространения ислама за исключением его приближённых. В государственном управлении по-прежнему придерживались древних тюрко-монгольских традиций (государственное управление, опирающееся на «Ясу», обращение к Вечному Небу, уйгурское



*Узбек-хан. Миниатюра Лицевого летописного свода XVI века*
*Үзбәк-хан. XVI гасырга караган рәсемле елъязма тупламаларыннан миниатюра. Копия*



*Джанибек- хан. Миниатюра из Каталанского атласа 1375 года Национальная библиотека. Париж, Франция*

*Җанибәк-хан. 1375 ел. Каталан атласыннан миниатюра © Милли китапханә. Париж, Франция*

маннар булганнар, христиан динен тотканнар.

Чыңгызиләр-җүчидләр диндә толерантлык сәясәте алып баралар, чөнки бу «Яса» күрсәтмәләренә – Чыңгыз хан законнарына туры килә. Бату хан үзе, фарсы тарихчысы Җүәйни сүзләренчә, «бер генә дин дә тотмаган һәм Аллаһы Тәгаләне белүгә омтылмаган да».

Батудан соң хакимияткә килгән Бәркә хан Алтын Урданың Ислам динен кабул иткән беренче хакиме була. Бәркәнең Бохарадагы суфичыл җәмгыятьләрдә торган мөселман галимнәре белән ихлас күңелдән үткән ышанычлы әңгәмәләре аны Ислам диненә этәргәндер, дип уйларга нигез бирә. Әмма Бәркә хан вакытында аның якыннары һәм буйсынган халыклары арасында Ислам дине киң таралыш алмый әле. Дәүләт идарәсендә элеккечә борынгы төрки-монгол гореф-гадәтләрен саклыйлар (Ясага нигезләнгән дәүләт идарәсе, Мәңгелек Күккә мөрәҗәгать итү, хан ярлыкларында һәм дипломатик документларда уйгур язуы һ.б.). Аннан соңгы ханнар – Мәңге-Тимер (1266–1281), Туда-Мәңге (1281–1287), Тула-Буга (1287–1291), Токта (1291–1312) вакытында да шулай дәвам итә. Ни генә булмасын, бу вакытта инде Ислам диненең абруе



*Пайцза Абдуллах-хана (1361–1370). Монгольская надпись уйгурским письмом: «Силою вечного неба. Покровительством великого могущества. Если кто не будет относиться с благоговением к указу Абдулла-хана, тот подвергнется [материальному] ущербу и умрет».*
*Государственный Эрмитаж. Санкт-Петербург*

*Абдуллаһ-хан (1361–1370) пайзасы. Өслегендә уйгыр графикасы нигезендә кытай язмасы: «Мәңгелек Күк гайрәтләре һәм Бөек көч яклавы астында. Абдуллаһ-хан фәрманына түбәнчелек һәм тирән хөрмәт белән карамаган кешегә җәза биреләчәк, үтереләчәк».*
*© Дәүләт Эрмитажы, Санкт-Петербург*



*Голова каменного изваяния. Найденная при изучении Ханской усыпальницы. Болгар Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Таштан ясалган кеше башы. Болгарда Хан төрбәсе хәрабәләрен казыганда табылган. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*

письмо на ханских ярлыках и дипломатических документах и т.д.). Так продолжалось и при последующих правителях – Менгу-Тимуре (1266–1281), Туда-Менгу (1281–1287), Тула-Буги (1287–1291), Токты (1291–1312), хотя авторитет ислама заметно возрос не только среди правящей аристократии, но и среди простых горожан, даже степных кочевников.

Благодаря поддержке мусульман, которых было уже немало и в правящих кругах, после смерти Токты ханский трон в Джучиевом государстве занял Мухаммад Узбек (1312–1342), воспитанный в мусульманской среде Хорезма. Правильно оценив политическую обстановку в стране и запросы общества, он без колебаний провозгласил ислам официальной религией, господствующей идеологией Новую веру, поддержанную государственной властью, приняли многие слои золотоордынского общества, в том числе и среди населения степной зоны. Это хорошо иллюстрируется после этих событий и появлением мусульманских некрополей, заменивших кочевнические захоронения. Укреплению новой религии среди рядового населения способствовала также политика Джанибека (1342–1357), младшего сына Узбека, направленная на поддержку мусульманского духовенства. Персидский историк Муид ад-Дин Натанзи писал о Джанибеке: «*Весь улус Узбека он обратил в ислам, разрушил все капища идолов, воздвиг и устроил много мечетей и медресе. Всё своё внимание он обратил на благополучие людей ислама <…> Все обычаи стран ислама ввёл он в том государстве*».



*Печать с именем хана Джанибека. 1342–1357. Болгарское городище*

*Җанибәк-хан исеме язылган мөһер. 1342–1357. Болгар шәһәрлеге казылмаларыннан*

хөкүмәт даирәсендә дә, гади халык, хәтта күчмә кыпчаклар арасында да сизелерлек дәрәҗәдә арта.

Токта хан үлгәннән соң, хөкүмәт даирәсендә эшчәнлек алып барган мөселманнар ярдәме белән Җучи дәүләте тәхетенә Хәрәземнең мөселман мохитендә тәрбияләнгән Мөхәммәт Үзбәк (1312–1342) утыра. Илдәге сәяси хәлне һәм җәмгыять алдында торган бурычларны дөрес бәяләп, монгол Ясасын алыштырып, ул, икеләнмичә, Исламны, дәүләт идеологиясе дәрәҗәсенә күтәреп, рәсми дин буларак кабул итә. Дәүләт хакимияте тарафыннан хупланган яңа дин Алтын Урда җәмгыятенең күп катламнары тарафыннан кабул ителә, шул исәптән дала зонасы халкы арасында да киң тарала. Әлеге вакыйгалардан соң, күчмә халыклар каберләрен алыштырган мөселман некропольләренең барлыкка килүе моны яхшы дәлилли. Гади халык арасында яңа динне ныгытуга Үзбәк ханның кече улы Җанибәкнең (1342–1357) мөселман руханиларына ярдәм итүгә юнәлдерелгән сәясәте дә ярдәм итә. Фарсы тарихчысы Мөхәммәт әд-Дин Натанзи Җанибәк турында болай яза: «*Үзбәк ханның бөтен олысы Ислам динен кабул итте, ул мәҗүсиләрнең барлык гыйбәтәтханәләрен, изге урыннарын җимертте, бик күп мәчетләр һәм мәдрәсәләр ачты. Ул барлык игътибарын Ислам кешеләренең иминлегенә юнәлтте < … > Ислам илләренең*



***Монгольский принц изучает Коран. Миниатюра из книги Рашид-ад-Дина «Джами ат- Таварих». Табриз (?). Первая половина XIV века***

***Монгол принцы Коръән өйрәнә. Рәшид-әд-Диннең «Җәмигъ әт-Тәварих» китабыннан миниатюра. Тәбриз (?). XIV гасырның беренче яртысы***

Культурное пространство Золотой Орды в этот период переживает максимальный подъем, что определило формирование ее цивилизационного значения для мировой культуры. Последовавший упадок и сложение отдельных политических образований привело к консолидации ее культурных традиций в новых формах, оказав свое влияние и на сопредельные страны. Широкое проявление золотоордынской культуры в современном мире еще раз подчеркивает ее значение в истории человечества как яркого цивилизационного воспроизводящегося культурного пространства.

В успехах распространения ислама в Золотой Орде заметную роль сыграли проповедники из города Болгара, имеющие богатый опыт не только «священных войн» против неверных, но и мирной проповеднической деятельности среди финно-угорских соседей и кочевников. В XIV в. булгары были известны как *«самые злейшие сарацины, крепче держащиеся закона Магометова, чем кто-нибудь другой»* (В. Рубрук). Не только в западноевропейских, но восточных и русских, источниках имя волжских болгар, а затем татар прочно ассоциировалось с понятием «мусульманство».



***С.Г. Дьяков. Столица Золотой Орды на Ахтубе (Сарай Бату, XIV век). 2008***

***С.Г. Дьяков. Ахтүбәдә Алтын Урда башкаласы (Сарай-Бату, XIV гасыр). 2008***

*барлык гореф-гадәтләрен ул үзенең дәүләтенә кертте»*.

Болгар дингә өндәүчеләре, кяферләргә каршы «изге сугышларда» гына түгел, ә фин-угыр күршеләре һәм дала күчмәләре арасында тыныч миссионерлык эшендә дә зур тәҗрибә туплап, Ислам диненең Алтын Урдада таралуында зур роль уйнаганнар. Алтын Урдада XIV гасырда болгарлар *«башка кавемнәргә караганда Мөхәммәт кануннарын нык тоткан*





* * *

Современники характеризуют монголо-татарские завоевания как *«огромное несчастье, подобного которому не производили дни и ночи, искры которого разлетелись во все стороны и зло которого простёрлось на всех»* (ибн ал-Асир). Однако не следует забывать и о «благочестивых делах» монголов, последовавших за этими драматичными событиями. О них современники пишут тоже с восхищением.




*Памятный знак, установленный на территории Царёвского городища*

*Царёв шәһәрлеге территориясендә урнаштырылган истәлек ташы*

По свидетельствам письменных документов, золотоордынские ханы относились к подвластным землям и народам не как

*Кодекс Куманикус. Первый разворот рукописи. Библиотека Собора св. Марка. Венеция, Италия*

*Кодекс Куманикус кулъязмасының беренче битләре. © Изге Марк соборы китапханәсеннән. Венеция, Италия*

*иң явыз сарациннар*[1]» (В. Рубрук) буларак билгеле була. Көнбатыш Европада гына түгел, ә көнчыгыш һәм рус чыганакларында да Идел буе болгарларының, аннары аларның варислары – татарларның да исемнәре «мөселманлык» төшенчәсе белән бик нык бәйләнгән.

* * *

Замандашлары монгол яуларын «*моңа кадәр күрелмәгән, очкыннары бөтен якларга җәелеп, явызлыгы бөтен җирләргә таралган коточкыч бәхетсезлек*» дип тасвирлый (Ибн әл-Асир). Әмма монголларның бу драматик вакыйгалар артыннан башланып киткән «изге эшләре» турында да онытырга ярамый. Замандашлары алар турында да сокланып язалар.

Язма документларда теркәлеп калган хәбәрләргә нигезләнеп, шуны раслый алабыз: Алтын Урда ханнары үзләренең кул астындагы җирләргә һәм халыкларга талау объекты буларак кына карамаганнар, ә гади игенчеләрнең, терлекчеләрнең һәм һөнәрчеләрнең хуҗалык тормышын җайга салып, аларны яңа яулап алынган җирләрнең муллык чыганагы итәргә омтылганнар. Шул максат белән 1257–1259 елларда Жучи олысы территориясендә халык санын алу үткәрелә, һәр хуҗалыктан еллык керемнең нибары 10% ын гына тәшкил иткән салым алуның бердәм системасы кертелә, башка йөкләмәләр исемлеге билгеләнә. Бу сәясәтнең нәтиҗәсе халыкны хәерчелеккә төшерү түгел, бәлки Җүчилар дәүләтен һәм аның составындагы җирләрне тернәкләндерү, куәтен ныгыту, халыкның тормыш дәрәҗәсен үстерү була.

Алтын Урданы, тарихчылар элек әйткәнчә, буйсындырылган халыклардан җыелган салымнар хисабына яшәүче паразит дәүләт дип санау дөрес булмас. Әлбәттә, яулап алынган җирләрнең гаять зур мәдәни һәм икътисади потенциалы җимерелгән хуҗалыкны торгызу чорында нык җәлеп ителә. Әмма Алтын Урда цивилизациясе, башлыча, үз икътисадын – авыл хуҗалыгын, һөнәрчелекне, эчке һәм тышкы сәүдәне рациональ оештыру һәм алардан килгән табышны дөрес куллану нигезендә барлыкка килә.

Һөнәрчелек җитештерүе һәм тышкы сәүдә күбесенчә административ-сәяси генә түгел, беренче чиратта, һөнәрчелек һәм мәдәни үзәкләр булган шәһәрләрдә урнашкан була. Алтын Урда цивилизациясе баштан ук урбанистик характер ала – безгә билгеле шәһәрләр саны гына да 100 дән артып китә. Аларның иң эреләре Идел сәүдә юлында калкып чыгалар.

Алтын Урда тарихының төрле чорларында аның башкаласы турындагы мәсьәлә бүгенге көнгә кадәр кайнар бәхәсләр китереп чыгара. Оешып кына килә торган Алтын

[1] Биредә сарациннарны мәҗүсиләр, христиан булмаган халык рәвешендә аңларга кирәк.

к объекту грабежа, а стремились, наладив нормальную хозяйственную жизнь, сделать их источником благосостояния вновь обретенных земель. С этой целью в 1257–1259 гг. на всей территории Улуса Джучи была произведена перепись населения, введена единая система подворного умеренного налогового обложения (10% годового дохода), определён перечень других повинностей. Результатом этой политики стало не обнищание народа, а постепенное укрепление мощи покорённых земель и рост благосостояния населения.

Вряд ли будет справедливым считать Золотую Орду паразитическим государством, существовавшим за счёт непомерной дани с покорённых земель, как традиционно утверждали историки в прошлом. Конечно, огромный культурный и экономический потенциал завоёванных земель был активно привлечён в период восстановления разрушенного хозяйства. Однако золотоордынское государство рождалась главным образом на основе рациональной организации своей экономики – международной и внутренней торговли, сельского хозяйства, ремесленного производства и т. д.

Ремесленное производство и внешняя торговля были сосредоточены преимущественно в городах, являющихся не только административно-политическими, но и ремесленными и культурными центрами. Золотоордынская цивилизация имела ярко выраженный урбанистический характер – количество городов превышало более 100 поселений. Наиболее крупные из них располагались вдоль Волжского торгового пути.

Вопрос о столице Золотой Орды в различные периоды её жизни относится к числу дискуссионных. Не вызывает споров лишь факт нахождения первой столицы формирующегося государства в городе Болгаре, о чём недвусмысленно сообщают письменные источники. Да и сам факт чеканки первых монет в этом городе, начавшейся практически сразу после завершения завоеваний Булгарии и сопредельных земель, свидетельствует об этом же.



*Горн для обжига кирпича Раскопки Селитренного городища. 2013*

*Кирпеч яндыру миче. Селитрен шәһәрлегендәге казылмалар. 2013*

*Археологические раскопки Царёвского городища*
*Царёв шәһәрлегендә археологик казулар*





*Изразец с персидскими стихами. XIV в. Царёвское городище*

*Фарсы телендә шигырь язылган рәсемле плитә (изразец). XIV гасыр. Царёв шәһәрлеге*
*© Дәүләт Эрмитажы, Санкт-Петербург*



*Мозаика. Фрагмент. XIV в. Царёвское городище*
*Мозаика. Фрагмент. XIV гасыр. Царёв шәһәрлеге*

*Кашинный кувшин. XIV век Раскопки Селитренного городища. 2015 (по Ю.А. Зеленееву и Е.М. Пигареву)*
*Кашин кувшин. XIV гасыр Селитрен шәһәрлеге казылмаларыннан. 2015 (Ю.А. Зеленеев һәм Е.М. Пигарёв буенча)*



Нижневолжской столицей Золотой Орды долгое время считалось **Селитренное городище** (Сарай-Бату) в районе современной Астрахани. Это действительно остатки большого города, но в нём за долгие годы раскопок не обнаружено монет XIII в. при обилии более поздних.

Ранние монеты имеются, и в значительном количестве, на Красноярском городище, расположенном ниже Астрахани, на восточной части Волжской дельты. Бату-хан, вероятно, заложил его в 1250-х гг. в качестве официальной столицы государства. Позднее при хане Узбеке, в 1330-ые гг., вследствие подтопления береговых городов в дельте Волги из-за подъёма уровня Каспия, столица была перенесена севернее на берег реки Ахтубы, протоки Волги, и получила название ***Сарай ал-Махруса*** («Дворец Богохранимый»), известное как археологический памятник Селитренное городище. Об этом городе сохранились сведения современников. Вот как описывает его арабский путешественник из Магриба ибн Баттута (1333 г.): *«Город Сарай [один] из красивейших городов, достигший чрезвычайной величины, на ровной земле, переполненный людьми, с красивыми базарами и широкими улицами. Однажды мы поехали верхом с одним из старейшин его, намереваясь объехать его кругом и узнать объём его. Жили мы в одном конце его и выехали оттуда утром, а доехали до другого конца его только после полудня <…>, и [всё] это сплошной ряд домов, где нет ни пустопорожних мест, ни садов. В нём 13 мечетей для соборной службы <…> Кроме того, ещё чрезвычайно много [других] мечетей. В нём [живут] разные народы, как то: монголы – это (настоящие) жители страны и владыки [её], некоторые из них мусульмане; асы, которые мусульмане; кыпчаки, черкесы, русские, византийцы, которые христиане. Каждый народ живёт на своём участке отдельно, там и базары их. Купцы же и чужеземцы из обоих Ираков, из Египта, Сирии и других мест живут в [особом] участке, где стена ограждает имущество купцов. Тамошний дворец султана называется Алтунташ»*.

В полном согласии с письменными источниками, начавшиеся в последние годы археологические исследования показывают Сарай ал-Махруса как один из крупнейших городов средневековой Евразии, не уступавший ни по занимаемой площади, ни по количеству жителей, ни по уровню благоустройства таким городам-гигантам, как Багдад, Каир, Рим и Константинополь. Он занимал огромную по тем временам площадь – более 2 тысяч га, включая пригороды. Численность населения достигала 75 тысяч человек. Культурный слой городища был сильно нарушен жилыми домами, хозяйственными и общественными постройками современного села, но выявленные руины древних зданий и большое количество находок вполне адекватно отражают былую развитую городскую культуру золотоордынского времени.

Урданың Бату хан сайлаган беренче башкаласы Болгарда булган. Бу хакта язма чыганаклар хәбәр итә, шуңа күрә әлеге мәсьәлә галимнәрдә бәхәс уятмый. Бу шәһәрдә, ягъни Болгарда, иң элгәреге Җүчи акчаларын суктыра башлау факты үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Алтын Урданың икенче башкаласы булып озак вакытлар хәзерге Әстерхан төбәгендәге Селитренное шәһәрлеге саналып килде. Биредә чыннан да бик зур шәһәр харәбәләре урнашкан, әмма анда хәзергә кадәр XIII гасыр тәңкәләре табылмаган.

Ә менә Әстерханнан түбәнрәк, Идел дельтасының көнчыгыш өлешендә урнашкан Кызыл Яр (Красноярск) шәһәрлегендә XIII гасыр тәңкәләре шактый күп. Бату хан аңа 1250 елларда дәүләтнең рәсми башкаласы буларак нигез салган булуы ихтимал. Соңрак, 1330 елларда Үзбәк хан чорында, Каспий диңгезенең күтәрелүе аркасында Идел дельтасындагы яр буе шәһәрләрен су басу сәбәпле, башкала төньякка, Иделнең кушылдыгы булган Ахтуба елгасы ярына күчерелә һәм Сарай әл-Мәхрүсә (мәгънәсе: «Аллаһ тарафыннан саклана торган Сарай») дип атала, хәзер әлеге археологик һәйкәл Селитренное шәһәрлеге буларак билгеле.

Бу шәһәр турында чордашларының кызыклы мәгълүматлары сакланган. Гарәп сәяхәтчесе Ибн Баттута (1333 ел) болай дип язып калдырган: *«Сарай шәһәре гаять зур, иң матур шәһәрләрнең берсе, тигез җирдә урнашкан, халкы тулып торган, матур-матур базарлары һәм киң урамнары булган гүзәл шәһәр. Бервакыт без, андагы аксакалларның берсе белән, шәһәрнең ни зурлыкта булуын белергә теләп, атка атланып, аны әйләнеп кайтырга дип киттек. Без шәһәрнең бер башында яши идек, аннан иртән чыгып киттек һәм шәһәрнең икенче очына бары тик төштән соң гына барып җиттек, анда өйлә намазын укыдык, ашап-эчтек, үзебез кайтасы урынга кояш баеганда гына барып җиттек. Бервакыт без аны киңлеккә үттек һәм ярты көннән соң гына әйләнеп кайттык. Бу шәһәр урамнары тоташ йортлардан гына тора, анда буш урыннар да, бакчалар да юк. Шәһәрдә җомга гыйбадәте өчен 13 мәчет бар < ... > Аннан кала, тагын бик күп мәчетләр санадык. Анда төрле халыклар яши: монголлар – болар чын мәгънәсендә илнең үз халкы, хуҗалары, аларның бер өлеше мөселманнар; аслар – мөселманнар; кыпчаклар; черкесләр; руслар һәм византиялеләр – болары христианнар. Һәр халык үз мәхәлләсендә аерым яши, базарлары да шунда. Гыйрактан, Мисырдан, Сүриядән һәм башка урыннардан килгән сәүдәгәрләр күп. Солтан сарае Алтынташ дип атала».*

Урта гасыр шәһәрләре, бигрәк тә Көнбатыш Европаныкылар арасында Сарай әл-Мәхрүсә үзенең югары дәрәҗәдәге төзеклеге, уңайлыклары белән аерылып торган. Монда керамик торбалардан суүткәргечләр һәм канализация системасы булган. Шәһәр кешеләре эчәр өчен суны арыклар белән тоташтырылган фон-

На территории ***Селитренного городища*** археологами исследованы богатые усадьбы, огороженные кирпичной стеной; многокомнатные дома, в том числе дома дворцового типа с пристроенными к ним банями и рядом расположенными хозяйственными постройками. В некоторых аристократических усадьбах работали ремесленные мастерские, там же располагались домики для проживания ремесленников и слуг. Вдоль усадебных стен выявлены улицы с арыками и дренажными канавками.

На городских площадях с оживлёнными базарами стояли мечети и общественные бани. В периферии города располагались дома рядовых горожан, некрополи, мавзолеи. Красоту и особый восточный колорит общественным зданиям придавали мозаичные плиты, майоликовые изразцы с поливой ультрафиолетового, белого, голубого, красного и жёлтого цветов, а также плитки резной и штампованной терракоты, богато украшенные плетёными фигурами, трилистниками, четырёхлепестковыми розетками, эпиграфическим орнаментом.

Селитренное городище было крупнейшим центром ремесленного производства. Археологами открыты большие по площади районы с горнами для обжига поливной и неполивной керамики, строительного кирпича; мастерские по производству стеклянной посуды, оконных дисков и украшений, ювелирных изделий и т. д. Выявлены следы чёрной и цветной металлургии, камнеобработки, производства костяных изделий. Особенно поражает исследователей высокий уровень организации ремесла в области керамического производства. Существовали целые кварталы гончаров, объединённых в особые корпорации – кархана, как их называли на Востоке. Например, на т.н. «Черепяном поле», занимающем огромную площадь – более 5 га! – функционировали десятки и сотни мастерских с высокопроизводительными горнами.

Быстрое возвышение Сарая как центра международной торговли обусловливалось не только высокоразвитой экономикой. Этому способствовала также общегосударственная политика, направленная на максимальное благоприятствование торговле: денежная реформа Узбек-хана, в результате которой сарайский дирхем стал единой по весу на всей территории империи; обеспечение безопасности торговых путей, установление низких таможенных сборов от 3 до 5% от стоимости товаров и т. д. Для иноземных купцов составлялись особые дорожники-путеводители и карты, двуязычные словари типа «Codex Cumanicus».

Во второй половине XIV в. столицей Улуса Джучи, вероятно, становится ***Новый Сарай – Сарай ал-Джадид***, руины которого локализуют на Царевском городище (Сарай-Берке) близ Волгограда. Он был построен в период правления Джанибек-хана (1342–1357) сыне Узбек-хана, когда здесь начал работать новый монетный двор «Гюлистан».

таннардан алганнар. Матур сарайлар һәм җәмәгать биналары яндырылган кирпечтән, ә гади кеше йортлары чи кирпечтән (сырец) һәм агачтан салынган. Биналар таштан яисә балчыктан сырлап ясалган бизәкләр, ялтыравык йөгертелгән полихром бизәкле плитәләр белән тышланган. Бай йортларда бүлмәләр эссе һава белән җылытылган. Ул, мичтән чыгып, идән астында урнашкан төтен юллары аша йөргән. Диварларга терәтеп җылы суфа – ятаклар куелган. Еш кына ишегалдында яисә биналар эчендә агымсулы бассейннар ясалган.

Сарай әл-Мәхрүсә, дәүләтнең административ үзәге булудан тыш, эре һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге буларак та танылган.

Сарайда 75 мең чамасы кеше яшәгән. Соңгы елларда үткәрелгән археологик тикшеренүләр Сарай әл-Мәхрүсәне Багдад, Каһирә, Рим һәм Константинополь кебек урта гасыр чорындагы Евразиянең гигант шәһәрләре рәтенә куярга нигез бирә.

XIV гасырның икенче яртысында Җучи олысы башкаласы, мөгаен, ***Яңа Сарай – Сарай әл-Җәдид*** булгандыр, аның харәбәләре Волгоград янындагы Царев шәһәрлегендә (Сарай-Бәркә) урнашкан. Ул Үзбәк хан улы Җанибәк хан (1342–1357) идарә иткән чорда, биредә «Гөлстан исемле акча суктыру үзәге барлыкка килгәч, төзелгән».

Шәһәр 600 гектарга якын мәйданны биләгән. Археологлар биредә элеккеге Шәрык шәһәре төзелеше традицияләрен саклап калган шәһәр эзләрен ачтылар: үзәктәге хан сараеның һәм гомумән шәһәрнең саклану ныгытмалары юк; хәтта югары катлау кешеләренең бай утарлары да ничектер тәртипсез, «ирекле» рәвештә урнашкан, кирпеч йортлар янында гына күчмәннәрнең чатырлары.

Яңа Сарай дистәләрчә мәчетләре, шау-шулы базарлары белән дан тоткан. Ул базарлар урынында әле бүген дә җир өстендә сибелеп яткан әллә никадәр көмеш һәм бакыр акчалар җыеп алырга була. Шәһәр үзәгендә матур бизәлешле биналар калкып торган, читтәрәк һөнәрчеләрнең остаханәләре урнашкан булган.

Яңа Сарай 1395 елда Аксак Тимер гаскәрләре тарафыннан җимертелә.

Иделнең уң як ярында, Волгоградтан 40 километр төньяктарак урнашкан ***Бәлҗемән*** – Алтын Урданың мәйданы 50 гектар чамасы булган кечкенә шәһәрләре исәбенә керә. Шәһәр халкының матди культурасын өйрәнүче галимнәр анда бер үк дәрәҗәдә диярлек рус һәм болгар традицияләренең берләшкән булуын билгеләп үтәләр. Бу аңлашыла да: археологлар фикеренчә, биредә руслар күпләп яшәгән, аларның хәтта аерым колонияләре дә булган. Бәлҗемәндә шулай ук кирпечтән салынган торак йортлар, мәчет, җылыту системасы булган җәмәгать мунчалары, чүлмәк яндыру мичләре казып тикшерелгән. Шәһәр читендә ерактан ук гөмбәз түбәле, диварлары мозаик плитәләр белән бизәлгән кирпеч төрбәләр (мавзолейлар) күренеп торган.

***Укәк*** – Саратов шәһәре читендә, Иделнең уң ягында урнашкан Алтын Урда шәһәре. Ул XIII йөзнең икенче



*Археологические раскопки мечети в Бельджамене*
*Бәлҗәмәндә (Бельджамен) казып чыгарылган мәчет хәрабәләре*

Город занимал большую площадь, достигающую около 600 га. Археологи выявили здесь остатки благоустроенного города, сохранившего традиции восточного градостроительства: отсутствие фортификации и цитадели в качестве укреплённого административного центра; свободное, без видимого порядка, расположение аристократических усадеб; юрты кочевой знати рядом с кирпичными домами и т. д. Главные улицы с богатыми усадьбами и кварталами рядовой застройки, культовыми сооружениями и постройками производственного характера радиально сходились на центральной площади. Усадьбы знати представляли собой огороженные кирпичными стенами дворы с бассейном и многокомнатными домами в центре.

Пригороды также были застроены усадьбами, самые крупные из них имели площадь до 200×130 м. Вокруг располагались более мелкие усадьбы и небольшие глинобитные дома, которые образовали торгово-ремесленные кварталы с водоёмами-хаузами и улицами, имевшими арыки для бесперебойного снабжения водой городского населения. На окраине города выявлены могильники, в том числе курганные, иногда с кирпичными надгробиями и склепами мусульман-

яртысында барлыкка килгән Алтын Урданың элгәреге чорына караган аз санлы шәһәрләренең берсе. Территориясенең җимерелүләрдән сакланып калган өлеше 205 гектардан артык (*«урта зурлыктагы шәһәр, әмма бик матур төзелгән»* – Ибн Баттута искәрмәсе, XIV гасыр). Үкәкнең иң югары икътисади күтәрелеш чоры 1270–1330 елларга карый. Ул чорда бу шәһәр Алтын Урданың икътисади һәм сәяси тормышында зур роль уйнаган. Үкәктә сугылган акчалар да шуны раслый. Шәһәрлектә кирпеч мавзолей калдыклары, төрбәләр һәм майолик плитәләр яндыруга көйләнгән мичләр ачылган. Шәһәр тирәсендә игенчелек белән көн күрүче һәм әле күчмә тормыштан аерылып җитмәгән кешеләрнең торулыклары урнашкан. Кара диңгез, Якын һәм Урта Көнчыгыш, Көнбатыш Европа шәһәрләреннән килгән күпсанлы тәңкәләр һәм чит ил эшләнмәләре Үкәкне халыкара сәүдә үзәге буларак та күрсәтә.

***Наручат*** хәзерге Мордовия территориясендә Алтын Урда чорындагы Мухша төбәгендә урнашкан булган, аның мәйданы якынча 250 гек-

*Кротков А.А. Схематический план местности Увекского золотоордынского городища в 12 км от Саратова. Съемка 1905–1915 годов*

*А.А. Кротков. Саратовтан 12 км ераклыкта урнашкан һәм Алтын Урда чорына караган Үкәк шәһәрлеге план-схемасы*






*Планировка золотоордынского города Мохши (по Д.С. Иконникову и М.И. Баишевой)*

*Алтын Урда чорының Мухша шәһәрлеге планы. (Д.С. Иконников, М.И. Баишева буенча)*

ского населения города и его окрестностей.

***Бельджамен*** (Водянское городище), развалины которого находятся на правом берегу Волги в 40 км севернее Волгограда, относится к числу небольших городов Золотой Орды площадью около 50 га. В материальной культуре города исследователи отмечают «соединение русских и болгарских традиций». Исследованы также жилые здания, мечеть, общественные бани с подпольной системой отопления, керамические горны. На окраине города обращает на себя внимание кирпичный мавзолей с купольным перекрытием усыпальницы и с порталом, украшенным мозаикой.

***Укек*** – золотоордынский город на правом берегу Волги, расположенный на окраине г. Саратова. Это один из немногих городов раннезолотоордынского времени, возникших во второй половине XIII в. Сохранившаяся часть территории городища составляет более 205 га («город средней величины, но красивой постройки», по замечанию ибн Баттуты, XIV в.). Период наивысшего экономического подъёма Укека относится к 1270–1330-м гг., когда здесь чеканились монеты, свидетельствующие о значительной роли города в экономической и политической жизни государства. На городище открыты остатки кирпичного мавзолея, отдельно стоящие склепы и горны для обжига изразцов. В ближайшей округе располагались поселения осёдлого и кочевого населения. Многочисленные находки монет и импортных изделий из городов Причерноморья, Ближнего и Среднего Востока, Западной Европы представляют город как центр международной торговли.

***Наровчат*** находилась на землях современной Мордовии в области Мокша золотоордынской эпохи, площадь его достигала около 250 га. Возникновение города связывают с политикой Узбек-хана по преобразованию государства и с принятием ислама государственной религией в 1321 г., по имеющимся сведениям, именно в этом городе. Здесь была построена большая Соборная мечеть, существовал свой монетный двор, строились из кирпича и камня жилые дома, мечети, караван-сараи,



*Генуэзская крепость в Судаке*
*Судак (Кырым.) – генуялылар каласы. XIV–XV гасырлар*

ция калдыклары сакланган. Җитештерү комплекслары – чүлмәк ясау һәм тимерчелек остаханәләре, төзелеш кирпечен яндыру өчен мичләр эшләп торган. Археологик материаллар үзенең зур үсеш чорында Үкәкне дә үзенең икътисади орбитасына керткән Наручатның Мухша төбәгендә эре икътисади һәм сәяси үзәккә әйләнеп китүен, Алтын Урданың күп кенә өлкәләре, шулай ук рус кенәзлекләре белән дә мәдәни һәм сәүдә элемтәләре урнаштырган булуын раслыйлар. Наручат шәһәре XIV гасыр ахырына кадәр яшәгән.

тар тәшкил иткән. Алтын Урданың күренекле шәһәрләреннән. Шәһәрнең барлыкка килүен Үзбәк ханның дәүләтне үзгәртеп кору сәясәте һәм, булган мәгълүматлар буенча, 1321 елда нәкъ менә шушы шәһәрдә дәүләт дине буларак Ислам динен кабул итү белән бәйлиләр. Наручатта акчалар да сугылган. Биредә зур җәмигъ мәчете, кирпечтән һәм таштан торак йортлар, мәчетләр, кәрван-сарай, мавзолейлар төзелгән. Сусаккыргыч, балчык торбалардан кнеәт канализа-

Алтын Урда ханнары хакимияте астында булган Кырым ярымутравы шәһәрләре арасында иң зурысы – ***Солхат*** (хәзерге Иске Кырым). Шулай ук хәзерге Бахчасарай районындагы Кырк-Ер/Чуфут-Кала, Кафа (хәзерге Феодосия), Солдайя/Судак, Мангуп тавындагы Феодоро һ.б. һөнәрчелек һәм сәүдә үзәкләре буларак та-



*Руины Маджара. Акварель из книги «Voyage de J. Potocki dans les steps d'Astrakhanet du Caucase» (Paris, 1829)*

*П.С. Паллас. Алтын Урда шәһәре Маҗарда сакланып калган соңгы төрбә-мавзолей*




***Большие Маджары между реками Кума и Бибала***

***Кума һәм Билбала елгалары арасында Олы Маҗар. Иллюстрация китаптан: Паллас П.С. Путешествия по южным провинциям Российской империи в 1793–1794 годах. Лейпциг, 1794***

мавзолеи. Сохранились остатки водопровода и канализации из глиняных труб. Функционировали производственные комплексы – гончарные и кузнечные мастерские, горны для обжига строительного кирпича. Археологические материалы свидетельствуют о превращении Наровчата в крупный экономический и политический центр области Мокши, включавший в период свое расцвета в свою экономическую орбиту и Укек, имевший культурные и торговые связи со многими регионами Золотой Орды, а также с русскими княжествами. Город Наровчат про существовал до конца XIV в.

Среди городов Крымского полуострова, находившегося под властью золотоордынских ханов наиболее крупными были: Солхат (совр. Старый Крым), Кырк-Ер/Чуфут-Кале в районе Бахчисарая, Кафа (совр. Феодосия) и др. Со времени основания и до конца XV века Солхат являлся самым значительным экономическим, политическим, административным и культурным центром, «столицей» полуострова. Следует заметить, что многие из сооружений монументальной архитектуры (мечети, медресе, мавзолеи, караван-сараи, крепостные стены и др.), олицетворяющих высокий статус города, в довольно хорошем состоянии сохранились до наших дней.

На восточных и юго-восточных территориях Золотой Орды, включавших в основном земли современного Казахстана и Туркменистана (в низовьях Аму-Дарьи), располагались такие известные города, как Сарайчик, Ургенч, Сыгнак, Сауран, Яссы, Отрар, Дженд и др., часть которых возникла задолго до монгольских завоеваний и продолжала существовать после распада государства Джучидов. Этот регион связанный с древней областью Хорезм был один из важных урбанистических центров Золотой Орды.

Самые известные золотоордынские города Западной Сибири – Тюмень, являвшаяся административно-политическим центр улуса, и Искер (близ совр. Тобольска), в бу-



*Мечеть Узбека. Солхат, Крым. 1314*

*Үзбәк-хан мәчете. 1314. Солхат, Кырым*

һ.б. кебек шәһәрләр урнашкан була. Аларның бер өлеше монгол яулауларына кадәр үк барлыкка килеп, Җүчиләр дәүләте таркалганнан соң да яшәүләрен дәвам иткән. Борынгы Хәрәзем өлкәсе белән бәйле бу төбәк Алтын Урданың мөһим урбанистик үзәкләренең берсе булган.

Көнбатыш Себернең иң билгеле Алтын Урда шәһәрләре – шул олысның административ-сәяси үзәге булган Төмән һәм хәзерге Тубыл (Тобольск) янында урнашкан Себер ханлыгының булачак башкаласы Искер. Алар монголларга кадәрге чорда барлыкка килгән, ә Алтын Урда таркалганнан соң, Себер ханлыгының административ үзәкләренә әйләнгәннәр. Бу шәһәрләрнең төрки телле халкы инде Ислам дине белән таныш була һәм ул төбәктә таралуын дәвам итә, әмма әле иске диннәрендә калучылар да булган.

Хәтта иң танылган Алтын Урда шәһәрләрен өстән-өстән генә күзәтү дә, монгол ханнары җимерүчеләр түгел, ә төзүчеләр булган, диган нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Һәр

нылганнар. Солхат, нигез салынганнан алып XV гасыр ахырына кадәр, ярымутрауның иң мөһим икътисади, сәяси, административ һәм мәдәни үзәге, «башкаласы» булып саналган. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, шәһәрнең югары статусын гәүдәләндерүче монументаль архитектура корылмаларының күбесе (мәчетләр, мәдрәсә, мавзолейлар, караван-сарай, кирмән диварлары һ.б.), бүгенге көнгә кадәр шактый яхшы хәлдә сакланып калган. Үзбәк хан мәдрәсәсе – Солхатның иң матур биналарыннан саналган. Аның янәшәсендә фонтан атып торган, аңа су керамик торбалар буйлап якындагы тау сыртында урнашкан чишмәдән агып килгән.

Алтын Урданың көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш территорияләрендә, нигездә, хәзерге Казахстан һәм Төркмәнстан җирләрен үз эченә алган төбәкләрдә (Аму-Дарьяның аскы өлешендә) Сарайчык, Өргәнч, Сыгнак, Сауран, Яссы, Отрар, Җәнд



*Сарайшык. 2020*

*Сарайчык шәһәрлеге. XIII–XIV гасырлар. Тарихи-мемориаль комплекс. Казахстан. 2000*

дущем столица Сибирского ханства. Многие из них появились еще домонгольское время, а после распада Золотой Орды стали административными центрами Сибирского ханства. Тюркоязычное население этих городов было уже знакомо с исламом и он получал свое распространение в регионе, однако часть населения продолжала придерживаться традиционных верований.

Даже поверхностный обзор наиболее известных золотоордынских городов позволяет заключить, что ханы Улуса Джучи по большому счёту были не разрушителями, а строителями. Практически в каждом городе раскопаны остатки многокомнатных кирпичных домов, мечетей, бань, караван-сараев и других общественных зданий. Их стены были облицованы расписной штукатуркой, многоцветными поливными изразцами, орнаментальной резьбой по камню и гипсу, фресковой росписью. Время сохранило произведения декоративно-прикладного искусства золотоордынской поры. Это мастерски выполненные ювелирные изделия, украшения женского и мужского костюма, конского снаряжения, поливная и неполивная керамика, резная кость – все с пышным декором, изображениями растений, животных, геометрических фигур или арабесок. Города отличались высоким уровнем благоустройства, красотой архитектурных сооружений, чистотой улиц и площадей.



*Отрар. 2020*

*Отрар шәһәрлеге. XIII гасыр. Казахстан, Төркестан өлкәсе. 2020*



*П.С. Паллас. Последние сохранившиеся мавзолеи золотоордынского города Маджара. 1780*
*Маҗар хәрабәләре. Акварель, китаптан:*
*Vayage de J. Potock; dans les steps d' Astrakhanet du Caucase. Paris, 1829*

шәһәрдә диярлек археологлар күп бүлмәле кирпеч йортлар, мәчетләр, мунча, кәрван-сарай һәм башка иҗтимагый биналарның харәбәләрен казып чыгарганнар. Аларның диварлары полихром плитәләр, фрескалар белән бизәлгән. Вакыт Алтын Урда чорына караган декоратив һәм гамәли сәнгать әсәрләрен саклап калган. Болар – оста эшләнгән зәркән әйберләре, хатын-кыз һәм ир-ат киемнәре өчен бизәкләр, ат җигү өчен кирәк-яраклар, ялтыравыклы һәм ялтыравыксыз керамика, уеп ясалган сөяк – болар барысы да мул бизәкләр, үсемлекләр, хайваннар рәсеме, геометрик фигуралар яки арабескалар белән бизәлгән. Шәһәрләр югары дәрәҗәдәге уңайлыклар, матур архитектура корылмалары, урамнар һәм мәйданнар чисталыгы белән аерылып торган. Хакимнәр шәһәр кешеләре өчен мөмкин кадәр уңай тормыш шартлары тудырырга һәм сәүдәне үстерергә тырышканнар.

Алтын Урданың шәһәр мәдәнияте монголлар басып алган төрле илләрнең оста-һөнәрчеләре традицияләре кушылмасы була. Анда Кытай һәм Урта Азия сәнгате сыйфатлары, Үзәк Азия, Кавказ һәм Русьтан алынган йорт төзелеше элементлары, Кырым, Хәрәзем һәм Идел буе Болгары һөнәрчелеге элементлары чагыла. Кытай цивилизациясенең кайбер казанышлары Урда шәһәрләренә Бөек ефәк юлыннан җиңел үтеп керә. Казу эшләре вакытында археологлар кытай көзгеләре, фарфор һәм селадон савыт-саба, кош һәм аждаһа сурәтләре төшерелгән сөяк әйберләр, чуен казаннар, кытай ефәге табалар. Алтын Урданың эре шәһәрләрендә XIII–XIV гасырлар арасында бай художество традицияләренә ия булган мөселман сәнгате тарала.

* * *

Алтын Урда урта гасырлар цивилизациясенең моңарчы күрелмәгән дәрәҗәсенә ирешкән. Аның чәчәк атуы XIV гасырның беренче яртысына туры килә, ул вакытта үзәкләшкән дәүләт шартларында ике арадагы ызгышлар туктатыла, сәяси хәл то-



трыклана, тышкы дөнья белән киң сәүдә элемтәләре урнаштырыла. Алтын Урда хакимнәре Сарайга атаклы галимнәрне, дин әһелләрен, шагыйрьләрне, ерак иләрдән белемле кешеләрне җәлеп итәргә омтылып, аларга һәрдаим ярдәм итеп тора. Шул эшләре белән Бәркә, Үзбәк, Җанибәк ханнар мәдәният дөньясында олы хөрмәт һәм дан казаналар. Бәркә хан үз халкы арасында Ислам дине тарата башлавы белән танылa: *«аның карамагында булган барлык җирләрдә мәчетләр һәм мәктәпләр төзи башлый, галимнәрне, хокук белгечләрен үзенә чакыра, алар белән дуслаша»* (Ибн Халдун). Бәркә хан сараенда *«фән һәм шәригатькә карата фикер алышулар даими үткәрелеп тора«* (Җүзҗани). Үзбәк хан Сарайда *«галимнәр өчен мәдрәсә төзеде, чөнки ул фәнгә һәм кешеләргә бик тугъры иде»* (әл-Гомәри). Җәнибәк *«белемнәре, аскетик эшләре һәм диндарлыгы белән аерылып торган галимнәргә һәм барлык кешеләргә зур хөрмәт күрсәтте»* (Әбү-л-Гази Баһадур).

Бу чорда Алтын Урда башкаласы мәдәният үзәгенә әверелә. XIV гасыр гарәп язучысы Ибн Гарәбшаһ билгеләп үткәнчә, Сарай әл-Мәхрүсә

***Поливная посуда золотоордынского времени, найденная на территории Азака. Выставка «Золотоордынские древности. Забытый город Азак» из собрания Азовского музея-заповедника. Казанский кремль. Музей истории государственности татарского народа и Республики Татарстан. 2014***

***Азак шәһәре территориясендә табылган глазурьлы савыт-саба. «Алтын Урда борынгылыклары: онытылган Азак шәһәре» дип аталган күргәзмә. Азак музей-тыюлыгы тупламаларыннан. Казан кремле. Татар халкы һәм Татарстан Республикасы дәүләтчелеге тарихы музее. 2014***





***Предметы культа, деньги, различные предметы быта. Найдены во время раскопок городища Искер (по А.А. Адамову)***

***Культ (табыну) предметлары, акчалар, көнкүреш кирәк-яраклары. Искер шәһәрлеге казылмаларыннан чыккан табылдыклар. (А.А. Адамов буенча)***

Правители стремились создать максимально благоприятные условия жизни для горожан и развитию торговли.

* * *

Золотая Орда достигла высокого уровня своего развития. Расцвет её пришёлся на первую половину XIV столетия, когда в условиях централизованного государства прекратились междоусобицы, стабилизировалась политическая обстановка, установились широкие торговые связи с внешним миром. Правители Золотой Орды стремились привлечь ко двору крупных учёных, богословов, поэтов, образованных людей из дальних стран, покровительствовали им. Такую славу о себе оставили ханы Берке, Узбек, Джанибек. Берке-хан снискал себе уважение тем, что «среди всего своего народа распространил ислам; на всех подвластных ему территориях начал строить мечети и школы, созвал к себе учёных, правоведов, подружился с ними» (ибн Халдун). При дворе Берке-хана «постоянно происходят диспуты относительно науки и шариата» (Джузджани). Узбек-хан построил в Сарае «медресе для науки, [потому что] он очень предан науке и людям её» (ал-Омари). Джанибек «оказывал великое уважение учёным и всем, отличавшимся познаниями,




*Городище Искер. План (по А.А. Адамову)*
*Искер шәһәрлеге. План (А.А. Адамов буенча)*

*«фән һәм иркенлек чыганагына әверелә; кыска гына вакыт эчендә бирегә галимнәр, атаклы затлар, танылган шагыйрьләр һәм сәнгатьчеләр, кыскасы, бик күп лаеклы кешеләр туплана, шул кадәр мәшһүр затлар хәтта халкы бихисап саналган Мисырның күп өлешендә дә җыела алмас иде».*

Алтын Урда шәһәрләрендә мәдәният үсеше Ислам динен дәүләт дине буларак кабул итү нәтиҗәсе булып тора. Моңарчы дәүләт эшендә иске уйгыр язуы кулланылса, Ислам дине кабул ителгәч, аны гарәп графикасы алыштыра, гарәп әдәбияты нигезендә язмачылык киң тарала. Җәмәгать биналарының иң күренекле урыннары, мәсәлән, гөмбәз, биек порталлар һәм ишекләр гарәпләрнең бормалы язуы, Коръән сүрәләре, шәрык шагыйрьләренең шигырьләреннән өзекләр белән бизәлгән. Кәгазьгә металл каләм белән язганнар. Балчык һәм металл савытларда, бизәнү һәм көнкүреш әйберләрендә халыкның төрле катлаулары арасында укый-яза белүнең киң таралуына ишарәләүче төрле язулар сакланып калган.

Бай йортларның китап киштәләрендә Фирдәүси һәм Рудаки (X гасыр), Гомәр Хәйәм (XII гасыр), Низами (XII гасыр), Руми һәм Сәгъди (XIV гасыр) иҗат иткән әсәрләрне күрергә мөмкин була. Алар Алтын Урда шагыйрьләренә үрнәк булып торганнар, яңа әсәрләр язарга рухландырганнар һәм үзләренең әсәрләрендә еш кына искә алынганнар.

Сарайда һәм илнең башка шәһәрләрендә төрле уку йортларының киң челтәре булдырылган. Биредә күренекле дин белгечләре, галимнәр һәм шагыйрьләр, шул исәптән мөселман



*Пророк Мухаммед у ворот рая. Иран. 1465 Миниатюра из «Нахдж ал-фарадис» Махмуда ас-Сараи ал-Булгари*

*Мөхәммәд пәйгамбәр оҗмах капкасы янында. Иран, 1465. Мәхмүд ас-Сараи әл-Болгариның «Нәһҗ-әл-фарадис» поэмасыннан миниатюра © Дэвид коллекциясе, Копенгаген, Дания*



*Кемаль-ад-Дин Бехзад Иллюстрация к поэме «Хосров и Ширин» Низами. 1468–1506. Герат*
*Кемал-ад-Дин Бәхзад. Низаминың «Хәсрәү вә Ширин» поэмасына иллюстрацияләр*

аскетическими делами и благочестием» (Абу-л-Гази Бахадур).

Центром культуры была столица Золотой Орды. Как отмечал арабский писатель XIV столетия ибн-Арабшах, Сарай ал-Махруса *«сделался средоточием науки и рудником благодатей, и в короткое время в нём набралась [такая] добрая и здоровая доля учёных и знаменитостей, словесников и искусников, да всяких людей заслуженных, какой подобная не набиралась ни в многолюдных частях Египта, ни в деревнях его»*.

Развитие культуры в золотоордынских городах было следствием принятия ислама как государственной религии. Вместе с исламом широко распространилась письменность на основе арабской графики и литература, заменив даже в государственном делопроизводстве старое уйгурское письмо. Самые видные места общественных зданий, например, купола, высокие порталы и двери украшались красивыми надписями арабской вязью – изречениями из Корана, стихами восточных поэтов. Писали на бумаге металлическими перьями. На глиняных и металлических сосудах, украшениях и бытовых предметах сохранились различные надписи, свидетельствующие о широком распространении грамотности среди различных категорий населения.

Включение ислама в политическую и общественную культуру нашло отражение в широком распространении в Поволжье, Хорезме и Крыму суфийских течений, представленных в местах духовных их практик ханака, рибатами. Суфизма, как мистическое направления в исламе благодаря произведениям ал-Газали, Ахмеда Ясави и их последователей стали важной частью суннитского течения. Суфийские ханака служили центрами распространения ислама в разных регионах Улуса Джучи.

На книжных полках богатых домов можно было видеть творения Фирдоуси и Рудаки (X век), Омара Хайяма (XI век), Низами (XII век), Руми и Саади (XIV век), произведения которых вдохновляли золотоордынских поэтов на создание собственных сочинений и часто упоминались в их произведениях.

В Сарае и в других городах страны была создана широкая сеть различных учебных заведений. Здесь преподавали видные богословы, учёные и поэты, в том числе выходцы из городов мусульманского Востока. Так, в Болгаре долгое время жили крупные религиозные деятели Ходжа Хасан ибн-Омар ал-Болгари, получивший известность в Ганджи (Азербайджан), Абу Мохтар ибн-Махмуд ал-Казвини, беженец из Ирана, Госам ибн-Малик ал-Маргиани из Ферганы. При медресе имелись богатые библиотеки, школы каллиграфов и переписчиков книг.

Многие учёные и поэты владели несколькими языками, они писали свои произведения на поволжском тюрки, арабском и персидском языках. Письменная культура развивалась в основном на старотатарском языке, очень близком к современному татарскому. На нём написаны офи-



*Блюдо с изображением птицы. Кашин. Золотая Орда. XIV век.*
*Найдено при раскопках Болгарского городища.*
*Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*
*Кош сурәте төшерелгән савыт. Кашин. Алтын Урда, XIV гасыр.*
*Болгар шәһәрлеге казылмаларыннан.*
*© Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*

илләреннән чыккан кешеләр укыткан. Мәсәлән, Болгарда озак вакытлар Ганҗәдә дан казанган Хәсән ибн Гомәр әл-Болгари (Әзербәйҗан), Иран качагы Әбу Мохтар ибн Мәхмүт әл-Казвини, Фирганәдән Ибн Мәлик әл-Маргиани кебек укымышлылар яшәгән. Мәдрәсә каршында бай китапханәләр, каллиграфлар мәктәбе һәм китап күчереп язучы хаттатлар булган.

Күп кенә галимнәр һәм шагыйрьләр берничә телне белгән, алар үз әсәрләрен иске татар, гарәп һәм фарсы телләрендә язганнар. Ләкин язма мәдәният, нигездә, хәзерге татар

циальные ханские ярлыки, шедевры золотоордынской литературы XIV в. «Хосров и Ширин» Кутба, «Нахдж ал-фарадис» Махмуда ас-Сараи ал-Булгари, «Джумджума-султан» Хисама Кятиба, «Гюлистан бит-тюрки» Саифа Сараи.

Поэты и писатели эпохи Золотой Орды отстаивали земные добродетели, такие общечеловеческие качества, как справедливость, скромность, верность. Тюрко-татарский поэт Кутб утверждал, что движущей силой Вселенной является любовь, именно она придаёт смысл человеческой жизни. Для правителя же важнее всего быть справедливым и мудрым, стоять на страже правосудия, хорошо знать нужды и чаяния своего народа.

теленә бик якын булган кыпчак телендә үсеш алган. Ул телдә рәсми хан ярлыклары, XIV гасырның Алтын Урда әдәбияты шедеврлары – Котбнең «Хөсрәү вә Ширин», Мәхмүт әс-Сараи әл-Болгариның «Нәһҗ әл-фәрадис», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә-Солтан», Сәйф Сараиның «Гөлстан бит-төрки» китаплары язылган.



*Матрица для тиснения ювелирных изделий. XIV век. Найдена при раскопках Болгарского городища. Болгарский государственный историко- архитектурный музей-заповедник*

*Зәркән эшләнмәләр ясаганда басып (чокырлатып) бизәк төшерү матрицасы. Болгар шәһәрлегендә табылган.*
*© Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*

## Город Болгар – духовный өентр ислама в Золотой орде

Среди городов Золотой Орды Болгару принадлежит особое место. Русские летописцы величали его Великим. Именно в этом городе – первой столице формирующегося татарского государства – в течение некоторого времени, в 1240–1250-х гг., располагался административный центр государства Бату-хана. Здесь ханам, были созданы хорошие условия для приёма правителей других земель, а также русских князей, приезжающих за ярлыком на княжение, правом сбора дани и налогов с населения. Зиму ханы проводили обычно на Нижней Волге с более мягким климатом, где они начали 1250-ые гг строительство новой столицы Улуса Джучи – Сарай.

Столичный статус Болгара официально подтвердило начало выпуска в конце 1230-х – начале 1240-х гг. первых монет Золотой Орды, от имени великого монгольского хана. В 1260-х гг. монеты начали чеканить уже с именем золотоордынских ханов, что означало приобретение самостоятельности Улуса Джучи



*Р.М. Вагапов. Город Болгар в XIII–XIV веках. Реконструкция. Вид с севера*

## Болгар шәһәре – Алтын Урданың ислам рухи үзәге

Алтын Урда шәһәрләре арасында Болгар аерым урын алып тора. Рус елъязмачылары аны Бөек Болгар дип атаган. Нәкъ менә шушы шәһәрдә – яңа гына барлыкка килгән татар дәүләтенең беренче башкаласында – күпмедер вакыт дәвамында, якынча 1240–1250 нче елларда, Бату хан дәүләтенең административ үзәге урнашкан була. Бирегә ханнарга башка җирләрнең хакимнәрен, шулай ук кнзьлеккә ярлык артыннан килгән рус кнзьләрен кабул итү үткәрелә, халыктан салымнар җыю өчен уңай шартлар тудырыла.

Ханнар кышны, гадәттә, Түбән Иделдә, йомшаграк климатлы, ат һәм сарык көтүләре (күчмә халыкларның төп байлыгы!) дала киңлекләрендә азыкны җиңел таба торган урыннарда үткәргәннәр. Шунда ук 1250 нче елларда Җучи Олысының яңа башкаласына – Сарай әл-Мәхрүсәгә нигез салына.

1230 нчы еллар азагы – 1240 нчы еллар башында Болгарда Бөек Монгол ханы исеме белән Алтын Урданың беренче тәңкәләре сугыла. 1260 нчы елларда тәңкәләр



*Р.М. Вәһапов. XIII–XIV гасырларда Болгар. Реконструкция. Төньяк тарафтан күренеше*




*А. Шмидт. План Великого Града Болгар, древней столицы Болгарского царства. 1827. ГА РТ. Ф.200. Оп.1. Д.53. Л.2об.-3*

*А. Шмит. Болгар патшалыгы башкаласы. Бөек Болгар планы. 1827. Татарстан Республикасы дәүләт архивы. (Ф. 200, оп. 1, д. 53, л. 2 об.–3)*



*Монета с именем Ан-Насир ли-дин Аллаха Болгар. 1240-е годы. Волжская Булгария. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Насыйр-лид-Дин Аллаһ исеме язылган акча Болгар. 1240 еллар башы © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



*Монета Менгу-каана. Болгар. XIII век. Найдена при раскопках Болгарского городища. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Мәңге-каан акчасы. Болгар, XIII гасыр. Болгар шәһәрлеге казылмаларыннан. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



*Монета Ариг-Буга. Чекан Болгара. XIII век. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Ариг-Буга акчасы. Болгарда сугылган. XIII гасыр. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



*Монета Менгу-Тимура. Болгар. 786 г. х. Найдена при раскопках Болгарского городища. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Мәңге-Тимур акчалары. Болгар. Һиҗри белән 786 ел. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы.*



*Анонимная монета с тамгой Бату-хана. Болгар. XIII век. Найдена при раскопках Болгарского городища. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Бату-хан тамгасы белән аноним акча. Болгар © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



*Соборная мечеть в Болгаре. Графическая реконструкция*
*Болгарның Җәмигъ мәчете. График реконструкция*

и независимости его от монгольского имперского центра в Каракоруме.

После катастрофы 1236 г. Болгар быстро восстанавливается: засыпаются следы пожарищ и руины рухнувших строений, уничтожаются оборонительные стены, начинается интенсивное строительство жилых домов и крупных общественных зданий. Переселяются в новый город ремесленники, купцы и государственные чиновники. В центральной части города закладывается белокаменная Соборная мечеть и формируется административный и торговый центр города.

Юго-восточные районы Болгара у Малого минарета застраиваются богатыми кирпичными домами с подпольными системами отопления и представляли собой места, где проживала городская знать. В городе возникают новые ремесленные районы: слободы металлургов и кузнецов, гончаров и кожевников. В западном и северо-западном районах Болгара функционировали многочисленные ремесла – металлургические, гончарные, меднолитейные, ювелирные. Налаживается производство чугуна, возрождаются стеклоделие и ювелирное дело. Большой концентрацией производственных комплексов отличается район Галанского озера. Многочисленные находки обломков болгарской посуды, керамических



*Часть интерьера Соборной мечети. Вид на южную стену с минбаром и михрабной нишей. Графическая реконструкция*

*Җәмигъ мәчете интерьерының бер өлеше. Минбар һәм михраб урнашкан көньяк дивары. График реконструкция*

Алтын Урда ханнары исеме белән чыга башлый, бу исә Жучи Олусының мөстәкыйльлеген һәм аның Каракорумдагы империя үзәгеннән бәйсезлеген аңлаткан.

1236 елгы фаҗигадән соң Болгар тиз арада торгызыла: янгын эзләре (көл-күмер катламы) һәм җимерелгән корылмаларның харәбәләре күмелә, элеккеге шәһәр ныгытмаларын сүтеп ташлыйлар, яңаларын төзергә тотыналар. Гомумән, шәһәрдә зур төзелеш башлана, яңа торак йортлар һәм иҗтимагый биналар салалар. Яңа шәһәргә һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр, дәүләт түрәләре һәм хезмәткәрләре күченә. Шәһәрнең үзәк өлешендә ак таштан биек манаралы Җәмигъ мәчете калкып чыга, административ һәм сәүдә үзәге формалаша.

Болгарның көньяк-көнчыгышында, Кече манара янында, шәһәр аристократлары яшәгән, идән асты җылыту системасы булган бай кирпеч йортлар төзелә. Шәһәр читендәрәк яңа һөнәрчелек районнары – металлурглар һәм тимерчеләр, чүлмәкчеләр һәм күнчеләр бистәсе



*Находки из слоя базара: гирьки, чашечка от торговых весов, монетный клад (по В.Ю. Ковалю и Д.Ю. Бадееву)*

*Болгар хәрабәләрен казыганда чыккан табылдыклар: герләр, үлчәү тәлинкәсе, акча хәзинәсе (В.Ю. Коваль, Д.Ю. Бадеев буенча)*

родного торгового центра на Великом Волжском пути.

Центральный рынок, построенный в первой половине XIV в. в самом городе, находился в районе Соборной мечети, в 150 м к юго-западу от неё. Судя по археологическим данным последних лет, он представлял собою довольно крупное здание (36×36 м) с небольшой толщиной стен с межкомнатными перегородками. К главному входу с северо-восточной стороны подходит широкая торговая улица с оградами из обожжённого кирпича. Характер находок – весы и гирьки, горнов дают возможность предположить, что здесь было сосредоточено массовое гончарное производство в период расцвета города в середине XIV в. Таким образом, Болгар превращается в город ремесленников, одновременно сохраняя за собой прежнюю славу крупнейшего междуна-




*Центральный базар. План раскопок (по В.Ю. Ковалю и Д.Ю. Бадееву)*

*Үзәк базар. Казылмалар планы (В.Ю. Коваль, Д.Ю. Бадеев буенча)*



*Раскопки центрального городского базара Болгара*
*Шәһәрнең Үзәк базарында казу эшләре*

барлыкка килә. Болгарның көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш өлешләрендә күпсанлы һөнәрчеләр металлургия, чүлмәкчелек, бакыр кою, зәркәнчелек эшләре белән шөгыльләнгәннәр. Чуен җитештерү җайга салына, пыяла ясау һәм зәркән (ювелирлык) эше яңадан торгызыла. Галан күле тирәсендәге бистә сәнәгать комплексларының күп булуы белән аерылып торган. Болгар савыт-сабасы, керамик мич калдыкларының күпсанлы табылдыклары биредә XIV гасыр уртасында, шәһәрнең чәчәк аткан чорында күпләп чүлмәкчелек әйберләре җитештерелүен фаразларга мөмкинлек бирә. Шулай итеп, Болгар һөнәрчеләр шәһәренә әверелә, бер үк вакытта, Бөек Идел юлында эре халыкара сәүдә үзәге булып, элеккеге данын саклап кала.

XIV гасырның беренче яртысында барлыкка килгән Үзәк базар шәһәрнең үзәгендә, Җәмигъ мәчеттәннән көньяк-көнбатышка таба 150 метр ераклыкта урнашкан. Соңгы еллардагы археологик мәгълүматларга караганда, ул шактый зур бина (36×36 м) булып күз алдына килеп баса. Төньяк-көнчыгыш ягыннан төп керү юлына яндырылган кирпечтән куелган коймалары белән киң сәүдә урамы килеп тоташа. Табылдыкларның үзенчәлеге – үлчәүләр һәм герләр, кургаш һәм бронза товар пломбалары (алар арасында Көнбатыш Европа пломбалары да бар), көмеш һәм алтын кисәкләре, күп санлы көмеш һәм бакыр тәңкәләр, йозаклар һәм тимер рәшәткә ватыклары – барысы да бу базар аеруча кыйммәтле товарлар: зәркән бизәнү әйберләре, Европа тукымалары, импорт савыт-саба белән сәүдә итү өчен билгеләнгән дигән фикерне раслый.



*Церковь Сурб Аствацацин в монастыре Норванк – возможный прототип Греческой палаты в Болгаре. 1339*

*Норванк монастырендагы Сурб Аствацацин чиркәве – Болгардагы Грек пулатының фаразлана торган прототибы. 1339*

свинцовые и бронзовые товарные пломбы, среди которых много западноевропейских, слитки серебра и золота, большое количество серебряных и медных монет, замки и фрагменты оконных решёток из железа – указывает на то, что этот рынок предназначался для торговли особо ценными товарами: ювелирными украшениями, европейскими тканями, импортной посудой. К сожалению, рынок просуществовал относительно недолгое время, будучи уничтоженным, вероятно, во время большого пожара, возникшего при взятии Булат-Тимуром города в 1361 г.

Возрождение экономики и заметное оживление политической жизни региона вызвали прилив населения в город, остро нуждающийся в рабочей силе. Последствием этого стало почти пятикратное (по сравнению с домонгольским временем) увеличение территории города. В период своего расцвета он занимал площадь более 400 га. В пригородных посёлках жили иностранные купцы, ремесленники и мастера-строители, которые в чуждой им мусульманской среде не испытывали особых неудобств. Археологические находки иллюстрируют торговые связи Болгара с различными регионами Евра-




*А. Шмит. Развалины Греческой палаты. Рисунок из альбома 1832 года*
*Грек пулаты хәрабәләре. Иллюстрация китаптан:*
*Архитектурные чертежи развалин древних Болгар. Сняты с натуры в 1827 г. архитектором А. Шмитом. СПб., 1832*

(Кызганычка каршы, базар кыска гомерле булып чыга – 1361 елда Булат Тимер шәһәргә басып кергән мәлдә, зур янгын вакытында юк ителгән булырга мөмкин).

Икътисадның яңарышы һәм төбәкнең сәяси тормышы сизелерлек җанлану халыкның эшче көчләргә бик тә мохтаҗ шәһәргә күпләп килеп төпләнүенә сәбәп була. Моның нәтиҗәсе – шәһәр территориясенең монголларга кадәрге чор белән чагыштырганда биш тапкырга диярлек киңәюе. Аның чәчәк атып яшәгән чордагы мәйданы якынча 400 гектарга җитә. Шәһәр яны бистәләрендә чит ил сәүдәгәрләре, һөнәрчеләр һәм төзүчеләр яшәгән һәм болгарлар алар өчен ят мөселман мохитендә уңайсызлыклар тудырмаска тырышканнар.

Болгар Евразиянең төрле төбәкләре: Түбән Идел һәм Кырым шәһәрләре, Балтыйк буе илләре, Иран һәм Урта Азия, Русь һәм Византия, Һиндстан һәм Кытай белән сәүдә итә. Шәһәрнең культура катламы чит ил әйберләренә бай: Кытайдан, Ираннан һәм Хәрәземнән фарфор һәм селадон савыт-саба, Венеция, Сүрия һәм Мисыр һөнәрчелек остаханәләрендә җитештерелгән пыяла эшләнмәләр, Балтыйк диңгезе ярларыннан гәрәбә, Һинд океаны утраула-



*Чаша селадоновая. Китай или Корея. XIV век (по А.М. Губайдуллину и И.В. Волкову)*

*Болгар казылмаларыннан селадон касә. Кытай яисә Корея. XIV гасыр (А.М. Гобәйдуллин, И.В. Волков буенча)*

зии: нижневолжскими и крымскими городами Золотой Орды, Ираном и Средней Азией, Русью и Византией, Индией и Китаем. Культурный слой городища насыщен предметами импорта: парадной поливной посудой из Ирана и Хорезма, фарфоровыми пиалами и селадоновыми вазами из Китая, изделиями из художественного стекла, произведёнными в ремесленных мастерских Венеции, Сирии и Египта, экзотическими раковинами с островов Индийского океана. Восточные купцы, приезжающие на весенне-летние ярмарки, проживали в караван-сараях, один из которых, известный под названием «Малый городок», археологически исследован у южных ворот городища

Во все времена торговля между странами велась не только ради прибыли она способствовала обмену новыми технологиями в области ремесленного производства, важными достижениями в других областях материальной и духовной культуры. Благодаря международной торговле мир уже тогда составлял определённое пространственное и информационное единство. В создании этого евразийского единства в эпоху средневековья важную роль играл город Болгар, на ярмарках которого встречались представители многих стран, жаждущие не только накопить богатство, но и обогащаться духовно, расширяя свой кругозор за счёт новой информации, собираемой иногда и по заказу своих покровителей.

Поликультурность и многоконфессиональность, были неотъемле-



*Фрагмент расписного поливного сосуда. Китай. Вторая половина XIII–XIV век (по М.Д. Полубояриновой)*

*Рәсемле глазурь савыт фрагменты. Кытай, XIII–XIV гасырлар (М.Д. Полубояринова буенча)*



*Амфора. Византия или владения крестоносцев на острове Хиос. XIII–IV века (по А.М. Губайдуллину и И.В. Волкову)*

*Амфора. Византия яисә Хиос утравындагы тәре йөртүчеләр биләмәсе. XIII–XIV гасырлар (А.М. Гобәйдуллин, И.В. Волков буенча)*



*Чаша с росписью «минаи». Иран. XIV век (по В.Ю. Ковалю и Д.Ю. Бадееву)*

*«Минаи» тибындагы бизәкле касә. Иран. XIV гасыр (В.Ю. Коваль, Д.Ю. Бадеев буенча)*

мой частью духовной жизни Золотой Орды. Болгар характеризуется непрерывной преемственностью историко-культурных традиций, которые сохранялись здесь на протяжении многих столетий. Выражением этого является и мирное сосуществование разных религий в пределах одного города. Среди местного населения встречаются и представители и других конфессий. Примерами служат и отдельные находки христианской культуры в постройках за пределами городских стен. В северо-западной части к городу примыкала Армянская слобода, возникшая как пригородный поселок. Археологами выявлены свидетельства существования здесь в XIV в. торговой колонии и остатки каменной христианской культовой постройки, получившей название «Греческая палата». Обнаруженные в ходе изучения города зримые материальные объекты – это яркое свидетельство взаимовлияния религиозных ценностей в Болгаре и уважительного отношения мусульманского населения города к представителям других религий.

В золотоордынский период в Болгаре сложился свой архитектурный стиль, основанный на местных строительных материалах, исламских традициях строительства. Каменные здания мечетей, минаретов, мавзолеев и бань не только определили облик города Болгара в XIII–XV вв., но также повлияли на архитектуру соседних регионов и Казанского ханства. Даже после того как жизнь в городе Болгаре угасла, воспоминание о его архитектуре сохранилось




*Ханский дворец.*
*Общий план раскопов*
*(по Р.Ф. Шарифуллину)*

*Болгар. Хан сарае. Казылмаларның гомуми планы*
*(Р.Ф. Шәрифуллин буенча)*

рыннан килгән экзотик кабырчыклар (каури) – барысы да бар. Язгы-җәйге ярминкәләргә килгән чит ил сәүдәгәрләре кәрван-сарайда яшәгәннәр. Шуларның берсе, «Кече шәһәр» дип аталганы, Болгарның көньяк капкасы янында урнашкан була, ул соңгы елларда археологлар тарафыннан җентекләп өйрәнелде.

Сәүдә, әлбәттә, табыш алу өчен алып барыла. Шул ук вакытта аның башка төрле функцияләре дә булган: сәүдәгәрләр бер-берләре белән тегеяки бу илдә барган сәяси вакыйгалар, фән һәм мәдәният өлкәсендәге мөһим казанышлар турында фикер алышканнар, һөнәрчелек өлкәсендә барлыкка килгән яңа технологияләр дә игътибардан читтә калмаган. Кыскасы, һәр сәүдәгәр үзенә күрә бер информация чыганагы булган. Шунысын да онытмыйк: алар үзләре белән бик кыйммәтле товар – китаплар да алып килгәннәр. Алар махсус заказ буенча китерелгәннәр, яисә ачык сатуга куелганнар. Болгарлар, билгеле булганча, Сәмәркандтан китерелгән кәгазьгә язганнар.

Халыкара сәүдә ярдәмендә урта гасырлар дөньясы киңлек (пространство) һәм мәгълүмати бердәмлек тәшкил иткән. Әлеге Евразия бердәмлеген булдыруда байлык тупларга гына түгел, үзләрен рухи яктан да баетырга теләгән чит ил вәкилләрен очраштырган кунакчыл Болгар да мөһим роль уйнаган.

Күпмәдәниятлелек һәм күпконфессиялелек Алтын Урда рухи тормышының аерылгысыз өлешенә әверелә. Болгар тарихи-мәдәни традицияләрнең өзлексез дәвамлылыгы белән аерылып тора. Бу шулай ук бер шәһәр эчендә төрле диннәрнең

*Ханский дворец. Графическая реконструкция*
*Хан сарае. График реконструкция*



в татарских народных преданиях, тюрко-татарском эпосе «Идегей», а руины зданий совместно с окружающим ландшафтом стали местом религиозного поклонения, эстетического любования, а затем и научного изучения.

* * *

В середине XIV в. Болгар числился в ряду не только крупнейших, но и самых благоустроенных и красивых городов Золотой Орды. С первых лет после покорения монголами булгарских земель с большим размахом началось строительство культовых мусульманских сооружений, других общественных зданий из камня и кирпича, в архитектуре которых булгарские зодчие придерживались ближневосточных, мусульманских традиций, но одновременно предложили немало оригинальных решений, обусловленных природно-климатическими особенностями региона.

Самую большую группу архитектурных сооружений составляют каменные общественные здания, мавзолеи и городские бани. На территории Болгарского городища выявлено и исследовано к настоящему времени около трех десятков монументальных построек. Особое место принадлежит погребальным сооружениям – мавзолеям – дюрбе. Во второй половине XIV в. наблюдается увеличение числа некрополей в южных районах города, на которых возводились из камня погребальные

*Консервация юго-восточного помещения Ханского дворца*
*Хан сараеның консервацияләнгән көньяк-көнчыгыш өлеше*





*Проект музеефикации объекта с использованием защитного купола из поликарбоната*
*Поликорбанаттан эшләнгән саклау гөмбәзе белән объектны музейлаштыру проекты*

тату яшәвендә дә чагылыш таба. Мөселман халкы арасында башка дин вәкилләре дә очрый. Шәһәр диварларыннан читтәге корылмаларда табылган христиан мәдәниятенә караган артефактлар да моңа мисал булып тора. Шәһәрнең төньяк-көнбатыш өлешенә шәһәр яны торагы булarак барлыкка килгән әрмән бистәсе килеп тоташкан. Археологлар бирედә XIV гасырда сәүдә колониясе булуын күрсәтүче дәлилләргә һәм «Грек палатасы» дип аталган христиан диненә караган таш корылма калдыкларына тап булганнар иде. Шәһәрне өйрәнү барышында табылган матди объектлар Болгардагы диннәрнең үзара бәйләнеше һәм шәһәр мөселман халкының башка дин вәкилләренә хөрмәт белән карауларын ачык күрсәтә.

Алтын Урда чорында Болгарда җирле төзелеш материалларына, Ислам кануннарына нигезләнгән архитектура стиле барлыкка килә. Мәчетләр, манаралар, төрбәләр һәм мунчаларның таш биналары XIII–XV гасырларда Болгар шәһәренең тышкы кыяфәтен генә билгеләп калмыйча, күрше өлкәләрнең һәм Казан ханлыгының архитектурасына да йогынты ясый. Хәтта Болгар шәһәрендә тормыш сүрелгәннән соң да, аның архитектурасы турындагы истәлекләр татар халык риваятьләрендә һәм «Идегәй» төрки-татар дастанында яшәп кала бирде, ә биналарның харәбәләре, тирә-юньдәге ландшафт белән бергә, гыйбадәт кылу, эстетик соклану һәм соңрак фәнни-тикшеренү урынына әйләнде.



*Н.Г. и Г.Г. Чернецовы. Соборная мечеть и Большой минарет. 1838*
*Ил. из кн.: «Воспоминания из путешествия по Волге». 1862*
*Н.Г. һәм Г.Г. Чернецовлар. Җәмигъ мәчете һәм Олы манара. 1838*
*Иллюстрация китаптан: Воспоминания из путешествия по Волге. 1862*

постройки. Кроме Восточного и Северного мавзолеев, Ханской усыпальницы, выявлено археологами еще 9 мавзолеев, сохранившихся на уровне фундаментов, и 4 мавзолея, остаются скрытыми под холмами над местами их разрушений. Большинство мавзолеи Болгара построены из известняка в середине XIV – начале XV в. Найденные и исследованные в них захоронения свидетельствуют, что это мусульманские погребения знатных и особо почитаемых лиц. В целом среди всех каменных архитектурных объектов на территории городища выделяются Соборная мечеть с Большим минаретом, руины Ханского дворца, «Чёрная палата» и Малый минарет с рядом расположенной ханской усыпальницей.

***Ханский дворец*** – резиденция Батыя – хана Золотой Орды, располагался на северном краю высокой надпойменной террасы реки Волги. Руины этой крупной кирпично-каменной постройки размерами 27×29 м по внутреннему периметру исследовались в 1996–2011 гг. Высота сохранившейся части кладки достигала в южной части более 2 м. Фундамент здания толщиной 1,5 м сложен из бутового камня, а стены возведены из хорошо обожжённого квадратного кирпича с обкладкой фасадов тёсаными, тщательно отесанными известняковыми блоками. Юго-западный и юго-восточный углы здания сохранили основания круглых в плане пилонов-башен из специально обработанных блоков. Богатство



*П.С. Паллас (1741–1811) Гравюра по рисунку Амбруаза Тардье. XVIII век*

*П.С. Паллас (1741–1811). Амбруаза Тардье рәсеме буенча гравюра. XVIII гасыр*

* * *

Әйтеп узганыбызча, XIV гасыр урталарында Болгар Алтын Урданың иң зур шәһәрләре генә түгел, ә иң төзек һәм матур калалары рәтендә йөргән. Болгар җирләрен монголлар яулап алганнан соң, беренче еллардан ук зур колач белән мөселман гыйбадәт кылу корылмалары, таштан һәм кирпечтән башка җәмәгать биналары төзелә башлый. Аларның архитектурасында болгар төзүчеләре Якын Көнчыгыш, Урта Азия мөселман традицияләренә таянганнар, ләкин бер үк вакытта төбәкнең табигый-климат үзенчәлекләренә бәйле күп кенә оригиналь яңалыклар да тәкъдим иткәннәр.

Болгар шәһәре территориясендә XVIII йөз сәяхәтчеләре 70 кә якын бина харәбәләре санаганнар. Архитектура корылмаларының иң зур төркемен таш җәмәгать биналары, мавзолейлар һәм шәһәр мунчалары тәшкил итә. Хәзерге вакытта өч дистәдән артык монументаль корылма тикшерелгән. Мавзолейлар – төрбәләр аерым урын алып торалар. XIV гасырның икенче яртысында шәһәрнең көньяк өлешендә таштан корылган каберлекләр – некропольләр саны артуы күзәтелә. Көнчыгыш, Төньяк мавзолейларыннан һәм Хан төрбәсеннән тыш, археологлар фундамент биеклегендә сакланган тагын 9 төрбәне табалар, ә 4 төрбә исә җимерелгән урында калкулыклар астында күмелгән. Болгар төрбәләренең күпчелеге бурташтан (известь) XIV гасыр уртасында – XV гасыр башында төзелгән. Төрбәләрдә табылган һәм тикшерелгән каберләрдә мөселман югары катлау вәкилләре яисә аеруча хөрмәтле затлар күмелгәне ачыкланды. Гомумән алганда, шәһәрлектә барлык таш архитектура объектлары арасында биек манаралы Җәмигъ мәчете, Хан сарае харәбәләре, «Кара пулат» һәм Хан төрбәсе янында урнашкан Кече манара аерылып тора.

***Хан сарае*** – Алтын Урда ханы Батуның резиденциясе, Идел үзәненең биек террасасында, хәзерге шәһәрлекнең төньягында урнашкан. Эчке периметр буенча 27×29 метрлы әлеге зур кирпеч-таш корылма харәбәләре Болгар археология экспедициясе тарафыннан 1996–2011 нче елларда тикшерелгән. Бина начар сакланган. Сакланып калган стеналарның биеклеге көньяк өлешендә 2 метрдан артмый. Бинаның 1,5 метр калынлыктагы нигезе ак таштан салынган, стеналары яхшы яндырылган квадрат кирпечләрдән өелгән, ә фасад ягы җентекләп шомартылган известь блоклар белән капланган. Бинаның



*Раскопки у северной стены Соборной мечети. Фотография 1964 года*
*Җәмигъ мәчетенең төньяк өлешендә казу эшләре. 1964 елгы фотография*

дома подчёркивают большое количество монет, значительная часть которых чеканена в 1240–1259 гг., привозная (из Китая и городов Ближнего Востока) посуда, в том числе и стеклянная, другие предметы, обнаруженные во время раскопок.

Консервация выявленных при раскопках частей здания производилась в 2012–2013 гг. По рекомендации ЮНЕСКО для защиты этого уникального архитектурного памятника использованы современные технологии. В настоящее время над законсервированным фундаментом сооружения возведён защитный купол.

***Джами (Соборная) мечеть*** – одно из первых по времени строительства монументальное каменное сооружение Болгара сразу после монгольского завоевания в 1240-ые годы. Возведённая на центральной площади, в районе, где находился административный и торговый центр, Джами (Соборная) мечеть с высоким трёхъярусным минаретом стала подлинным украшением города. Она возвышалась над всеми городскими зданиями.

В конце XIII в. Соборная мечеть подверглась реконструкции: на некоторых участках производилась замена кладки стен, укладывался новый пол, вдоль западной и северной стен поставили дополнительные восьмигранные колонны, поддерживающие антресольную галерею, все старые колонны заменили более тонкими, восьмигранными. По западному и восточному фасадам появились декоративные ниши.

Вторичная реконструкция мечети произошла в начале XIV в., когда ко всем четырём углам здания пристроили двенадцатигранные крепостные башни, выполнявшие одновременно роль контрфорсов для повышения устойчивости стен, на которые в нашей зоне возрастала нагрузка в зимнее время из-за снежного покрова на крышу здания. Кроме того, перепланировали внутренние опоры



көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш почмакларында махсус эшкәртелгән блоклардан ясалган түгәрәк пилон-башняларның нигезләре сакланып калган. Йортның байлыгын казулар вакытында табылган күп сандагы көмеш акчалар күрсәтеп тора. Аларның шактый өлеше 1240–1259 нчы елларда сугылган. Табылдыклар арасында, Кытайдан һәм Якын Көнчыгыш шәһәрләреннән китерелгән кыйммәтле савыт-саба ватыклары (пыяладан эшләнгәннәре дә күп), бизәнү әйберләре, сугыш кораллары бар.

Бинаның сакланып калган өлешләрен консервацияләү (өлешчә реставрацияләү юлы белән) 2012–2013 нче елларда башкарылды. ЮНЕСКО тәкъдиме буенча әлеге уникаль архитектура һәйкәлен саклау өчен заманча технологияләр кулланылды. Корылманың реставрацияләнгән фундаменты өстенә саклагыч гөмбәз куелды. Нәтиҗәдә ул туристларның яратып карый торган объектына әверелде.

***Җәмигъ мәчете*** – төзелү вакыты буенча Болгарның монументаль таш корылмалары арасында беренчеләрдән булып тора, ул 1240 елларда монголлар яулап алганнан соң ук салына. Шәһәрнең Үзәк мәйданында, административ биналар һәм сәүдә үзәге урнашкан җирдә калкып чыккан биек манаралы бу мәчет әле хәзер дә болгар архитектурасының чын бизәге булып тора.

XIII гасыр ахырында Җәмигъ мәчете реконструкцияләнә: кайбер урыннарда стеналарын алыштыралар, яңа идән салына, көнбатыш һәм төньяк стеналар буйлап антресоль галереясен күтәреп торырга ярдәм итүгә исәпләнгән өстәмә сигез кырлы колонналар куела, иске колонналарның барысын да бераз нечкәртеп, сигез кырлы итеп үзгәртәләр. Көнбатыш һәм Көнчыгыш фасадлар буенча декоратив нишалар – уемнар ясала.

Мәчетнең икенчел реконструкциясе XIV гасыр башында үткәрелә: бинаның дүрт почмагына да диварларның ныклыгын арттыру өчен контрфорс ролен башкаручы унике кырлы крепость башнялары утыртып куялар. Моннан тыш, эчке терәкләрне дә ныгыталар: алты рәтнең һәрберсендә алты колонна барлыкка килә, өч ишек янына эчке тамбурлар ясала. Стеналарны тагын бер мәртәбә штукатурлыйлар, кайбер урыннарга майолик (ялтыравыклы, эмаль белән капланган плитә) һәм изразец (балчык-керамик) плитәләр ябыштырып куялар.

Шул кыяфәттә Җәмигъ мәчете халыкка 1431 нче елга кадәр, Болгарга Фёдор Пёстрый исемле рус воеводасы җимергеч яу белән килгәнче хезмәт итә. Бу яу нәтиҗәсендә шәһәр үзенең элеккеге данын-кодрәтен югалта һәм түбәнгә тәгәри башлый. Әмма мәчет әле нигезенә кадәр җимерелеп бетмәгән, мөселман халкы,



*Соборная мечеть и Большой минарет со стороны восточного фасада после консервационных работ. Фотография начала 2000-х годов*

*Җәмигъ мәчете һәм Олы манара реставрациядән соң. 2000нче еллар*

(шесть колонн в шести рядах), появились внутренние тамбуры ко всем трём входам. В очередной раз оштукатурили стены, некоторые участки их были отделаны майоликовыми и изразцовыми плитками.

В таком облике Джами-мечеть исправно служила мусульманам до 1431 г., когда на Болгар был совершён разорительный поход русского воеводы Фёдора Пёстрого. В результате город потерял свою былую славу и начал клониться к упадку. Однако мечеть не была разрушена до основания и охранялась немногочисленным мусульманским населением, которое продолжало обитать в полуразрушенном городе и поддерживать сакральные погребальные постройки.

Руины этого здания давно привлекали внимание учёных. Самое раннее и довольно подробное описание их принадлежит члену Российской академии наук известному путешественнику второй половины XVIII в. П.С. Палласу: *«Сие здание состоит из неровных худо отёсанных, но весьма плотно складенных известковых диких и гипсовых камней, которые уповательно браны в гористом береге Волги <...> Знатнейшая из оных башня [Большой минарет] сделана из отёсанных камней несколько выше 12 сажень [26 м]. На оную всходят по круглой лестнице о 72 ступенях*



*Строительный блок оформления Соборной мечети. Известняк. Вторая половина XIII–XIV век. Болгарское городище. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Җәмигъ мәчетенең эчен бизәгәндә кулланылган төзелеш блогы. Бурташ. XIII–XIV йөзләр © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*

болгарлар, ярымҗимерек шәһәрдә яшәвен дәвам иткән һәм үз мәчетен саклап кала алган.

Әлеге бинаның харәбәләре галимнәр игътибарын күптән җәлеп итеп торган. Аларның иң әүвәлге һәм шактый җентекле тасвирламасы Россия Фәннәр академиясе әгъзасы, XVIII гасырның танылган сәяхәтчесе П.С. Паллас кулы белән язылган: *«Сие здание состоит из неровных худо отёсанных, но весьма плотно складенных известковых диких и гипсовых камней, которые уповательно браны в гористом береге Волги <...> Знатнейшая из оных башня [Большой минарет] сделана из отёсанных камней несколько выше 12 сажень [26 м]. На оную всходят по круглой лестнице о 72 ступенях <…> Двери в башню сделаны на полуденной [южной] стороне, и видны в стене большие железные крючья, на которых дверь висела. В стенах башни оставлены небольшие скважины, в которые свет проходит, и потому видно ходить по лестнице»*. П.С. Паллас фикеренчә, «кайчандыр бу харәбәләр урынында, бәлки, зур мәчет булгандыр». Соңрак әлеге бинаны «калын таш стеналар белән ныгытылган замок – солтан яки хан торагы», яисә «манаралы Хан сарае» булмады микән дип фараз кылучылар да табыла. 1892 нче елда



*Капитель колонны Соборной мечети. Известняк. Болгарское городище. XIV век. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Җәмигъ мәчетенең колонна капителе. XIV гасыр © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*

<…> *Двери в башню сделаны на полуденной [южной] стороне, и видны в стене большие железные крючья, на которых дверь висела. В стенах башни оставлены небольшие скважины, в которые свет проходит, и потому видно ходить по лестнице».* По мнению П.С. Палласа, здание, «может быть, представляло большую мечеть». Позднее были высказаны предположения о функциональном назначении этого здания в качестве «укреплённого замка, обнесённого толстыми стенами, где было жилище султана или хана», «ханского дворца с минаретом». Согласно заключению членов археологической комиссии, занимавшихся раскопками руин «Четырёхугольника» в 1892 г., памятник «ближе всего напоминает собой остатки медресе».

Точку на этом вопросе поставили археологические исследования, проведённые под руководством А.П. Смирнова в 1964–1970 гг. Выяснилось, что первоначально здание имело прямоугольную в плане форму (32×34 м) с пятью рядами четырёхгранных колонн, несущих аркаду и деревянную крышу. Котлован фундамента имел глубину 2 метра. Стены были сложены из белого бутового камня и укреплены дубовыми связями. К северному фасаду примыкали арочный портал входа и минарет высотой 24 метра, с винтовой лестницей, освещаемой шестью небольшими окнами. С южной стороны молельного зала размещалась михрабная ниша, стены которой были украшены богатой орнаментальной резьбой. В декоративном оформлении дверных и оконных проёмов, капителей и колонн также была использована резьба по камню. Зал освещался окнами, располагавшимися на уровне арок.

24-метровый Большой минарет имел, по свидетельствам и иконографическим документам XVIII–XIX вв., значительное сходство с сохранившимся Малым минаретом,



***А.П. Смирнов Фотография 1960-х годов***
***А.П. Смирнов (1899–1974) 1960 еллар фотосы***

но был в два раза выше последнего и имел резные арабские надписи на фасаде. Рухнул в 1841 г., и камни были растасканы местными жителями на хозяйственные нужды. Профессор Казанского университета известный российский востоковед И.Н. Березин писал: *«Ныне большой столб, т.е. минарет, уже не существует, остатки его лежат на месте падения. В 1846 году проездом через бул-*



*Реставрация одного из оконных проемов западной стены Соборной мечети в Болгаре*

*Җәмигъ мәчетенең көнбатыш диварындагы тәрәзә уемы реставрациядән соң*

*гарскую местность я видел несколько камней с надписью из Алькурана, принадлежавшии упавшему минарету»*.

На основании анализа историко-литературных и иконографических материалов Н.И. Савинкова и И. Крапивина (1732), В.Н. Татищева (1730-е), Г.Р. Державина (1761), А.М. Свечина (1762), П.С. Палласа (1768), И.И. Лепёхина (1767), Н.И. Кафтанникова (1819), П.П. Свиньина (1823), Ф.Х. Эрдмана (1825), Э. Турнерелли (1837), Г.Г. и Н.Г. Черневцовых (1838), А. Дюранда (1839), И.И. Второва (1840), альбома архитектора А. Шмита «Архитектурные чертежи развалин древних Болгар, снятые с натуры в 1827 г.» был разработан проект воссоздания Большого минарета Соборной мечети, реализованный в 2000 году.

Восстановление минарета осуществлялось на историческом фундаменте. Восстановление Большого минарета улучшило общее восприятие комплекса, обеспечило целостность и потенциальное единство с Соборной мечетью, Северным и Восточным мавзолеями.

В результате проведенного сравнительного анализа установлено, что по материалу кладки, техническим и декоративным приёмам болгарская Соборная мечеть с Большим минаретом ближе к каменным постройкам Закавказья, Крыма, Малой Азии, Северной Месопотамии. В то же время в архитектуре данной мечети, особенно в её позднейшем облике, нашли отражение объёмно-композиционные черты, присущие постройкам Средней Азии золотоордынского периода, а также местные традиционные приёмы, использованные при строительстве Соборной мечети в Биляре и




***Большой минарет.***
***Ил. из альбома А. Шмита 1832 года***

***Олы манара. Иллюстрация китаптан:***
***Архитектурные чертежи развалин древних Болгар. Сняты с натуры в 1827 г. архитектором А. Шмитом. СПб., 1832***



*И.Н. Березин*

«Дүртпочмак» харәбәләрен казу белән шөгыльләнгән археология комиссиясе әгъзалары бәяләмәсе буенча, «тикшерелгән бина барыннан да бигрәк мәдрәсә калдыкларына охшаган» .

1964–1970 нче елларда А.П. Смирнов җитәкчелегендә үткәрелгән археологик тикшеренүләр бу мәсьәләгә нокта куйды. Бинаның башта түбәне күтәреп торучы биш рәт булып урнашкан колонналы залдан гыйбарәт турыпочмаклы (32×34 м) таш корылма булуы ачыкланды. Нигез чокыры 2 метр тирәнлектә. Стеналар ак таштан өелгән. Төньяк фасадка керү порталы тоташкан һәм шул якта ук 24 метр биеклектәге манара урнаштырылган. Манараның алты кечкенә тәрәзәсе булган, югарыга әйләнгеч (винтовой) баскычтан күтәрелгәннәр. Намаз залының көньяк стенасында михраб нишасы урнашкан, аның стеналары уеп ясалган орнаменталь бизәк эзләрен саклаган. Ишек һәм тәрәзә уемнары, капительләр һәм колонналарның декоратив бизәлешендә шулай ук ташны уеп ясалган орнаментлар кулланылган. Зал аркалар биеклегендә урнашкан тәрәзәләр белән яктыртылган.

XVIII–XIX гасырлардан калган иконографик документларга караганда, Җәмигъ мәчетенең 24 метрлы Олы манарасы бүгенге көннәргә кадәр яхшы сакланган Кече манарага бик охшаш, әмма соңгысыннан ике тапкыр биегрәк һәм фасадына уеп эшләнгән гарәп язулары белән генә аерылып торган. 1841 нче елда Олы манара җимерелә, ташларын җирле халык тиз арада хуҗалыкта куллану өчен ташып бетерә. Казан университеты профессоры, танылган рус шәрыкчесе И.Н. Березин: «хәзер Олы манара юк инде, аның калдыклары шул җимерелгән урынында ята. 1846 нчы елда, мин Болгар җиреннән үтеп барышлый, әл-Коръәннән алынган язулы берничә таш күрдем», – дип язып калдырган.

Н.И. Савинков һәм И. Крапивин (1732), В.Н. Татищев (1730), Г.Р. Державин (1761), А.М. Свечин (1762), П.С. Паллас (1768), И.И. Лепехин (1767), Н.И. Кафтанников (1819), П.П. Свиньин (1823), Ф.Х. Эрдман (1825), Э. Турнерелли (1837), Г.Г. һәм Н.Г. Чернецовлар (1838), А. Дюранд (1839), И.И. Второв (1840) кебек галимнәр калдырган рәсемнәр, тарихи-әдәби һәм иконографик материаллар, архитектор А. Шмитның «1827 елда натурадан төшерелгән «Борынгы Болгарның архитектура сызымнары» альбомы Җәмигъ мәчетенең Олы манарасын торгызу проекты нигезен тәшкил иттеләр. Ул проект 2000 елда тормышка ашырылды.





*Облик центрального архитектурного комплекса Болгарского заповедника после восстановления Большого минарета*

*Олы манара торгызылганнан соң Болгарда үзәк архитектура комплексы күренеше. 2000нче еллар*



Манара борынгы фундаментта торгызыла. Манараны торгызганда Сөйки ятмасыннан алынган (Болгар каршында Иделнең уң як ярында урнашкан Сөйки авылы янында) бурташ (известняк) файдаланылды. Комплексның барлык архитектура һәйкәлләре шул таштан төзелгән.

Чагыштыру нәтиҗәләре буенча, Җәмигъ мәчетенең төзелеш материалы, техник һәм декоратив алымнары Кавказ аръягы, Кырым, Кече Азия, Төньяк Месопотамиянең таш корылмаларына якын булуы ачыкланды. Шул ук вакытта бу мәчетнең архитектурасында, бигрәк тә аның соңгы «кыяфәтендә», Алтын Урда чорындагы Урта Азия корылмаларына хас күләмле-композицион сыйфатлар, Биләрдәге Җәмигъ мәчетен һәм Алабуга шәһәрендәге мәчетне төзегәндә кулланылган җирле традицион алымнар чагылыш тапкан. Гомумән алганда, Болгардагы һәйкәл архитектурасы Шәрык архитектурасының үзенчәлекле стилистик тармагын тәшкил итә.

Җәмигъ мәчете комплексына Болгарның мемориаль корылмалары – шәһәрнең аристократик катлау вәкилләре күмелгән ак ташлы төрбәләр (мавзолейлар) керә. Алар арасында шәһәрнең үзәк өлешендә урнашкан Көнчыгыш төрбә (монастырь чорында Изге Николай чиркәве буларак кулланылган) һәм Төньяк төрбә (монастырь чорында монастырь базы буларак кулланылган) иң атаклыларыннан санала.

***Көнчыгыш төрбә*** Җәмигъ мәчетенең көнчыгыш фасады каршында урнашкан. 1330 нчы елларда төзелгән әлеге бинадан XVIII гасыр башында Изге Николай чиркәвен ясыйлар, аның төп фасады көньяктан көнбатышка таба күчерелә, очына тимер хач утыртып куелган сөзәк түбәсе сигез кырлы итеп корыла. Чиркәү янында христиан зираты барлыкка килә, анда 1965–1966 еллардагы казу



*Восточный мавзолей – Церковь Св. Николая. Фотография 1960-х годов. На первом плане – юго-восточная башня Соборной мечети до проведения реставрационных работ*

*Көнчыгыш мавзолей – Изге Николай чиркәве. 1960 елларда төшерелгән фото. Алгы планда – Җәмигъ мәчетенең көньяк-көнчыгыш башнясы хәрабәләре реставрациягә кадәр*



*Крепость-мечеть в Елабуге. Современный вид*
*Алабугада мәчет хәрабәләре консервациядән соң. Бүгенге күренеше*

крепости-мечети в Елабуге. В целом архитектура исследуемого памятника составляет своеобразную стилистическую ветвь восточного зодчества, сложившегося в относительно пограничном с указанными странами географическом регионе Поволжья в золотоордынский период развития.

К комплексу Соборной мечети тяготеют архитектурные памятники Болгара, представленные мемориальными сооружениями – каменными белокаменными мавзолеями, являющимися некрополем аристократической верхушки города. Наиболее известными среди них являются Восточный мавзолей (в монастырский период использовалась как церковь Св. Николая) и Северный мавзолей (в монастырский период использовалась как Монастырский погреб), расположенные в центральной части города.

***Восточный мавзолей*** находится напротив восточного фасада Соборной мечети. Сооружённый в 1330-х гг., он в начале XVIII в. был превращён в церковь Святого Николая с перемещением главного фасада здания с юга на запад и устройством низкой восьмискатной деревянной кровли с главкой, увенчанной железным крестом. Рядом с церковью возникло православное кладбище, где раскопками



*С.С. Айдаров*

эшләре вакытында өч дистәдән артык XVIII–XIX гасырларга караган каберлек ачыла.

Бу төрбәнең элгәреге күренешен, беренчел йөзен реконструкцияләү галимнәргә аны фасад стенасыннан чыгып торган порталлы чатыр рәвешендә эшләнгән шәрык төрбәләре төркеменә кертеп карарга нигез бирде. Чиркәүгә әйләндергәнче, порталлы төп ишек көньякка юнәлтелгән була. Эчке өлеше, ягъни дога уку залының түшәме, ярымсфера рәвешендәге гөмбәз итеп эшләнгән. Өч яктан стенада тәрәзә уемнары бар. XVIII гасыр сәяхәтчеләре хәбәр итүенчә, төрбә эчендә «гарәпчә язулы кабер ташлары табылган».

Архитектура тарихы белгече профессор С.С. Айдаров фикеренчә, Көнчыгыш төрбә Урта Азия, Кырым һәм Кавказ мавзолейларына якын. Ул шулай ук Башкортстандагы Тура хан



***Мавзолей «Кэшэнэ» в Башкортостане***
***Башкортостанда Кэшэнэ төрбәсе***



*Восточный мавзолей*
*Көнчыгыш төрбә*

*«находимы были намогильные плиты с арапскими письменами»*.

По мнению известного историка архитектуры С.С. Айдарова, Восточный мавзолей по своей объёмно-планировочной структуре близок среднеазиатским, крымским и закавказским мавзолеям, а наиболшее сходство он обнаруживает с мавзолеем Тура-хана в Башкортостане, что подчеркивает формирование общемусульманского архитектурно-строительного культурного пространства Болгарского улуса.

В 1964–1966 гг. у наружных стен, а в начале 1990-х гг. внутри памятника производились археологические раскопки. Они показали, что Восточный мавзолей располагался на участке городища, застройка которого началась ещё в домонгольское время. Мавзолей возник на окраине мусульманского кладбища у Соборной мечети, некоторые погребения оказались под фундаментом здания. В раннезолотоордынское время здесь жили ремесленники, что подтверждается остатками металлургических и гончарных горнов.

Мавзолей являлся семейной усыпальницей знатного болгарского рода

1965–1966 гг. вскрыто более трёх десятков погребений XVIII–XIX вв.

Реконструкция первоначального облика этого мавзолея позволили учёным отнести его *«к типу восточных шатровых усыпальниц с выносным порталом и прямоугольным внутренним помещением, плавно переходящим, благодаря пирамидальным скосам-тромпам, в восьмигранный ярус изнутри и снаружи»* (С.С. Айдаров). До использования под церковь вход с портальной нишей был обращен на юг. Внутренне помещение имело крытый полусферический свод. С трёх сторон по центру размещались оконные проёмы стрельчато-арочной формы. По сообщениям путешественников XVIII в., внутри мавзолея



*Музеефикация археологического раскопа в интерьере Восточного мавзолея. 2012*
*Көнчыгыш төрбә эчендә археологик казулар вакытында табылган объектларны музейлаштыру. 2012*

мавзолеена аеруча охшаган, бу исә Болгар олысының гомуммөселман архитектура-төзелеш мәдәни киңлеге формалашуына ишарә ясый.

1964–1966 нчы елларда төрбәнең тышкы диварлары янында, ә 1990 нчы еллар башында аның эчендә археологик казу эшләре алып барыла. Алар Көнчыгыш төрбәнең шәһәрнең монгол яуларына кадәр үк үзләштерелгән борынгы өлешендә урнашуын күрсәттеләр. Мавзолей Җәмигъ мәчете янындагы мөселман зираты кырыенда төзелгән, кайбер каберләр бинаның фундаменты астында калган. Биредә һөнәрчеләр яшәгән. Алар Алтын Урда чорында да яшәүләрен дәвам итәләр, моны тимер кою һәм чүлмәк яндыру мичләренең калдыклары раслый.

Мавзолей болгар нәселеннән булган Бураш-бәкләрнең гаилә төрбәсе булган. Төрбәне тикшергәндә җиде таш кабер табылган. Мәрхүмнәр мөселманнарда кабул ителгән йолага туры китереп күмелгән.

***Төньяк мавзолей*** 1330 нчы елларда төзелгән. Озак вакытлар Успение монастыре монахлары аны нәүрәп – кар базы буларак файдаланганнар. Моннан әлеге Мавзолейның икенче исеме барлыкка килә – Монастырь базы.

Ул Җәмигъ мәчетенең төп фасады каршында урнашкан, шуңа күрә Көнчыгыш төрбәгә караганда зуррак һәм

Бураш-беков. При изучении внутри него было найдно семь каменных склепов. Умершие похоронены с соблюдением правил мусульманской погребальной традиции.

***Северный мавзолей,*** построенный в 1330-х гг., долгое время использовался монахами Успенского монастыря под погреб. Отсюда второе название этого мавзолея – Монастырский погреб.

Он располагался перед главным фасадом Соборной мечети, поэтому был крупнее и, судя по всему, наряднее, чем Восточный мавзолей. Но сохранился он хуже: до нас дошли фундаменты, стены с частью внутренней облицовки, стрельчато-арочные формы дверного и оконного проёмов, угловые скосы переходов от квадратного основания внутреннего помещения в восьмигранник и круглое основание купола. Как утверждают специалисты, по сходству планировочной структуры и сохранившихся деталей интерьера этот памятник очень похож на Восточный мавзолей.

По сведениям путешественников XVIII в., здесь, как и в Восточном мавзолее, лежали надгробные камни, а во время земляных работ во время копки погребов разрушались захоронения, совершённые по мусульманскому обряду.

На памятнике были проведены работы по консервации и фрагментарной реконсрукции в 1968–1969 гг. В настоящее время здесь открыт лапи-

*Северный мавзолей до реставрации. Фотография 1950-х годов*
*Төньяк төрбә реставрациягә кадәр. 1950 еллар фотографиясе*





*Северный мавзолей. Современный вид*
*Төньяк төрбә. Бүгенге күренеше*



*Намогильные камни в Северном мавзолее*
*Төньяк төрбәдә кабер ташлары*



*Северный мавзолей после реставрации 1960–1970-х годов*
*Төньяк төрбә 1960–1970 елларда үткәрелгән реставрациядән соң*

дарий – экспонируются надгробные камни Болгара конца XIII – начала XV в., сбору которых положил начало российский император Пётр I, посетивший городище в 1722 году.

***Чёрная палата,*** дошедшая до наших дней почти в первозданном виде, является удивительным по своей красоте архитектурным сооружением. Она находится в 400 м к югу от комплекса Соборной мечети и на таком же расстоянии к востоку от комплекса Малого минарета. Построена в середине XIV в. из белого известняка. Археологические исследования Чёрной палаты проводились в 1957 и 1966 гг., реставрационные работы – в 1897, 1911, 1956–1957, 1977–1984 и 1999 гг.

«Чёрная палата» представляет собой двухэтажную постройку с центральным трёхъярусным купольным залом (7×7 м) на втором этаже. Он был окружён небольшими помещениями различного назначения. С северной и западной сторон они служили крытой галереей с величественным порталом и каменной лестницей, с двух других сторон представляли собой закрытые помещения и открытую портальную нишу перед центральным входом в купольный зал высотой 9,5 м. На всех четырёх стенах каждого яруса врезаны окна. Четвёртый ярус построен в

матуррак булган. Тик ул бик начар сакланган: безнең көннәргә кадәр нигезе, стена калдыклары, ишек һәм тәрәзә уемнары, планда квадрат рәвешле эчке залның диварлары сигез кырлыга күчә барган өлеше һәм түгәрәк гөмбәз нигезе килеп җиткән. Шуңа да карамастан, төрбәнең элеккеге күренешен яңадан торгызу алай ук кыен түгел, чөнки белгечләр раслаганча, планлаштыру структурасы һәм интерьерның сакланган детальләре охшашлыгы буенча бу һәйкәл Көнчыгыш мавзолейга охшаган.

XVIII гасыр сәяхәтчеләре мәгълүматлары буенча, биредә, Көнчыгыш мавзолейдагы кебек үк, кабер ташлары яткан, ә җир эшләре вакытында базларны казыганда мөселман йоласы буенча күмелгән каберләр ачылган.

Һәйкәлдә 1968–1969 нчы елларда консервация һәм реконструкция эшләре алып барыла. Хәзерге вакытта монда лапидарий ачылган, экспозициядә – XIII гасыр ахыры – XV гасыр башындагы Болгарның кабер ташлары. Аны җыю һәм өйрәнү эшенә 1722 нче елда Азов походына барганда шәһәрлеккә кереп чыккан Россия императоры Петр I нигез салган.

***Кара пулат («Чёрная палата»)*** – үзенең элеккеге кыяфәтен тулысынча диярлек саклап (әлбәттә, бөтенләй юкка чыккан өлешләре дә күп), безнең көннәргә кадәр килеп җиткән гүзәл архитектура һәйкәле. Ул Җәмигъ мәчете комплексыннан көньякка 400 метр ераклыкта һәм Кече манара комплексыннан көнчыгышка таба шундый ук ераклыкта урнашкан. XIV гасыр уртасында ак известьташтан салынган. Кара пулатта археологик тикшеренүләр 1957 һәм 1966 нчы елларда, реставрация эшләре – 1897, 1911, 1956–1957, 1977–1984 һәм 1999 нчы елларда алып барыла.

Ни өчен бу пулатны «кара» ди атаганнар? «Янмый торган кыз» исемле татар риваяте аны болай аңлата: *«Шөһрәтле Болгар шәһәрен Аксак Тимер (Тамерлан) басып ала һәм кешеләрен кылычтан үткәрә... Болгарда ул вакытта патшалык иткән Габдулла хан, үзенең шәһәрне саклап кала алмавын аңлагач, гаиләсе һәм кайбер якыннары белән шәһәрнең иң нык таш пулатларыннан исәпләнгән Хөкем палатасына кереп бикләнә. Дошман сугышчылары бу бинаны бүрәнәләр, корыган агачлар белән әйләндереп алалар да, ут төртеп җибәрәләр. Габдулла хан һәм аның белән бергә бинага бикләнгән якыннары, хан кызыннан һәм аның Галимбәк белән Алтынбәк исемле ике улыннан кала, барысы да һәлак булалар». Ак таштан салынган Хөкем сарае шушы янгыннан соң каралып калган, имеш».* Чынлыкта, аңлатма күпкә җиңелрәк – XVIII гасыр монахлары биредә Иделдән тотылган балыкны ыслау белән шөгыльләнгәннәр, пулат диварларын кара корымга батырганнар.

Башта Кара пулат ике катлы бинадан гыйбарәт булып, аның икенче катында өч яруслы гөмбәзле залы (7×7 м) булган. Ул төрле функцияләр үтәүгә исәпләнгән зур булмаган биналар белән әйләндереп алынган. Тө-



*Интерьер Чёрной палаты после частичной реставрации начала 2000-х годов*

*Кара пулатның эчке күренеше 2000нче еллар башында үткәрелгән өлешчә реставрациядән соң*

ньяк һәм көнбатыш яктан алар мәһабәт портал һәм таш баскычлы ябык галерея хезмәтен үтәгәннәр, калган ике яктан исә ябык биналар һәм 9,5 метр биеклектәге гөмбәзле залга керү юлы каршындагы ачык портал нишасы (уемы) рәвешендә булганнар. Һәр ярусның барлык дүрт стенасында да тәрәзәләр урнаштырылган. Дүртенче ярус ярымсферик гөмбәз белән тәмамлана торган сигезпочмак рәвешендә төзелгән. Бина ягыннан беренче кат тигезлегендә зур булмаган бүлмәләр урнашкан.

Икенче ярусның гөмбәзле бинасында бина штукатурланган һәм йолдызлы розеткалардан, капительле кечкенә колонналардан, тромп йөзлегендәге сталактитлардан торган алебастрдан әвәләп ясалган орнаментлар белән бизәлгән. Дүртпочмаклы өлешенең үлчәмнәре – 10×10 метр, галереяне дә кертеп, – 15×16 метр.

«Кара пулат» стеналарын, бурташ измәсе белән сылап-беркетеп, бурташ һәм бурташ туфыннан салганнар. Гөмбәз исә бик сыйфатлы бурташ измәсе белән беркетелгән туф блоклардан эшләнгән.

Татар халык риваятьләрендә, болгар ханы Кара пулатта гаеплеләрне гадел хөкемгә тарткан, диелә. Хөкем

***Чёрная палата. Середина XIV века. Вид с юго-востока. Фотография начала 2000-х годов***
***Кара пулат. XIVгасыр уртасы. Көньяк-көнчыгыш яктан күренеше. 2000 нче еллар башы***






*Чёрная палата. Юго-восточный вид. Ил. из сочинений П.С. Палласа. 1768*
*Кара пулат. Көньяк-көнчыгыш яктан күренеше. Иллюстрация китаптан:*
*Pallas R.S. De ossibus Sibiriae fossilibus, craniis praescrtim Rhinoctrotum atque Buffalorum, observations. Novi Commentarii Academiiae Scientiarum Imperialis Petropolimanae. XIII. SPb, 1768*

виде восьмиугольника, завершающегося полусферическим куполом. По сторонам здания на уровне первого этажа располагались небольшие помещения.

Здание в купольном помещении второго яруса оштукатурено и украшено алебастровой лепниной, состоящей из профилированных тяг, звездчатых розеток, колонок с капителями, сталактитов на тромповых скосах. Размеры в плане сохранившегося четверика 10×10 м, включая галереи – 15×16 м. Кладка стен «Чёрной палаты» выполнена из известняка и известнякового туфа на известковом растворе. Снаружи и внутри здания до реставрационных работ были видны следы разновременных закладок из камня и кирпича на различных известковых растворах. Купол выполнен из туфовых блоков, скреплённых плотным, качественным известковым раствором.

Как гласят татарские легенды, в «Чёрной палате» болгарский хан вместе с тремя судьями вершил правосудие; в низких комнатах первого этажа содержались осуждённые. По мнению крупнейшего авторитета в булгарской археологии профессора А.П. Смирнова, «Чёрная палата» служила мечетью. Предполагают также, что в этом здании могли размещаться государственный архив и библиотека. Некоторые видят в нём ханаку – пристанище для странствующих дервишей – или же мавзолей одного из правителей Булгарского улуса Золотой Орды.

Эпитет «чёрный» в названии палаты объясняет татарская легенда:

карарын ул абруйлы картлардан сайлап куелган өч хөкемдар белән бергәләп чыгарган. Хөкем йортының беренче катындагы түбән бүлмәләрендә хөкем ителгәннәрне тотканнар, имеш.

Болгар археологиясенең абруйлы белгече, профессор А.П. Смирнов фикеренчә, «Кара пулат» халыкка мәчет сыйфатында хезмәт иткән. Кайберәүләр бу бинада дәүләт архивы һәм китапханәсе урнашкан булырга мөмкин, дип фаразлый. Кара пулатны ханәкә – сәяхәтче дәрвишләр, суфилар өчен сыену урыны буларак күз алдына китерүчеләр дә бар. Мәскәү археологы Э.Д. Зиливинская тарафыннан күптән түгел әйтелгән тагын бер фараз материаллар белән ярыйсы гына нигезләнгән:



*М.К. Мавровская. Болгары. Чёрная палата. 1969.*
*Собрание Болгарского государственного историко-архитектурного музея-заповедника*
*М.К. Мавровская. Болгар. Таш пулат. 1969.*
*© Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



*Чёрная палата. Вид с северо-запада. Реконструкция*

*Кара пулат. Төньяк-көнбатыш яктан күренеше. Реконструкция*

когда город был взят Аксак Тимуром (Тамерланом), булгарский хан Абдуллах со своей семьёй укрылся в этом здании. Враги обложили его деревом и подожгли. Все погибли, кроме дочери хана, набожной и добродетельной. Она вознеслась на небеса, здание тоже осталось целым, но почерневшим от пожара. На самом деле, объяснение гораздо прозаичнее – в XVIII в. монахи устроили в нём коптильню и стены здания покрылись черной копотью.

Первоначальный облик «Чёрной палаты» реконструируется как здание с опоясывающими центральный объем галереями, портальным входом и восьмидольным сомкнутым куполом – аналогично зданию «Диван-хане» в Баку (Азербайджан), построенному в XV веке, примерно на столетие позже.

***Малый минарет и ханская усыпальница*** находятся восточнее «Чёрной палаты», там, где в XIV в. располагалось кладбище знати с надгробными памятниками и белокаменными усыпальницами.

В этом же районе находится Малый минарет высотой около 12 м – почти полностью сохранившийся в первозданном виде средневеко-

Кара пулат – Алтын Урданың Болгар олысы хакимнәреннән берсе күмелгән төрбә. Кыскасы, фаразлар күп һәм әлегә аларның барысы да яшәргә хаклы.

Белгечләрнең фикеренчә, Кара пулатның борынгы тышкы күренеше куб рәвешендәге үзәк бинаны әйләндереп алган галереяләре, портал тибындагы ишеге һәм сигез бүлемле гөмбәзе белән Бакуда (Әзәрбайҗан) XV гасырда, ягъни бераз соңрак төзелгән «Диван-ханә» бинасына охшаш. Дөрес, ул тагын да зиннәтлерәк күренә, әмма, кайбер галимнәр фикеренчә, ул да ханның хөкем итү урыны булып хезмәт иткән. Киңрәк алып караганда, Кара пулат, гомумән, урта гасырлар чорында Шәрык илләрендә таралган архитектура корылмаларын хәтерләтә. XIV гасырның урталарында һәм икенче яртысында Урта Азия корылмалары, аерым алганда, Күнә-Үргәнечтәге Түрәбәк-ханым, Шах-и-Зинда ансамблендәге Ширин-бикә-әкә төрбәләрендә дә Кара пулат архитектурасына охшаш элементлар табарга була. Кара пулатның Урта Азия корылмалары белән бердәмлеге төзелеш техникасы үзенчәлекләрендә дә ачык чагыла: эчке һәм өлешчә тышкы капламнарда кулланылган туф блокларының формасы һәм үлчәмнәре шуңа ишарәли.

***Кече манара һәм Хан төрбәсе*** Кара пулаттан көнчыгыштарак ур-



*Мавзолей Тюрабек-ханум в Куня-Ургенче*

*Күнә-Үргәнечтә Түрәбәк ханым төрбәсе*



*Малый минарет. Фотография А.С. Башкирова. 1910*
*Кече манара. А.С. Башкиров фотосы. 1910*



*Диван-хане на изображении Григория Гагарина. 1847*
*Г.Г. Гагарин. Ширвән-шаһлар төрбәсе. 1842-1853.*
*«Живописный Кавказ» альбомы өчен акварель. © Дәүләт Рус музее. Санкт-Петербург*



*Ханская усыпальница и Малый минарет. Вид с севера*
*Болгарда Хан төрбәсе һәм Кече манара. Төньяктан күренеше. 2000нче еллар*





*И.И. Шишкин. Развалины Ханской усыпальницы и Малый минарет в Болгарах. 1861. Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан*

*И.И. Шишкин. Болгарда Хан төрбәсе хәрабәләре һәм Кече манара. 1861. © Татарстан Дәүләт рәсем сәнгате музее. Казан*



*Мавровская М.К.*
*Внутренний вид Ханской усыпальницы.*

*М.К. Мавровская. Хан төрбәсенең эчке күренеше. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*




*Ф.Х. Эрдман. Малый минарет и Ханская усыпальница. Ил. из кн.: «Die Ruinen Bulgars». 1820*

*Ф.Х. Эрдман. Хан төрбәсе һәм Кече манара.*
*Китаптан: Die Ruinen Bulgars. 1820*

нашкан, биредә XIV гасырда каберташлар куелган мөселман зираты һәм ак таштан салынган төрбәләр урнашкан булган.

Шул ук районда чатырлы очыннан башка 12 метр биеклектәге Кече манара урнашкан. Ул – Болгарның элеккеге хәлендә сакланып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән бердәнбер архитектура һәйкәле. Кече манара тулысынча диярлек Җәмигъ мәчетенең Олы манара үрнәге буенча төзелгән. Аның куб сыман аскы өлешенә (4,8×4,8 м), сигезкырлык утыртылган, ә кубның түбәләре өчпочмаклы кыеклар рәвешендә. Сигезкырлыкка цилиндрик кәүсә утыртылган, ул өскә таба нечкәреп килгән һәм тагын да нечкәрәк цилиндрга тоташтырылган. Аңа уелган кечкенә ишектән чыгып, тар гына түгәрәк мәйданчыкка әләгергә була.

Манараның төньягында җирдән бер метр чамасы биклектә як-ягы үрмә гөлләргә охшаш бизәкләр уелган ишек аша эчкә үтәргә мөмкин. Яшьрәк туристлар гадәттә, 45 әйләнгеч баскычтан югарыга күтәрелеп, түгәрәк мәйданчыктан тирә-юньне күзәтергә ярата.

Манараның тышкы ягында туристлар игътибарыннан читтә калмый торган тагын бер нәрсә бар: астагы нигез кубның көнбатыш стенасында көймә сыман куыш күренеп тора. Анда нәфис итеп уелган бизәкле кайма эзләре сакланган, ә өстәрәк геометрик һәм үсемлек бизәкләре төшерелгән. Биредә кайчандыр язулы таш булгандыр, дип уйлый эпиграфист галимнәр.

Әйбәт сакланган дип әйтсәк тә, XIV гасыр урталарында яхшы итеп шомартылган сыйфатлы ташлардан төзелгән бу корылма, әлбәттә, элеккеге матур күренешен бераз җуйган, кайбер өлешләре юкка чыккан. Шуңа күрә, реставраторлар 1968 нче елда ук әле өске түгәрәк катның беренчел тышкы капламын, өстәге түгәрәк мәйданчыкның рәшәткәсен, 1969 нчы елда цилиндр сыман катларның кәрнизләрен, манарага керү ишеген, тыштагы бурташ блокларның кайберләрен, куыш белән ишек янындагы бизәкләрне өлешчә торгыздылар, яңарттылар. 1990 нчы елларда да биредә реставраторлар эшләде. 1995 елда мөселман халкы соравы буенча, манарада ярымай урнаштырылды.

Тышкы күренеше һәм бизәлеш элементлары ягыннан караганда, бу манара күзәтү башнясы буларак, ягъни, хәрби максатларда кулланылмады микән? дип сорау бирә кайбер галимнәр. Әйе, Әзәрбайҗандагы безнең манараларга охшаш корылмалар чыннан да күзәтү максатларында да хезмәт иткәннәр. Болгарның Кече манарасы исә «Хан зираты»нда урнашкан. Ул безнең көннәргә кадәр сакланмаган мәчеткә караган булса кирәк. Җәмигъ мәчетенең биек манарасыннан да тирә-юнь бик яхшы күзәтелә. Һичшиксез, хәрби максатларга да хезмәт иткән булырга тиеш ул.

Кече манарадан төньякка урнашкан төрбә харәбәләрен хәзер шулай, *Ханнар зираты* дип йөртәләр, чөнки, археологлар һәм эпиграфист галимнәр раславынча, бу мөселман зира-



*Малый минарет и Ханская усыпальница после реставрации 2005–2006 годов*
*Кече манараның нигез өлешендәге уем (ниша) 2000 нче еллар*



*Оформление входа в Малый минарет в начале 2000-х годов*
*Кече манара гөмбәзенә ярымай урнаштыру. 1990 нчы еллар уртасы*

тына югары катлау кешеләрен күмгәннәр. Мәрхүмнәрнең күпчелеген табутларга салып җир куенына тапшырганнар, кайбер каберләр өстендә таш төрбә эзләре бар. Әлбәттә, матур каллиграфик язулы каберташлар да куелган.



*Ниша в основании Малого минарета. Современная фотография*

*Рече манара нигезендәге уем*

Бу төрбәләрнең берсе, «Хан төрбәсе» дип йөртелгәне – ул бүген дә тулысынча диярлек төньяк һәм көнбатыш диварларын саклап калган – планда квадрат рәвешендәге, үлчәмнәре 9,5×9,5 метрлы бина. Тышкы яктан куе һәм ачык зәңгәр, сары һәм ак төстәге ялтыравыклы геометрик бизәкләр төшерелгән, куфи язулы гипс плитәләр белән капланган була. Эчкә кереп карасаң, бинаның аскы каты почмак кыеклары ярдәмендә сигезкырлыкка күчүен шәйләргә мөмкин. Сигезкырлык өстендәге түгәрәк нигезгә гөмбәз рәвешендәге түбә утыртылган. Бина эчендә мөселман йоласы буенча күмелгән җиде каберлек ачылды. Биредә олы яшьтәге кешеләр дә, балалар да күмелгән. Димәк, төрбә ниндидер бер танылган гаиләгә мөнәсәбәтле, дип уйларга нигез бар. Бинаның көньяк диварына 1309 нчы елгы кабер плитәсен кертеп урнаштырганнар.

Хан төрбәсенең көнбатыш ягында тагын бер кечерәк кенә төрбә булган, көнчыгыш ягында исә соңрак янәдән бер бина төзеп куялар. Анысының төньякка карап торган порталы да бар. Төньяк-көнбатыш тарафта Хан төр-

вый культовый памятник Болгара. Он сооружён по образцу Большого минарета Соборной мечети. Основу минарета составляет массивный столп, кубовидное основание которого (4,8×4,8 м), ориентированное точно по сторонам света, плавно переходит при помощи треугольных скосов в восьмигранный ярус. Он, в свою очередь, соединяется с круглым основанием цилиндрического ствола минарета, в верхней части которого располагается обходная галерея, куда из арочного входа нижнего квадратного яруса ведёт винтовая лестница в 45 ступеней.

Расположенный с севера арочный вход в минарет и орнаментальная ниша в западной части основания имеют богатое оформление, выполненное в технике тонкой каменной резьбы. Следы декора сохранились и на верхней обходной галерее, куда ведёт винтовая каменная лестница.

Район расположения минарета изучался археологическими раскопками в 1914, 1968–1969 гг. В 1968–1970 гг. и в последнее десятилетие XX в. проводились консервационно-реставрационные работы памятника. В 1995 г. по просьбе мусульманского населения на минарете был установлен полумесяц.

Минарет – необходимый элемент несохранившейся мечети, возведённой на «Ханском кладбище», как назван этот район города в преданиях татар. Такое же название носят руины трёх усыпальниц, расположенных к северу от Малого минарета.

Одна из этих усыпальниц, средняя, квадратная в плане (9,5×9,5 м), с купольным перекрытием и арочным порталом, выделялась среди других тщательной отделкой стен, украшенных гипсовыми плитками с геометрическим орнаментом. Внутри здания вскрыто семь погребений в гробах, взрослых и детских, совершённых по правилам мусульманской погребальной обрядности. Это, скорее всего, семейная усыпальница знатной фамилии.

Руины Ханской усыпальницы зафиксированы на рисунках XIX в. Она и сегодня почти на полную высоту сохранила северную и западную стены. В первоначальном виде это было беспортальное купольное здание с квадратным планом (8,5×8,5 м). Основной куб посредством откосов снаружи и тромпов внутри превращался в восьмигранник, переходящий в полусферический купол.

Внутренняя поверхность основного здания была оштукатурена; некоторые участки её, например, карнизы и наличники были отделаны поливными изразцами тёмно-синего, голубого, жёлтого и белого цветов с геометрическим и растительным орнаментом, переплетающимся с куфическим письмом. В южную стену помещения заделана могильная плита 1309 года.

Ханская усыпальница позднее была реконструирована в целый комплекс мавзолеев. С западной стороны к ней пристроили, с перевязкой к кладке, усыпальницу поменьше, с




*Мавзолеи и некрополи на территории Болгара.*
*Карта из экспозиции Музея Болгарской цивилизации*
*Авторы: И. Артамонов, А. Леухин, Ф. Валиуллин, Р. Шигабутдинов, И. Щетинин*

*Болгар җирлегендә төрбәләр һәм борынгы зиратлар.*
*Болгар цивилизациясе музее экспозициясеннән. Авторлар: И. Артамонов, А. Леушин, Ф. Вәлиуллин, Р. Шиһабетдинов, И. Щетинин © Болгар цивилизациясе музее. Болгар*



*Мавзолей № 1*
*1 нче төрбә*



*Мавзолей № 2*
*2 нче төрбә*



*Мавзолей № 3*
*3 нче төрбә*

восточной – более поздний пристрой с портальной нишей, ориентированной на север. С северо-западной стороны располагается ещё одна усыпальница, аналогичная центральной Ханской. Позднее все они объединяются в одно сооружение. Весь этот комплекс является образцом центрально-купольного типа кубичных мавзолеев, распространённых в странах мусульманского Востока.

***Мавзолей № 1,*** построенный в конце XIV в., расположен в 150 м к юго-востоку от Малого минарета. Археологически исследовался в 1970–1971 гг. От здания сохранились котлован ленточного фундамента, отдельные незначительные участки кладки и большое количество строительного мусора. Размеры прямоугольной в плане постройки – 6,6×7 м, толщина стен около 1 м. К южной стене примыкал портал (2,5×2 м), от которого зафиксированы остатки кладок пилонов. В мавзолее было совершено единственное захоронение по мусульманскому обряду.

***Мавзолей № 2,*** исследованный в 1976–1977 гг., находится в 350 м к юго-востоку от Малого минарета и в 110 м от Мавзолея № 1. Время строительства – последние десятилетия XIV в. От постройки сохранились котлован ленточного фундамента шириной около 1 м, отдельные участки кладки фундамента и стен, локальные участки пола и отмостки, а также плитки резного ганча и куски штукатурки. Сооружение квадратное в плане (9,6×9,6 м). К северной стене примыкали два пилона – основыароч-

бәсенә охшатыбрак тагын бер төрбә салып куялар. Хәер, 1968 нче елда үткәрелгән казу эшләре вакытында әлеге «төрбәнең» кеше күмү өчен билгеләнмәве ачыкланды – биредә мич калдыклары һәм идән астыннан җылыту өчен төтен юллары ачылды. Белгечләрнең раславынча, элегрәк бу бина зират мәчете буларак яисә биредә күмелгән атаклы затларны зиярәт кылучы мөселманнар, дәрвишләр өчен махсус салынган ханәкә сыйфатында кулланылгандыр. Соңрак исә аны төрбәгә әйләндерүләре дә мөмкин.

Болгарда ачылган мемориаль объектлардан тагын берничәсенә тукталып китик.

***1 нче төрбә.*** Ул XIV гасыр ахырында төзелгән. Кече манарадан көньяк-көнчыгышка таба 150 метр ераклыкта урнашкан. 1970–1971 нче елларда археологик яктан өйрәнелә. Бинадан тасмалы фундамент чокыры (котлован), кайбер участокларда стена харәбәләре һәм төзелеш чүп-чары сакланган. Турыпочмаклы корылманың пландагы үлчәме – 6,6×7 метр, диварларның калынлыгы 1 метрга җитә. Көньяк диварга портал (төп керү ишеге) (2,5×2 м) тоташкан, аннан калган пилон (багана, колонна) эзләре сакланган. Төрбәнең идәне – җир. Биредә мөселман йоласы буенча күмелгән бердәнбер каберлек ачылды.

***2 нче төрбә.*** 1976–1977 елларда өйрәнелгән бу төрбә Кече манарадан көньяк-көнчыгышка 350 метр һәм югарыда тасвирланган 1 нче төрбәдән 110 метр ераклыкта урнашкан.



*Мавзолей № 4*
*4 нче төрбә*



*Мавзолей № 5*
*5 нче төрбә*



*Мавзолей № 6*
*6 нчы төрбә*



*Южный мавзолей*
*Көньяк төрбә*

квадратное в плане (8,6×8,6 м) с шириной стен 0,7–0,9 м. В нём совершено одиннадцать погребений: три из них детские, четыре погребения полностью или частично нарушены другими захоронениями.

ного портала (2×3 м). Внутри помещения пол был выстлан деревянными досками. Вокруг стен сооружения прослежена вымостка из щебёнки, залитой известковым строительным раствором. Внутри сооружение было тщательно оштукатурено.

***Мавзолей № 3,*** построенный во второй половине XIV в., находится в 250 м восточнее Малого минарета. Исследовался в 1981 г. От постройки сохранились котлован ленточного фундамента, отдельные участки кладки фундамента и пилона, а также куски строительного раствора и мелкие камни известняка. Мавзолей прямоугольный в плане (5,5×5,3 м), к северной стене примыкает портал (2×1,7 м). Пол сооружения был земляной. В мавзолее совершено четыре захоронения по мусульманскому обряду.

***Мавзолей № 4,*** исследованный в 1981 г., находится в 600 м к юго-востоку от Малого минарета и в 230 м от мавзолея № 1. Относится ко второй половине XIV – началу XV в. От постройки сохранился котлован ленточного фундамента. Сооружение квадратное в плане (8,6×8,6 м) с шириной стен 0,7–0,9 м. В нём совершено одиннадцать погребений: три из них детские, четыре погребения полностью или частично нарушены другими захоронениями.

***Мавзолей № 5 (двухкамерный),*** построенный во второй половине XIV в., находится на южной окраине города, в 300 м севернее южных ворот. От мавзолея остался незначительный холмик строительного мусора. Зафиксирован ленточный котлован прямоугольной постройки размерами 14×8 м и шириной стен от 1,2–1,3 м. Вход с южной стороны, где зафиксирован фундамент арочного пилона и портала (2×2,5 м). Внутреннее пространство состояло из двух помещений размерами 6×6 и 5×5 м. В первом из них было совершено восемь, во втором – четыре захоронения.

***Мавзолей № 6*** середины XIV в. находится в центральной части городища. Сохранившиеся остатки мавзолея маловыразительны. Вход в постройку, скорее всего, оформляли выступы – пилоны (1,2×1,5 м) в южной части постройки. Сооружение квадратное в плане (8,6×8,6 м) с шириной стен 0,7–0,9 м. Судя по заполнению поздних хозяйственных ям, стены были возведены из известняка и туфа на

Төзелеш вакыты – XIV гасыр ахыры (1390 нчы еллар). Корылмадан 1 метр киңлектәге тасмалы нигез чокыры, фундаменты һәм стеналарның аерым участоклары, идәне, шулай ук уелган ганч плитәләре (балчык һәм гипс катнашмасыннан торган плитә) һәм штукатурка кисәкләре сакланган. Корылма квадрат планда (9,6×9,6 м). Төньяк диварга ике пилон – аркалы портал (2×3 м) нигезләре тоташкан. Бина эчендә идән агач такталардан ясалган. Төрбә тирәсендәнге участокларга бурташ измәсе белән ныгытылган вак таш түшәлгән. Эчке стеналар штукатурланган.

***3 нче төрбә.*** XIV гасырның икенче яртысында төзелгән, Кече манарадан 250 метр ераклыкта көнчыгыш тарафта урнашкан. Археологик яктан 1981 елда өйрәнелә. Әлеге корылмадан тасмалы фундамент чокыры, фундамент һәм кайбер участокларда пилон нигезләре, төзелеш измәсе кисәкләре һәм бурташ кисәкләре сакланган. Мавзолей турыпочмаклы планда (5,5×5,3 м), төньяк диварга портал (2×1,7 м) тоташа. Корылманың идәне – җир. Төрбәдә мөселман йоласы буенча дүрт кеше күмелгән.

***4 нче төрбә*** шулай ук 1981 елда казып чыгарылган. Ул Кече манарадан көньяк-көнчыгышка таба 600 метр һәм 1 нче төрбәдән 230 метр ераклыкта урнашкан. Төзелү вакыты XIV гасырның икенче яртысына – XV гасыр башына карый. Корылмадан тасмалы нигез чокыры сакланып калган. Үлчәмнәре 8,6×8,6 квадрат метр, стеналарының киңлеге 0,7–0,9 метр. Бу төрбәдә унбер кабер ачылган. Шуларның өчесендә балалар күмелгән. Дүрт кабер соңрак бүтән кешеләрне күмгән вакытта җимертелгән.

***5 нче төрбә*** XIV гасырның икенче яртысында төзелгән. Шәһәрнең көньяк читендә, көньяк капкадан 300 метр ераклыкта урнашкан. 1983–1985 елларда үткәрелгән казу эшләре вакытында үлчәмнәре 14×8 м зурлыгында һәм стеналарының киңлеге 1,2–1,3 метр булган турыпочмаклы корылманың тасмалы фундамент чокыры ачылды. Ишеге көньяктан булган, анда арка пилоны һәм порталның нигезе (2×2,5 м) сакланып калган. Төрбә эче үлчәмнәре 6×6 һәм 5×5 метрлы ике бүлмәдән гыйбарәт. Беренчесендә сигез, икенчесендә – дүрт кеше күмелгән. Ачылганнан соң, 1983-1985 елларда төрбә калдыклары консервацияләнә.

***6 нче төрбә*** XIV гасыр уртасында төзелгән, шәһәрнең үзәк өлешендә урнашкан. Ул бик начар сакланган. Төрбәнең ишеге көньяк өлешендә булгандыр кебек, чөнки биредә аркалы порталның пилон эзләре (1,2×1,5 м) сакланган. Корылманың нигезе квадрат рәвешендә (8,6×8,6 м), стеналарының киңлеге 0,7–0,9 метр чамасы, бурташтан һәм туфтан өелгән. Алебастр кисәкләре төрбә диварларының штукатурланган булуына ишарәли. Археологик казу эшләре вакытында кеше сөякләре табылган, әмма каберлекләр сакланмаган.

***Көньяк төрбә*** 2012 елда казып тикшерелгән. Ул Болгар шәһәрлегенең көньяк өлешендә, Көньяк капкадан ерак түгел бер җирдә урнашкан. Биредә, өстендә таш-кирпеч



*Намогильный камень, найденный на территории кладбища*
*Борынгы зират урынында табылган кабер ташы. Фотография казу эшләре вакытында төшерелгән*

известковом растворе. Находки кусков алебастра дают возможность предположить, что стены постройки были оштукатурены.

***Южный мавзолей*** выявлен в 2012 г. во время археологических исследований невысокого холма, находящегося в южной части Болгарского городища, недалеко от южного проезда. Холм скрывал руины белокаменного мавзолея прямоугольной формы (10,2×9,7 м), построенного в середине XIV в. Вход расположен с северной стороны и маркируется двумя мощными каменными пилонами длиной 2,7 м. Внутри здание было восьмигранным. Основание фундамента мавзолея представляет собой ряд грубо обработанных камней, плотно стоящих друг к другу под наклоном. Камни поставлены всухую, без использования раствора. Внутри мавзолея, в его южной части, зафиксировано 9 захоронений в грунтовых могильных ямах прямоугольной формы, расположенных в два ряда, плотно друг к другу. Все умершие находились в гробах ящичного типа, сколоченных из толстых и широких досок или плах. Вокруг мавзолея формируется открытое кладбище. В раскоп попало более 90 погребений, в захоронениях с внешней стороны мавзолея. Захоронения совершены с соблюдением мусульманских традиций. В северо-западном углу раскопа, в слое кладбища, найден белокаменный намогильный камень с рельефной арабской надписью.

* * *

Обратим внимание ещё на один интересный объект Болгарского горо-

кисәкләре аунап яткан артык биек булмаган бер калкулыкта, археологлар XIV гасыр уртасында төзелгән төрбә харәбәләрен тикшерәләр. Аның нигезе турыпочмаклы (10,2×9,7 м), керү төньяктан, аркалы ишеге 2,7 метр киңлектә урнаштырылган пилоннар белән чикләнгән. Төрбәнең фундаменты берсе өстенә берсен авыштырып куйган тупас эшкәртелгән ташлардан өелгән. Ташлар коры килеш, измә кулланмыйча гына куелган. Төрбәнең эче сигез почмаклы итеп ясалган.

Биредә, төрбәнең көньяк өлешендә, мөселман йоласына туры китереп күмелгән 9 кешенең кабере урнашкан. Аларның барысы да калын һәм киң такталардан ясалган әрҗә тибындагы табутларда ята. Төрбә янында гына мөселман зираты барлыкка килгән. Биредә археологлар төрбәнең тышкы ягында 90 нан артык каберлек казып тикшерәләр. Каберләр мөселман йоласы буенча күмелгән. Зиратның төньяк-көнбатыш почмагында рельефлы гарәп графикасы белән язылган каберташ табылган.

* * *

Шәһәр чигендә, Җәмигъ мәчете комплексыннан 2 километр чамасы ераклыкта, көньяк капка тирәсендә, борынгы ныгытмаларга терәлеп дирлек урнашкан ***Кече шәһәр*** («Малый



*Южный мавзолей и некрополь после завершения археологических исследований. 2012. Исследователь И.И. Елкина*

*Көньяк төрбә һәм борынгы зиратта ачылган каберләр археологик казу эшләре тәгәлләнгәннән соң. 2012. И.И. Елкина казылмалары*



*Малый городок. Здание въездных ворот. Середина XIV века. Современный облик после реставрационных работ 2010-х. годов*

*Кече шәһәрчек. Эчкә керү капкалары. XIV гасыр уртасы 2010 нчы еллардагы реставрациядән соңгы күренеше*

*Л.А. Беляев рядом с юго-восточным углом Южного здания. Фотография 1982 года*

*Л.А. Беляев Көньяк бинаның көньяк-көнчыгыш почмагы янында. 1982 елгы фото*





*Малый городок на плане Болгара. Рисунок из «Атласа» А. Шмита. 1832*

*Болгар планында Кече шәһәрчекнең урыны Иллюстрация китаптан: Архитектурные чертежи развалин древних Болгар. Сняты с натуры в 1827 г. архитектором А. Шмитом. СПб., 1832*



*Руины зданий Малого городка в начале XIX века Рисунок из «Атласа» А. Шмита. 1832. Вверху – южное здание; внизу – пилоны въезда*

*Кече шәһәрчектәге биналарның XIX гасыр башында сакланып калган хәрабәләре. Өстә – көньяк бина, аста – керү пилоннары. Иллюстрация китаптан: Архитектурные чертежи развалин древних Болгар. Сняты с натуры в 1827 г. архитектором А. Шмитом. СПб., 1832*



*Фрагмент резной ганчевой плитки, найденный во время исследований здания с водоёмом*

*Кече шәһәрчек территориясендә су җыю урыны – бассейн урнашкан бинаны казыганда табылган ганч плитә фрагменты. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*

дища, расположенный за его пределами – к западу от южных въездных ворот, примерно в 2 км к югу от комплекса Соборной мечети. Это ***Малый городок***, впервые зафиксированный под таким названием в 1712 году в описи дьяка Казанской губернской канцелярии Михайлова, прибывшего в Болгар для осмотра земли под строительство Успенского монастыря.

Малый городок в плане имеет трапециевидную форму, вытянутую с севера на юг, с двумя поясами укреплений в виде невысокого земляного вала и неглубокого рва по периметру. Длина наружных укреплений с западной стороны – 330 м, восточной – 290 м, северной – 300 м, южной – 150 м; размеры почти квадратной в плане площадки внутренних укреплений – 105×90–106 м. Северная и южная стороны четырёхугольника прерываются каменными сооружениями. Руины ещё одного здания находятся в северо-восточном углу городка. Первые раскопки с расчисткой руин каменных зданий производились здесь в 1893 году, но никакой документации от них не сохранилось. Долгое время данный объект считали остатками фортификационных сооружений, своеобразного форта, поставленного с наиболее уязвимой для города стороны.

Основательные исследования Малого городка производились в 1981–1984, 2013-2015 гг. московскими археологами Л.А. Беляевым и И.И. Елкиной. Выяснилось, что культурный слой объекта небольшой мощности содержит незначительное количество находок в виде мелких обломков керамики и строительного мусора. Время постройки городка удалось определить серединой – второй половиной XIV в. Скорее всего, строительство началось в период правления Булат-Тимура в 1361–1367 гг. Установлено также, что первоначальный архитектурный замысел комплекса остался не до конца реализованным, т. е. строительство проектируемых зданий было по каким-то причинам прервано и не возобновлено в дальнейшем.

Композиционным центром ансамбля служили монументальные двухбашенные ворота с широким проездом с северной стороны городка. Башни-пилоны, рассчитанные, как полагают, на огневое прикрытие проезда, имели в плане форму прямоугольника размерами 8×9 м. Внутри западной башни сохранились ступеньки винтовой лестницы. Восточная башня представляла собой зальное помещение со сводчатым прикрытием.

Вторая монументальная постройка Малого городка, также встроенная в линию рва, находилась с южной стороны внутренней площадки. Она имела в плане форму прямоугольника (19×13 м). Внутри здание разделено легкой перегородкой на два помещения.

Третье сооружение представлено квадратной в плане (5,2×5,3 м) постройкой с широким (2,7 м) входом с восточной стороны. Оно располагалось между двумя поясами обороны, у северо-восточно угла внутренней

городок») 1712 елда Успение монастырена җир биләмәсе сайлап алу өчен Болгарга килгән Казан губернасы канцеляриясе дьягы Михайлов тасвирламасында беренче тапкыр телгә алына.

Кече шәһәр, исеме үк әйтеп тора, зур түгел, төньяктан көньякка сузылган трапеция рәвешендә. Ике рәт артык биек булмаган балчык үр һәм чокыр белән әйләндереп алынган. Көнбатыш ягыннан тышкы ныгытмаларның озынлыгы – 330 метр, көнчыгыш ягыннан – 290 метр, төньяктан – 300 метр, көньяктан – 150 метр; ныгытмалар эчендәге мәйданның үлчәме – 105×90–106 метр. Шәһәрчекнең төньяк һәм көньяк якларында ниндидер таш корылмалар урнашкан. Тагын бер корылма харәбәләре шәһәрчекнең төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан. Биредә беренче казу эшләре, шул исәптән таш бина калдыкларын казый башлау 1893 нче елда башкарылган, әмма бу казылмалардан бернинди документ та сакланмаган. Озак вакытлар Кече шәһәрне Болгарның көньяк тарафтан начаррак ныгытылган өлешен саклау өчен төзелгән үзенчәлекле форт калдыклары дип санап килделәр.

Кече шәһәрне максатчан тикшерү 1981–1984, 2013-2015 нче елларда Мәскәү археологлары Л.А. Беляев һәм И.И. Елкина тарафыннан башкарылды. Тикшерелә торган объектның юка гына культура катламында керамика ватыклары һәм төзелеш чүп-чары ише табылдыкларның аз булуы ачыкланды. Шәһәрчекнең төзелү вакытын XIV гасырның уртасы – икенче яртысы итеп билгеләделәр. Төзелеш эшләре 1361–1367 нче елларда Булат-Тимер идарә иткән чорда башланган булырга мөмкин. Әмма комплексның беренчел архитектура идеясе тормышка ашырылып бетмәгән, ягъни проектлана торган биналар нинди дә булса сәбәпләр аркасында туктатылган һәм алга таба яңадан дәвам ителмәгән.

Ансамбльнең композицион үзәге булып шәһәрнең төньягында 4 метр киңлегендәге, ике ягынннан башнялар күтәрелгән капка тора. Ул башняларның нигезе 8×9 метрлы турыпочмак рәвешендә. Көнбатыш башня эчендә борылма баскычның астагы басмалары сакланган. Көнчыгыш башнясы бер залдан торган гөмбәз түбәле бинадан гыйбарәт. Башняларга эчтән менеп, капка өстеннән йөрергә мөмкин булган дип фаразлыйлар.

Кече шәһәрчекнең икенче монументаль корылмасы шәһәрчекнең көньягында урнашкан. Аның да нигезе турыпочмак рәвешендә (19×13 м). Бина эчендә ике бүлмә булган.

Өченче корылма – көнчыгыш ягыннан 2,7 метр киңлегендәге ишекле, нигезе 5,2×5,3 метр үлчәмле кечерәк кенә бина. Ян стеналар буенда таш эскәмия калдыклары, ә ишек каршында михраб эзләре сакланган. Аның каршында юыну өчен бүлеп бирелгән каналлы кечкенә сулык була. Шул тирәдә үк тәһарәт алу өчен тәгаенләнгән кечкенә генә ясалма сулык.

Комплексның барлык биналары да алебастр эремәсендә буталар салу ысулы белән торгызылды.



*Аксонометрия и схема реконструкции здания въездных ворот*

*Кече шәһәрчеккә керү капкасы булган бинаның аксонометриясе һәм схемасы*



*Аксонометрия и схема частичной реконструкции Южного здания*

*Көньяк бинаның аксонометриясе һәм өлешчә реконструкция схемасы*



*Аксонометрия и схема реконструкции здания с водоёмом*

*Бассейнлы бинаның аксонометриясе һәм өлешчә реконструкция схемасы*

*Из книги: Беляев Л.А., Елкина И.И., Лазукин А.В. Малый городок: исследования 1981–1984 и 2011–2015 годов // Материалы и исследования по археологии Болгарского историко-архитектурного комплекса. Т. 1. Казань; М., 2018*



*Малый городок. Южное здание. Середина XIV века*
*Кече шәһәрчек. Көньяк бина. XIV гасыр уртасы*

*Малый городок. Здание с водоемом. Середина XIV века*
*Современный облик после реставрационных работ 2010-х годов*
*Кече шәһәрчек. Бассейнлы бина. XIV гасыр уртасы*
*2010 нчы еллардагы реставрациядән соңгы күренеше*



площадки. Вдоль боковых стен сохранились остатки каменной скамейки, а в стене напротив входа – следы михраба. Перед ним находился небольшой водоём с отводным каналом для омовений.

Все здания комплекса возводились способом бутовой кладки на алебастровом растворе с последующим их оштукатуриванием.

С восточной стороны Малого городка выявлен некрополь второй половины XIV – XV вв., с остатками каменного мавзолея (6×6 м), сложенного из камней вторичного использования из разрушенных построек города. В ходе раскопок изучено около 20 погребений, три из которых были совершены внутри мавзолея.

На основании новых открытий было высказано предположение, на наш взгляд, наиболее аргументированное, о функциональном назначении ансамбля Малого городка в качестве караван-сарая для купцов. Однако не следует полностью отказаться и от прежней гипотезы об оборонительном предназначении объекта. В конечном счёте, обе функции он мог выполнять, в случае завершённости строительства, одновременно.

* * *

Общественные бани – хаммамы являются важнейшем элементом благоустройства восточного города. Их было много и в Болгаре, как в любом мусульманском городе. Болгарские бани использовались не только в санитарно-гигиенических целях. Они служили одновременно местом общения и отдыха. Здесь богатые горожане вели беседы, спорили, играли в шахматы и шашки, лакомились вкусной пищей и напитками. К настоящему времени археологически исследовано шесть общественных бань, и все они построены в лучших традициях архитектурной школы Востока. Имея много общих конструктивных черт, они, тем не менее, различаются расположением, размерами, планировочными особенностями, материалом и временем строительства. Бани Болгара имеют схожие черты с типичными восточными хаммамами.

Руины четырёх бань находятся в подгорной части Болгара, на берегу речки Мелёнки. На верхнем плато изучены две бани, руины которых законсервированы с частичной реставрацией.

***Красная палата.*** Среди них наиболее известной является так называемая «Красная палата» с фонтаном в центральном зале, раскопанная ещё в 1939–1940 гг. В условном названии бани отражён красный цвет штукатурки внутренних стен – расположена у подножия склона верхней террасы левого берега р. Мелёнки, к северу от комплекса Соборной мечети. Начало функционирования здания определяется серединой XIV в.

Это одна из крупных бань города Болгара (32×16–24 м). Раскопки выявили фундаменты и основание стен здания, сохранившиеся на высоту 1,5–2 м (в юго-восточном углу до 3 м). Фундамент шириной около 1 м и нижняя часть стен выложены из камня, верхняя часть стен, отопительная печь, полусферические

Кече шәһәрнең көнчыгыш өлешендә XIV – XV гасырларның икенче яртысына караган некрополь булуы ачыкланды, анда шәһәрнең җимерелгән корылма ташларын кабат файдаланып салынган (6×6 метр) таш төрбә калдыклары табылган. Казу эшләре барышында якынча 20 кабер өйрәнелде, аларның өчесе төрбә эчендә урнашкан.

Әлегә кадәр галимнәр арасында бердәм фикер юк: нәрсә бу – шәһәр сакчылары өчен махсус урынмы, дәрвишләр өчен ханәкәме, әллә кәрван-сараймы? Шунысы ачык: корылмаларның берсе дә ахырынача төзелеп бетмәгән. Алар 1361 нче елда Булат Тимер заманында төзелә башламаган, киресенчә, җимертелгәннәр һәм төзелешкә яңадан әйләнеп кайтмаганнар дип уйлаучылар да бар.

Яңа ачышлар яктылыгында Кече шәһәр ансамбленең Көнчыгыш сәүдәгәрләре өчен кәраван-сарай сыйфатында салына башлавы турындагы фикер дөреслеккә күбрәк туры килә кебек. Әмма объектның оборона функциясе үтәргә тиешлеге турындагы фараздан да тулысынча баш тартырга кирәкми. Төзелеш тәмамланган очракта, ул ике функцияне дә үти алачак иде.

* * *

Җәмәгать мунчалары – Шәрык шәһәрләрен төзекләндерүнең, шәһәр халкына яшәү өчен уңайлыклар тудыруның мөһим өлеше булып тора. Җәмәгать мунчалары Идел буе Болгарында монголларга кадәр дә, Алтын Урда чорында да күп була. Болгар мунчалары санитар-гигиеник максатларда гына файдаланылмаган. Алар бер үк вакытта аралашу һәм ял итү урыны булып та хезмәт иткән. Биредә бай шәһәр халкы әңгәмәләр алып барган, агымдагы сәясәткә үз карашларын белдереп бәхәсләшкәннәр, бәхәсләшеп туйганнан соң, шахмат һәм шашка уйнаганнар, тәмле ризыклар һәм эчемлекләр белән сыйланганнар.

Хәзерге вакытта Болгарда археологик яктан алты җәмәгать мунчасы казып тикшерелгән, алар барысы да шәрык архитектура мәктәбенең иң яхшы традицияләренә нигезләнеп төзелгән. Күп кенә уртак конструктив элементларына да карамастан, алар үзләренең күләме–үлчәмнәре, планировка үзенчәлекләре, төзелеш материаллары һәм төзелү вакытлары белән бер-берсеннән аерылып торалар. Болгар мунчалары гадәти Шәрык хаммаларына (мунчаларына) охшаш сыйфатларга ия.

Алты мунчаның дүртесе Болгарның тауасты өлешендә, Мелёнка елгасы ярында урнашкан булган. Шәһәрнең югары өлешендә ике мунча өйрәнелгән, аларның харәбәләре өлешчә реставрацияләнгән.

***«Кызыл пулат»*** – Болгардагы атаклы мунчаның шартлы исеме. Бу мунчаның эчке таш диварлары кызыл төстәге измә белән штукатурланган була һәм шул төс аның исемендә чагылыш тапкан. Кызыл пулат Мелёнка елгасының сул як ярында, тау итәгендә, Җәмигъ мәчетеннән бераз төньяккарак китеп урнашкан. Бина XIV гасыр уртасында эшли башлый.



*Интерьер бани «Красная палата». Графическая реконструкция В.Ф. Зиновьева. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*«Кызыл пулат» – мунчаның эчке күренеше В.Ф. Зиновьев. График реконструкция. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



Кызыл пулат – Болгар шәһәренең иң эре мунчаларыннан санала, нигезенең үлчәмнәре: 32×16–24 метр. Казу эшләре бинаның 1,5–2 метр биеклектә (көньяк-көнчыгыш почмагында 3 метрга кадәр) сакланып калган фундаментын һәм стеналарын ачты. Бер метрга якын киңлектәге фундамент һәм стеналарның аскы өлеше таштан, ә өске өлеше – җылыту миче, бина өстендәге ярымсферик гөмбәз – квадрат кирпечтән (25×25×4 см) салынган. Эчке төзелеше, планировкасы ягыннан караганда ул – гадәти Шәрык мунчасы. Үлчәмнәре 14×16 метрлы үзәк залның дүрт почмагына 4×4 метрлы юыну-парлану камералары урнаштырылган. Төп залның үзәгендә 12 аерча розеткасы рәвешендәге фонтан, ә диварлар уртасында суы краннардан агып чыга торган таш юынгычлар урнашкан. Зал өстән олы гөмбәз һәм кечерәк үлчәмле дүрт тартма гөмбәз белән ябылган була. Үзәк залны яктырту өчен гөмбәз өстендә пыяла тәрәзәләр һәм түбәндәрәк кечерәк тәрәзәләр хезмәт иткән. Казу эшләре вакытында бик күп пыяла кыйпылчыклары табылган.

Бу залга капма-каршы бер яктан мунча алды – үлчәмнәре 7,6×4,2 метрлы чишенү бүлмәсе, икенче яктан – салкын һәм кайнар су өчен таш цистерна һәм зур бакыр казан урнаштырылган ярдәмче эш бүлмәсе, шулай ук су һәм бүлмәләрне җылыту өчен ике мич килеп кушылган. Стенада, идәннән 45 см биеклектә, җылытылган төтен газлары, кайнар

*Кемаль-ад-Дин Бехзад. Гарун аль Рашид в бане Миниатюра из «Хамсе» Низами. 1495/1496*

*Кемал-ад-Дин Бехзад. Һарун әр-Рәшид мунчада. Низаминың «Хәмсә» әсәреннән миниатюра. 1495–1496. © Британия китапханәсе. Лондон, Англия*



*Интерьер центрального зала Красной палаты Репродукция рисунка Н.О. Фреймана. 1939–1940*

*Н.О. Фрейман. «Кызыл пулат»-ның үзәк залы. 1939–1940*



*Фонтан калдыклары. XIV гасыр уртасы © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*

*Общий план бани «Красная палата» (по А.П. Смирнову)*

*«Кызыл пулат»ның гомуми планы А.П. Смирнов буенча*





*Баня «Красная палата» Вид на фонтан через арку из юго-западного помещения. Фотография Н.О. Фреймана. 1939–1940*

*«Кызыл пулат». Фонтан. Көньяк-көнбатыш бүлмә ягыннан күренеше. 1939–1940*
*© Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*

*Водоём из бани «Красная палата». XIV век. Известняк. Болгарское городище. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*«Кызыл пулат»ның су җыя торган корылмалары. Бурташ*
*© Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



купола над помещениями – из квадратного кирпича (25×25×4 см). Планировочная структура его характерна для восточных бань. Главным помещением является крестообразный центральный зал размерами 14×16 м, расчленённый на четыре угловые камеры-мыльни (4×4 м). В центре крестообразного зала расположен фонтан в виде 12-лепестковой розетки, а посреди стен – каменные водоёмы. Зал был перекрыт куполом и четырьмя коробовыми сводами. Между ними находились купольные перекрытия угловых комнат. Для освещения центрального зала служили застеклённые окно на вершине купола и окна по его окружности. Осколки оконного стекла в большом количестве обнаружены при раскопках.

К этому залу с двух противоположных сторон примыкали предбанник (7,6×4,2 м) – комната-раздевальня с каменными сиденьями у стен и служебное помещение с каменной цистерной для холодной и медным котлом для горячей воды, а также две печи для нагревания воды и помещений. В кладке стен на высоте 45 см от уровня пола имелись специальные горизонтальные ниши под гончарные трубы (дымогарные, для горячей и холодной воды). Дымогарные трубы диаметром 20–25 см соединялись с подпольными каналами отопления. Вход в баню был обрамлён арочным порталом шириной около 4 м. Перед ним открывалась площадь, в центре которой находился или искусственный водоём, или, скорее всего,

*Реконструкция бани № 1 на предполагаемом месте размещения объекта*
*1 нче мунчаның реконструкциясе (элек торган дип уйланылган урында)*





*Баня № 2 в процессе консервации после повторного вскрытия в 2011 году*
*2 нче мунча 2011 елда яңадан казып чыгарылганнан соң консервация эшләре вакытында*

һәм салкын су йөри торган керамик торбалар өчен горизонталь уемнар эшләнгән. 20–25 см диаметрлы төтен торбалары идән астында урнашкан җылыту каналлары белән тоташтырылган. Мунча ишеге 4 метр киңлектәге аркалы портал белән бизәлгән. Ишек каршында уртасында бассейны яисә су бөркеп торган фонтаны булган мәйдан барлыкка килгән. Фонтан версиясе вертикаль торба урнаштыру өчен блок-бүлгеч куелган керамик суүткәргеч ватыклары белән раслана.

***1 нче мунча*** XIV гасыр башында салынган һәм ул башта гади шәһәр кешеләре өчен төзелгән: күләме белән артык зур түгел (14×9 м), эчке планировкасы һәм интерьеры гадиләштерелгән, ә табылдыклар арасында байлыкның беренче билгесе буган ялтыравыклы савыт-саба ватыклары бөтенләй юк.

Әлеге мунча харәбәләре Кызыл палатадан көнчыгыш якта, аннан 150 метр чамасы ераклыкта урнашкан. Археологлар тарафыннан 1950 елда тикшерелгән. Ул аркылы ике стена белән өч өлешкә бүленгән турыпочмаклы (14×9 м) бина булган. Төньяк-көнчыгыш өлеше (3×5,5 м) киенү-чишенү һәм ял бүлмәсе булып хезмәт иткән, аның суфа тибындагы җылытыла торган ятагы да булган. Юына торган үзәк зал (6×6,5 м) мичтән идән астында урнашкан торбалар буенча килә торган кайнар һава белән җылытылган. Әлеге мич үзе юыну залына төньяк-көнбатыш яктан килеп тоташкан ярдәмче бүлмәдә (7×3 м) торган. Ул мичне тышкы яктан якканнар – аның тамагы ишегалды ягына төньяк-көнбатыш диварда ясалган уем аша чыккан. Суны мунчаның төньяк-көнчыгыш ягын-

фонтан, что доказывается остатками керамического водопровода с блоком-распределителем для установки вертикальной трубы.

***Баня № 1,*** построенная в начале XIV в., изначально предназначалась для горожан: она имела небольшие размеры (14×9 м), упрощённую планировку и оформление интерьера, а среди находок не было даже ни одного фрагмента поливной керамики – самый простой признак зажиточности.

Руины Бани № 1 были обнаружены в 150 м к востоку от Красной палаты и исследованы в 1950 г.. Она имела прямоугольную форму (14×9 м), разделённую двумя поперечными стенками на три части. Северо-восточное помещение (3×5,5 м) – предбанник с входной дверью и суфой-лежанкой – служило раздевальной и комнатой отдыха. Центральный зал мыльни (6×6,5 м) обогревался печью с системой дымоходных каналов под полом, расположенной в пристроенном к мыльне с юго-западной стороны служебном помещении (7×3 м). Печь отапливалась снаружи – её устье выходит за пределы здания через юго-западную стену. Воду брали из неглубокого (2,5 м) колодца, вырытого буквально в 1 м от юго-восточной стены бани. Вода из колодца подавалась по деревянному жёлобу прямо в цистерны, установленные в служебном помещении. Из-под завала здания было извлечено большое количество обломков водопроводных, дымогарных и канализационных труб.

***Баня № 2*** имела сложный план со всеми помещениями и оборудованием, характерными для восточных бань-хаммамов; тщательностью подбора и обработки строительных деталей; богатство оформления интерьера (например, следы полихромной фресковой росписи стен центрального зала); наличием широкой площади перед входом, оснащённой фонтанами и выложенной каменными плитами; богатый вещевой (с многочисленными предметами импорта) и нумизматический комплексы[9].[1]

Баня эта располагалась к западу от Красной палаты на левом берегу р. Мелёнки. Исследовалась раскопками в 1951 г.

Общие размеры прямоугольной постройки – 20×11 м. Она состояла из трёх частей, что характерно для большинства болгарских бань: предбанника (6,2×3 м), центрального зала (10×9 м) и топочного помещения (2,6×9 м). Стены толщиной 0,8–0,9 м сложены из рваного бута со следами грубой отёски, дверные проёмы облицованы блоками белого известняка с хорошей обработкой поверхности камней.

Вход находился в северо-восточной стене предбанника. Слева от него, в углу предбанника, устроена отапливаемая суфа-лежанка (2×0,4 м), сложенная из камней. Центральный крестообразный зал имел четыре угловые комнаты-мыльни

[9] Город Болгар. Монументальное строительство, архитектура, благоустройство / Отв. ред. Г.А. Фёдоров-Давыдов. М.: Наука, 2001. С. 226.



*Предполагаемый внешний облик объекта с юго-восточной стороны*
*Мунчаның көньяк-көнчыгыш яктан тышкы күренеше. Реконструкция*

нан бер-ике метр ераклыкта гына казылган сай коедан алганнар. Коедан су агач улактан турыдан-туры ярдәмче бүлмәдә урнаштырылган цистерналарга аккан. Казу эшләре вакытында мунча харәбәләреннән күп санда керамик торба ватыклары килеп чыга.

***2 нче мунчаның*** планировкасы катлаулы, Шәрык мунча-хаммамнарына хас булган бүлмәләре һәм җиһазлары, җентекләп сайланган



*Баня № 2 в разрезе с демонстрацией основных помещений и коммуникаций (рис. 148–150 по И. Артамонову и А. Леухину)*
*2 нче мунча киселеше: төп бүлмәләр һәм коммуникация корылмалары күренеп тора*



*Павильон для музеефикации бани № 2*
*2 нче мунчаны музейлаштыру өчен корылган павильон. 2000 нче еллар*



(2,6×2,2–2,6 м), обращённые к центру «креста».

Служебная (топочная) часть бани разделена глухой каменной стеной на два помещения. Юго-западное помещение с внутренними размерами 2,6×2,6 м имело пол, устроенный на 55 см выше пола центрального зала, скорее всего, в целях достижения необходимого напора во внутрибанной водопроводной системе. Заметим также, что и пол, и стены помещения на высоту 60 см покрыты слоями водонепроницаемого раствора («цемента») толщиной 20 см. Судя по всему, это помещение представляло собой цистерну для холодной воды. В другом помещении (4,5×2,2 м), пол которого был ещё выше, чем дно цистерны для холодной воды, располагалась вторая цистерна – для подогрева и подачи горячей воды. Рядом стояла печь в виде усечённого купольного свода (диаметр у основания 1,4 м), перекрытого дном вмазанного в него медного котла. Устье её выведено через сквозное отверстие в стене за пределы здания. От печи шла разветвлённая система каналов подпольного отопления и водоснабжения помещения.

Вода в баню подавалась из озера или искусственного водоёма на верхней террасе городища, возвышающейся над баней почти на 40 метров, по керамическим водопроводным трубам. В ходе раскопок обнаружены каменные водоёмы, гончарные тройники-распределители.

***Баня № 3***, расположенная в западной части заречья на правом берегу р. Мелёнки, построена, по мнению исследователей, в середине XIV в. в одном из посадов, отдалённых от центра города. Довольно крупное здание (12×15 м) с топочным пристроем в северо-западном конце (7×4 м) имеет те же функциональные части, которые характерны для всех типов бань: предбанник-раздевальня, главное помещение с центральным залом и мыльнями, служебное помещение с печью и цистернами для холодной и горячей воды. Наличие системы внутреннего водоснабжения и канализации демонстрируют многочисленные обломки гончарных труб и дымоходные каналы под полом.

***Белая палата,*** расположенная в юго-западной части верхнего плато городища, примерно в 100 м к югу от «Чёрной палаты», имела достаточно хорошую сохранность, судя по гравюрам Андре Дюранда (1839) и зарисовкам художников Н.Г. и Г.Г. Чернецовых (1838), вплоть до середины XIX в. Археологами это сооружение исследовалось дважды – в 1887 и 1979–1983 гг. По нумизматическим данным, баня была построена в 1330–1340-х гг. и функционировала не более 20–30 лет.

Это было прямоугольное в плане здание, вытянутое с севера на юг на 30 с лишним метров. Ширина постройки, имевшей прямую восточную и ступенчатую западную стены, составляет в северной части 10 м, в средней и южной (топочной) частях – 13,5 и 17 м соответственно. Фундамент толщиной 1,4 м и стены толщиной около 1 м сложены в технике панцирной

төзелеш детальләре, яхшы итеп шомартылган таш блоклар, интерьерны бизәү байлыгы (мәсәлән, үзәк зал стеналарындагы полихром орнамент эзләре), мунча алдында фонтаннар белән җиһазландырылган һәм таш плитәләр җәелгән киң мәйданы булган.

Бу мунча Кызыл палатадан көнбатышка таба Мелёнка елгасының сул як ярында урнашкан. Археологлар тарафыннан 1951 нче елда тикшерелгән.

Турыпочмаклы корылманың пландагы үлчәмнәре – 20×11 метр. Бина күпчелек болгар мунчалары өчен хас өч өлештән тора: киенү-чишенү һәм ял итү өчен мунча алды (6,2×3 м), юыну өчен үзәк зал (10×9 м) һәм җылыту миче, салкын һәм кайнар су өчен цистерналар куелган ярдәмче бүлмә (2,6×9 м). Бер метр чамасы калынлыктагы стеналары тупас эшкәртелгән бут ташыннан салынган, ишек уемнары яхшылап шомартылган ак таш блоклар белән тышланган.

Керү ишеге мунчаның төньяк-көнчыгыш диварында урнашкан. Сулда, мунча алды почмагында, озынлыгы 2, киңлеге 0,4 метрлы җылытыла торган суфа – таштан ясалган ятак урнашкан. Үзәк залының һәр почмагында 2,6×2,2–2,6 метр үлчәмендәге парлану-юыну бүлмәләре.

Мунчаның өченче бүлмәсе үз чиратында таш стена белән тагын ике өлешкә бүленгән. Мәйданы 2,6×2,6 метрлы көньяк-көнбатыш бүлмәнең идәне үзәк зал идәненнән 55 сантиметрга югарырак – үзәкләштерелгән су үткәрү системасында кирәкле басымга ирешү максатыннан шулай ясалгандыр. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, әлеге бүлмәнең идәне дә, 60 см биеклеккә кадәр стеналары да 20 см калынлыктагы су үткәрми торган измә («цемент») катламы белән сыланган. Биредә, күрәсең, салкын су тутырыла торган цистерна торгандыр. 4,5×2,2 метр үлчәмле икенче бүлмәнең идәне тегесенекенә караганда да биегрәк. Ул цистерна кайнар су җылыту һәм саклау өчен яраклаштырылган. Шул цистерна янәшәсендә генә диаметры 1,5 метрлы ярымшар рәвешендәге мич торган. Аның тамагы бинадан тышка үтәли тишек аша чыгарылган. Мичтән бинаны җылыту һәм су белән тәэмин итү каналларының тармакланган системасы башланып киткән.

Цистерналарга, ягъни зур мичкәләргә су күлдән яисә мунчадан 40 метр биеклектәге тау башына урнашкан ясалма сулыктан суүткәргеч торбалар буенча килгән. Казу эшләре барышында керамик торба ватыклары һәм өч тармаклы субүлгечләр табылган.

***3 нче мунча*** Мелёнка елгасының уң як ярында, елга аръягының көнбатыш өлешендә урнашкан. Тикшеренүчеләр фикеренчә, XIV гасыр уртасында, шәһәр үзәгеннән ерактарак урнашкан кала бистәсенең берсендә төзелгән. Бина үзе шактый зур – мәйданы 12×15 метр һәм ул барлык төр мунчаларга хас функциональ өлешләргә ия: киенү-чишенү бүлмәсе; почмакларында парлану-юыну бүлмәләре булган үзәк зал; мич, салкын һәм кайнар су өчен цистерналы




*Баня № 3. Схема размещения внутренних помещений*
*3 нче мунча. Эчке бүлмәләрнең урнашу тәртибе*

кладки из крупных кусков известняка, скреплённых качественным известково-алебастровым раствором. Внутренние стены и свод центрального зала украшены штукатурными профилированными архивольтами, кессонами и т. д. Главный арочный вход находился с восточной стороны и вёл в раздевальню с каменными скамьями по периметру. Предбанник-раздевальня (7×7,6 м) и смежное с ним тамбурное помещение (7,6×2,7 м) не отапливались.

В главное помещение (12×12 м), в который вписан центральный крестообразный зал с каменной чашей фонтана и квадратными (3×3 м) моечными помещениями по углам, можно было попасть через дверной проём шириной 0,6 м. Центральный зал высотой около 6 м, сложенный из отёсанных известняковых камней, завершался, судя по рисункам XIX в., куполообразной крышей. Вдоль стен моечных камер располагались каменные чаши водоёмов. К нему с южной стороны примыкало отопительное помещение, где стояли две большие круглые печи и цистерны-чаны для горячей воды. Печи были круглые в плане, диаметром 2 м с сохранившейся высотой около 1,7 м. Отсюда в центральный



*Н.Г. Чернецов. В развалинах предполагаемых бань в Болгарах. Изображён центральный зал Белой палаты с южной стороны*

*Н.Г. Чернецов. Болгар мунчалары хәрабәләрендә. Иллюстрация китаптан: Воспоминания из путешествия по Волге. 1862. Ак пулатның үзәк залына көньяктан күренеш*



*Баня «Белая палата». Литография А. Дюрана и А. Раффе из серии «Руины Булгара». 1839*
*«Ак пулат» мунчасы. «Болгар хәрабәләре» сериясеннән. А. Дюран һәм А. Раффе литографиясе. 1839. © Татарстан Милли музее. Казан*

ярдәмче бүлмә (аның мәйданы 28 квадрат метр чамасы). Мунчаны су белән тәэмин итү, канализация һәм гадәти җылыту системасы булганлыгын күп санлы керамик торба ватыклары, идән астында төтен йөри торган каналлар күрсәтеп тора. Бина интерьерының декоратив бизәлешенә ишарә ясый торган фактлар юк. Табылдыклар гадәти, арада, берән-сәрән очрый торган акчалардан башка, мунчага йөрүчеләрнең байлыгын күрсәтә торган әйберләр юк.

***Ак пулат*** Кара пулаттан көньяк-көнбатышка таба 100 метр ча-




*Общий план Белой палаты (по Р.Ф. Шарифуллину)*
*Ак пулатның гомуми планы (Р.Ф. Шәрифуллин буенча)*



*Белая палата после консервационных работ начала 2000-х годов*
*Ак пулат консервациядән соң*

зал по подпольным каналам шёл горячий воздух. Водопроводные и канализационные системы из керамических труб были заложены в стены. Вертикальные трубы в толще продольных стен моечных помещений создавали тягу в подпольной системе отопления.

В архитектурном решении Белой палаты археологи прослеживают традиции архитектурных школ Средней Азии, Крыма и Закавказья, видоизме-

*И.И. Шишкин. Развалины Булгар (Белая палата). 1861.*
*Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан*
*И.И. Шишкин. Болгар хәрабәләре. (Ак пулат). 1861*
*© Татар дәүләт рәсем сәнгате музее. Казан*



масы ераклыкта урнашкан. Бу тирәдә кайчандыр шәһәрнең югары катлау кешеләре яшәгән. Бина XIX гасыр уртасына кадәр чагыштырмача яхшы хәлдә сакланган. Аның түбәләре ишелеп төшкәнчегә кадәрге тышкы күренешен Андре Дюранд гравюралары һәм бертуган Н.Г. һәм Г.Г. Чернецовлар төшергән рәсемнәр буенча (алар бүген Петербургта Рус музеенда һәм Третьяков галереясында саклана) шактый ачык итеп күз алдына китереп була. Археологлар бу корылманы ике тапкыр – 1887 нче һәм 1979–1983 нче елларда тикшерәләр. Нумизматика мәгълүматларына карганда, мунча 1330–1340 нчы елларда төзелгән һәм 20–30 елдан да артык эшләмәгән. Архитектурасы һәм төзелеш үзенчәлекләре ягыннан караганда, ул без югарыда сөйләп үткән Кызыл пулатка охшаш.

Ак пулат – төньяктан көньякка 30 метрга сузылган турыпочмаклы бина. Киңлеге төньякта 10 метр, урта һәм көньяк өлешләрендә 13,5 һәм 17 метр. 1,4 метр калынлыктагы фундамент һәм 1 метр калынлыктагы диварлар бурташ-алебастр измәсе белән беркетелгән эре ташлардан панцир салу техникасында салынган. Үзәк залның эчке диварлары һәм гөмбәз



*Белая палата. Внутренний вид. Фотография 2000-х годов*
*Ак пулатның эчке күренеше. 2000 нче еллар*



*Белая палата. Вид на центральный моечный зал из боковой комнаты-мыльни*
*Фотография 2000-х годов*
*Ак пулат. Үзәк юыну залы күренеше 2000 нче еллар*

түбәсе штукатурлы профильле архивольтлар, кессоннар белән бизәлгән. Аркалы төп ишек көнчыгыш якта урнашан һәм шул ишектән стена буйлап таш эскәмияләр куелган чишенү бүлмәсенә кергәннәр. Бу бүлмә (7×7,6 м) һәм аның белән чиктәш тамбур янкорылмасы (7,6×2,7 м) җылытылмаган.

Чишенү бүлмәсеннән ишек аша 12×12 метр мәйданны биләп торган һәм гөмбәз түшәменең биеклеге 6 метрга җитә торган үзәк залга үткәннәр. Зал уртасында фонтанның таш касәсе һәм һәр почмагында планда 3×3 метр үлчәмле юыну-парлану бүлмәләре урнашкан. Аларның һәрберсендә суы стенага беркетелгән краннан ага торган таш юынгычлар булган. Төп залга көньяктан ярдәмче янкорма килеп кушыла, анда ике зур түгәрәк мич һәм цистерналар – кайнар һәм салкын су өчен чаннар куелган. Мичләрнең диаметры 2 метрга җитә, сакланып калган биеклеге 1,7 метр чамасы. Шул мичләрдән үзәк залга таш идәннәрне җылыту өчен идән асты каналлары буенча кайнар һава килеп торган. Керамик суүткәргеч торбалар, канализация торбалары стеналардагы уемнарга салынгын. Яктылык гөмбәздәге һәм диварлардагы тәрәзәләрдән төшкән.

Ак палатаның архитектурасында археологлар Урта Азия, Кырым һәм Кавказ архитектура мәктәпләренең үзебезнең җирле климат шартларына яраклаштырылган традицияләрен күзәтәләр.

***Көнчыгыш пулат*** археологлар тарафыннан 1984–1994 нчы елларда тикшерелде. Көнчыгыш пулат Зур Иерусалим чокырының көнчыгыш ягында урнашкан. Ул Болгарның иң эре архитектура һәйкәле булып тора – аның гомуми мәйданы 700 квадрат метрдан артып китә (39×19 м). Корылма, башка мунчалар кебек үк, планда турыпочмаклы, ә үлчәмнәре буенча төрле өч өлештән тора.

Урамнан керүче кеше иң әүвәл чишенү бүлмәсенә эләгә. Аның стеналарына терәтеп, җылытыла торган суфа – кирпеч ятак куелган. Кечкенә генә арадаш коридор аша киенү бүлмәсеннән җылытыла торган икенче мунча алды бүлмәсенә (биредә кайнар мунчага керер алдыннан җылынып утырганнар булса кирәк), аннан соң гына мунчаның үзәк өлешенә үткәннәр. Соңгысы дүрт почмагында да юыну-парлану камералары булган иркен залдан гыйбарәт. Үзәк зал дивары янына, көнчыгыш яктан, кайнар һәм салкын су тутырылган чаннар һәм җылыту миче урнаштырылган ярдәмче бина килеп тоташа. Бу бинадан керамик торбалар аша үзәк залга су килгән, идән астындагы канаулардан кайнар һава бирелгән.

Казу эшләре вакытында табылган нумизматика материаллары күрсәткәнчә, Көнчыгыш җәмәгать мунчасы 1290 нчы еллар башында ук төзелгән һәм 1330–1340 нчы елларга кадәр эшләп торган.

Мунчаның сакланышы төрле участокларында төрлечә. Аның көнчыгыш өлешендә сакланып калган стеналарының биеклеге 1,4 метрга җитә, көнбатыш өлешендә исә фундамент нигезенең эзләре генә сизелеп тора. Кайбер урыннарда идән һәм идән

нённые с учётом местных климатических условий.

***Восточная палата,*** исследованная археологами в 1984–1994 гг., расположена у восточного склона Большого Иерусалимского оврага. Она является самым крупным архитектурным памятником Болгара (39×19 м). Контур постройки состоит из трёх прямоугольных в плане и различных по размеру помещений.

С улицы посетитель попадал в предбанник – раздевальню с подогреваемой суфой-лежанкой, сложенной из кирпича. Центральная часть бани, куда можно было попасть из раздевальной через небольшое промежуточное помещение, представлял собой крестообразный в плане зал со вторым отапливаемым предбанником и четырьмя угловыми моечными камерами. В восточной, служебной части бани, примыкающей к стене центрального зала, размещались цистерны с горячей и холодной водой, которая подавалась в центральный зал по водопроводным трубам, и отопительная печь с разветвленной системой воздухоотводных каналов для подачи горячего воздуха.

Как показал анализ нумизматического материала, полученного при расчистке помещений, баня интенсивно функционировала уже в начале 1290-х гг. и просуществовала до 1330–1340-х гг.

На момент раскопок отдельные помещения бани имели различную сохранность. Часть плана сооружения была реконструирована на основании зачистки глинобитного ленточного фундамента, усиленного столбиками-коротышами. Лучшая сохранность каменных кладок зафиксирована в восточной части здания. Здесь отдельные участки стен с воздухоотводными каналами сохранились на высоту до 1,4 м. Помимо хорошей сохранности (на высоту трёх рядов кладки до 0,32 м) отопительных каналов суфы в предбаннике, необходимо отметить удовлетворительную сохранность вымостки пола из красноглиняных кирпичей-плинф. Плинфовое покрытие этого предбанника зафиксировано на площади 3,5×5,0 м.

Как видим, все бани Болгара представляют собой, за исключением Бани № 1 с анфиладным расположением помещений от входа к топке, типичные восточные хаммамы. Планировочная структура таких сооружений выглядит следующим образом: прямоугольный или квадратный объем с вписанным в него крестообразным залом, между сторонами которого устроены квадратные кабины-мыльни, представляет собой основу постройки и имеет подпольную систему обогрева. С двух противоположных сторон к нему, как правило, пристраивались служебные и вспомогательные помещения. Служебная часть предназначалась для тепло- и водоснабжения центральных помещений. Вспомогательные комнаты, иногда отделённые от мылен промежуточным тамбурным помещением, предназначались для переодевания и отдыха посетителей. Вариантами этого классического типа, причём




*Общий план Восточной палаты на уровне подпольной системы отопления (по Р.Ф. Шарифуллину)*

*Көнчыгыш пулатның гомуми планы (идән астыннан җылыту системасы тигезлегендә) Р.Ф. Шәрифуллин буенча*

*Восточная палата. Реконструкция интерьера и инженерного обеспечения*

*Көнчыгыш пулат. Интерьерының һәм инженерлык корылмаларының график реконструкциясе*





***Восточная палата. Современный вид***
***Көнчыгыш пулатның бүгенге күренеше***

весьма близкими, и являются бани города Болгара. Это роднит их с подобными же сооружениями Нижнего Поволжья, Азербайджана и Средней Азии.

### *Мусульманские эпиграфические памятники Болгара*

Ярким свидетельством распространения мусульманской культурной традиции являются могильники и погребальная обрядность. На территории Волго-Уралья в настоящие время исследовано более 80 грунтовых могильников, из которых 52 относятся к домонгольскому периоду (X–XIII вв.), а остальные к золотоордынскому времени. Мусульманский погребальный обряд становится доминирующим с рубежа X–XI вв. до середины XIII в. и приобретает единообразные «канонические» формы.

В золотоордынский период в связи с переменами в религиозной практике происходят изменения в погребальном обряде и во второй половине XIII в. начинается установка каменных эпиграфических памятников и сооружений мавзолеев дюрбе. Надписи на средневековых эпиграфических памятниках, сохранившихся на территории городища, в начале 1840 гг. исследовал известный



*Печь бани Восточная палата. Вид со стороны рабочего места истопника*
*Фотография после консервации и частичной реставрации объекта*
*Көнчыгыш пулатның миче. Консервациядән һәм өлешчә реставрациядән соңгы күренеше*

астыннан килә торган җылыту каналары канәгатьләнерлек сакланган. Шуларның барысын да исәпкә алып һәм, инде яхшырак тикшерелгән мунчалардан алынган мәгълүматка таянып, әлеге бина харәбәләрен туристларга күрсәтү өчен, өлешчә реставрация алымнарын кертеп, консервацияләп куйдылар.

Күргәнебезчә, Болгарның барлык мунчалары да диярек үзләренең архитектурасы, төзелеш үзенчәлекләре ягыннан мөселман илләрендә таралган мунча-хаммамнарга бик охшаш. Аларга иң якын тиңдәшләрне Түбән Иделдә, Әзербайҗанда һәм Урта Азия шәһәрләрендә табарга мөмкин.

### *Болгарның мөселман эпиграфик һәйкәлләре*

Мөселман мәдәни традицияләр таралуының ачык дәлиле булып каберлекләр һәм күмү йолалары тора. Идел-Урал төбәгендә бүгенге көндә 80 нән артык каберлек тикшерелгән, шуларның 52се монголларга кадәрге чорга (X–XIII гасырлар), калганнары Алтын Урда чорына карый. Ислам дине буенча җирләү, бердәм «каноник» формаларга ия булып, X-XI гасырлар чигеннән XIII гасыр урталарына кадәр өстенлек итә башлый.

Алтын Урда чорында дини практикадагы үзгәрешләр күмү йолаларын да үзгәртә, һәм XIII гасырның









*Бордюр намогильного памятника, отделяющий основной текст эпитафии от заглавной коранической формулы: «Он живой, который не умирает». Оформление бордюра – вьющаяся ветвь «ислими» (виноградная лоза)*

*Каберташ каймасы (бордюры). Төп текстны тимпандагы язмадан («Ул – мәңге тере, һичкайчан үлмәячәк») аерып торучы бизәк йөзем тәлгәше («ислими») рәвешендә ясалган*

*Намогильный памятник, поставленный над захоронением золотых дел мастера Шахидуллы и прорисовка эпиграфической надписи на нём 1317. Болгарское городище. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Текст гласит: «Он живой который не умирает / Красы молодцов, сердца сердец, / Уважавшего учёных, одиноких, вдовых / Сирот кормившего Мусы сына, / Золотых дел мастера Шахидуллы, место погребения / (Пусть Аллах) окажет милость, Аминь. В середине месяца раби, / По летоисчислению 717*

*Алтынчы Шаһидулла кабере өстенә куелган эпиграфик таш. 1317*
*© Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*
*Текст: «Ул мәңге тере, һичкайчан үлмәячәк. Галимнәрне хөрмәт итүче, толлар, ялгызлар һәм ятимнәргә ярдәм итүче. Егетләр күрке, күңелләр сафлыгы Муса угылы алтынчы Шаһидулла кабере. Аллаһы тәгаләнең рәхмәтләре ирешсен. Раби' аеның уртасында 717 елда (гүр иясе булды)»*

*Намогильный памятник с восьмилепестковой розеткой в тимпане. 694 год хиджры (1294/95). Известняк. Язык булгарский. Шрифт – куфи рельефный. Болгарское городище. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Текст гласит: Каждая душа вкусит смерть, после / Вы вернетесь к нам. Али йувари (его) дочь / Хум <…> памятник. Да будет милость Аллаха / Над ней милостью обширною / Из мира в мир вечности / Ушёл / По хиджры шестьсот девяносто / Четвёртого года джумади 11 / <…>*

*Тимпанга сигез таҗлы розетка уелган кабер ташы. 649 (1294/95) ел. Болгар телендә, язуы – кабарынкы куфи. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы.*
*Текст: «Һәр җан иясе үлем ачысын татыр, ахырда миңа кайтачаксыз. Али йувари кызы Хум... истәлек. Аллаһының рәхмәте булсын. Фани дөньядан мәңгелеккә күчте һиҗри белән 694 елда»*

*Намогильный памятник. 709 год хиджры (1309/10). Серый известняк. Язык булгарский, шрифт – куфи рельефный. Болгарское городище. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*
*Текст гласит: Он живой, который не умирает / а всё живущее умрёт / сына Аураз‌ Урун-Алпа, / памятник. Да будет милость Аллаха над ним / милостью обширною. Из мира / ушёл: по летоисчислению / семьсот девять лет / раджаба месяца десять дней / было. Смерть – дверь / и все люди /. войдут в неё*

*Кабер ташы. Һиҗри белән 709 ел (1309/10). Болгар телендә, язуы – кабарынкы куфи © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*
*Текст: «Ул мәңге тере, һичкайчан үлмәячәк, һәр җан иясе үләчәк. Аураз Урун-Алп улы кабере. Аңа Аллаһы тәгаләнең шәфкате-рәхимлелеге булсын. 709 ел рәҗәп аеның 10 көнендә фани дөньядан күчте. Үлем – ишек, һәрберебез аңа керәчәк»*



*Тимпан намогильного памятника с коранической формулой, отделённой от основного текста орнаментальным мотивом виноградной лозы. 711 год хиджры (1311/12). Белый известняк. Язык арабский, шрифт сульс рельефный. Болгарское городище. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник. В XVIII веке при строительстве церкви Успения памятник был установлен на северной стороне фундамента*

*Кабер ташы тимпанындагы язулар түбәндәрәк урнашкан төп тексттан йөзем тәлгәше рәвешендәге бизәк белән аерылган. Һиҗри белән 711 (1311/12) ел. Гарәп теле, шрифт – кабарынкы сөлс. XVIII гасырда төзелгән Успение чиркәве нигезенә куелган. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*

русский ориенталист И.Н. Березин. В его книге «Болгар на Волге» впервые были опубликованы интерпретация и анализ надписей. В настоящее время в Волго-Уралье выявлено более золотоордынских 400 намогильных эпиграфических памятников. Половина из них, около 200 каменных надгробий, происходит с Болгарского городища. Конечно, их было гораздо больше. Вспомним слова профессора Казанского университета С.М. Шпилевского *«о том, что будто бы у одного помещика в Спасском уезде выложен на дворе целый тротуар из камней с надписями». «Другой спасский помещик сам рассказывал мне, – продолжает учёный, – как он распорядился о перевозке огромного камня с надписями из с. Успенского, т.е. Болгарского городища, к себе в имение, но, к сожалению, по дороге этот камень возчики разбили».* Часть надгробий использовали при строительстве церкви Успения рядом с Соборной мечетью, ремонте архитектурных памятников, производившихся в XIX в. Ни для кого не секрет, что многие надгробные памятники свезены окрестными жителями под фундамент домов.

В настоящее время более 100 памятников хранится в фондах Болгарского заповедника, из них лишь 32 памятника сохранилось полностью, большинство дошло до нас в сильно разрушенном виде. Около трёх десятков надгробий находятся в фундаменте Успенской церкви.

Болгарские эпиграфические памятники, установленные на могилах знатных булгар, топографически увязываются в основном с некрополем у Соборной мечети и кладбищем у южных ворот городища, где в 2012 г. вскрывались руины каменного мавзолея. Подавляющее большинство каменных надгробий (98,5%) относятся к сравнительно небольшому отрезку времени – восьмидесятым годам XIV – середине XV веков. Это время заката Золотой Орды, когда страна утратила стабильность и наблюдался неуклонный спад благосостояния населения.

Надгробия изготовлены из местного материала – различных видов известняка и имеют форму прямо-



***Тимпан намогильного памятника, декорированный восьмилепестковой розеткой***

***Сигез таҗлы розетка белән бизәлгән каберташ тимпаны***

икенче яртысында таш эпиграфик һәйкәлләр урнаштыру һәм төрбәләр төзү башлана. Шәһәрлек территориясендә сакланып калган урта гасыр кабер ташларына язылган эпиграфика ядкәрләрен 1840 ел башында рус ориенталисты И.Н. Березин өйрәнә. Аның «Идел буендагы Болгар» китабында беренче тапкыр язмаларга аңлатма һәм анализ ясалды. Хәзерге вакытта Идел буе болгарлары яшәгән җирләрдә мөселман күмү йоласының мөһим элементы булган 400ләп эпиграфик һәйкәл – үлгән кешеләрнең кабере өстенә куела торган ташлар ачыкланган. Аларның яртысы, 200гә якын кабер ташы, Болгар шәһәрлегендә табылган. Әлегрәк алар, әлбәттә, күбрәк булган. Казан университеты профессоры С.М. Шпилевскийның «*Спас өязендәге бер алпавытның ишегалдына язулы ташлардан тулы бер тротуар салуы турында*» *сүзләрен искә төшерик: «Икенче бер Спас алпавыты – ул Успенскоедан, ягъни Болгар шәһәрлегендә урнашкан авылдан була инде, – шул авылдан үзенең имениесенә язулы бер зур таш алып кайтырга боерган була. Кызганыч, ди ул, юлда бу ташны йөкчеләр ватып бетергән*». Инде югарыда әйтеп үтелгәнчә, каберташларның бер өлеше Җәмигъ мәчете янында Успение чиркәвен төзегәндә һәм дә XIX гасырда архитектура ядкярләрен ремонтлаганда кулланылган. Беркемгә дә сер түгел: тирә-юньдә яшәүчеләр күп кенә кабер ташларын үзләренең йортларына фундамент салганда файдаланганнар.

Хәзерге вакытта йөздән артык һәйкәл Болгар тыюлыгы фондларына урнаштылырган, шуларның утыз икесе генә тулысынча сакланган, күбесе безгә бик нык җимерелгән хәлдә килеп җиткән. Өч дистәгә якын каберташ Успение чиркәве фундаменты буларак кулланылган.

Билгеле Болгар каберләренә куелган Болгар эпиграфик һәйкәлләре, нигездә, Җәмигъ мәчете янындагы некрополь һәм шәһәрнең көньяк капкасы янындагы зират белән бәйләнгән. Таш каберләрнең күпчелеге (98,5%) чагыштырмача аз вакыт – XIV гасырның сиксәненче еллары – XV гасыр уртасына карый. Бу – Алтын Урданың бөлгенлеккә төшеп, тотрыклылыгын югалтып барган чагы, халыкның яшәү шартлары күзгә күренеп начарайган чоры.

Каберташлар җирле материалдан – известьташның (бурташ) безнең якларда киң таралган төрләреннән

угольника с аркой в верхней части или без неё, на которую наносились кораническая формула или орнамент в виде шести- и восьмилепестковой розетки. Основную поверхность надгробия, окаймлённую, как правило, орнаментированным бордюром, занимал текст. Он оформлялся обычно врезанным шрифтом и содержал кораническую формулу («Жизнь час, используй её на благочестивые дела»), имена, титулы, родословную покойного и благожелательную формулу («Да будет милость Аллаха, милостью обширною»). По наблюдениям специалистов, памятники Болгара и его округи отличаются тщательностью отделки. Большинство из них имеют орнамент на боковых и оборотной сторонах. Выделяются памятники с прямоугольным или полукруглым верхом, со стрельчатой или килевидной аркой, с надписью, выполненной на арабском языке или же на литературном языке Золотой Орды («поволжский тюрки» или «старотатарский»). Как обязательный элемент текста приводится кораническая формула: «Он [Аллах] живой, который не умирает, всё живущее умрёт». Благожелательная формула носит иногда индивидуальный характер: «Да оросит всевышний Аллах его могилу, да дарует ему жилище в раю, да помилует его оставлением грехов и прощением, да вселит его в селения райские».

Типовое оформление, определённая структура и шаблонность отдельных фраз свидетельствуют о существовании болгарской школы по изготовлению надгробий. Характерной чертой её является стрельчатая, реже – килевидная арка с плечиками.

Изучение текстов эпиграфических памятников показывает огромную роль ислама и арабского языка в идеологической жизни булгаро-татарского общества.

* * *

Наше представление о Болгаре золотоордынского периода будет неполным, если мы хотя бы вкратце не затронем вопрос о его благоустройстве. Это выдающийся образец пространственной организации города и пример передового урбанизма в Золотой Орде.

Как известно, основная его территория занимала относительно ровное, местами изрезанное оврагами плато высокой надпойменной террасы левого берега Волги. Довольно плотно была заселена также подгорная часть, располагавшаяся по обоим берегам р. Мелёнки. Рост города в подгорной части вдоль подножия склона и строительство крупных зданий по краю террасы потребовали инженерных сооружений по отводу грунтовых вод и укреплению склона крутого берега волжской террасы. Проблема была решена путём создания довольно сложных по конструкции гидротехнических сооружений, включающих в себя водосборные бассейны, колодцы и каналы, куда поступала вода бьющих из-под склона берега ключей. По отводным трубам она поступала в канал, тянувшийся вдоль склона, а потом стекала в водо-

ясалган. Алар үзләренең эшләнеше һәм тышкы бизәлеше, текст төзелеше һәм теле ягыннан берничә төркемгә бүленәләр. Әмма асылда каберташларның барысы да озынча турыпочмак формасында, өске өлеше ярымтүгәрәк рәвешендә ясалган һәм анда алты яисә сигез таҗлы яфрак рәвешендәге розетка уеп төшерелгән. Каберташның бизәкле бордюр белән каймалап алынган төп өслеген гарәп хәрефләре белән язылган текст биләп тора. Текст «Ул мәңге тере, һичкайчан үлмәс, һәр җан иясе үләчәк»; «Һәр җан иясе үлем ачысын татыячак, ахырда барыгыз да миңа кайтачаксыз»; «Гомер бик кыска мизгел, аны изге гамәлләр кылу өчен куллан» кебек Коръән аятьләреннән алынган сүзләр белән башлана. Төп текстта мәрхүмнең һәм ата-бабасының исеме (кайберләрендә җиде буынга кадәр шәҗәрәсе) күрсәтелә, аннан соң «Я раббем, үзеңнең киң рәхмәтең белән ярлыка», «Аллаһның юмартлыгы, киң рәхмәте яусын», «Аллаһ Тәгалә бу мәрхүмнең каберен җәннәт бакчасы итсә иде, барча гөнаһларын ярлыкаса иде, урынын мәңге җәннәттә насыйп әйләсә иде» кебек мәрхүмгә яхшы теләкләр формуласы язылa.

Белгечләр искәртүенә караганда, Болгар һәм аның тирә-юнендә табылган каберташлар сыйфатлырак, нәфисрәк, башка төбәкләрнеке белән чагыштырганда яхшырак эшкәртелгәннәр. Күбесенең ян-якларында да бизәкләре бар. Кайберләрендә Алтын Урданың әдәби телендә – Идел буе төркиләренә хас иске татар телендә язылган җөмләләр дә очрый. Эпиграфик һәйкәлләр өчен таш Иделнең уң ягында чыгарылган дип уйлыйлар, чөнки Болгардагы барлык архитектура корылмаларының шул таштан төзелгән булуы бәхәссез.

Күпчелек каберташларга хас бертөрле бизәлеш, текстларның структурасы һәм анда формулалар охшашлыгы, аерым фразаларның шаблонлылыгы каберташлар ясау буенча Болгар мәктәбе барлыкка килүен раслый.

Эпиграфик һәйкәлләр текстларын өйрәнү болгар-татар җәмгыятенең идеологик тормышында Ислам дине һәм гарәп теленең гаять зур ролен күрсәтә.

* * *

Шәһәр халкына яшәү өчен уңайлы шартлар тудыруның мөһим бер өлкәсе төзекләндерү, шәһәр территориясен тәртиптә, чисталыкта тоту кебек эшләр белән бәйләнгән.. Әгәр дә без бу мәсьәләгә кыскача гына тукталмасак, Алтын Урда чорындагы Болгар турындагы күзаллауларыбыз тулы булмас иде. Бу шәһәр пространствосын оештыруның кыйммәтле күрсәткече һәм Алтын Урдадагы алдынгы урбанизм үрнәге.

Билгеле булганча, аның төп территориясе чагыштырмача тигез, урыны-урыны белән чокырлар белән кискәләнгән участокны – Иделнең сул як ярындагы яссы калкулыкны биләп тора. Мелёнка елгасының ике ярында урнашкан тауасты өлешендә дә халык шактый тыгыз утырган була. Әмма биредә зур биналар, кайчак хәтта гади генә йортлар төзү өчен дә, грунт суларын корыту һәм Идел

поглощающий колодец. Остатки этих сооружений протяжённостью около 60 м исследовались археологами в 1950-х гг., до затопления этого района водами Куйбышевского водохранилища. Тогда же изучались, на протяжении около 40 м, остатки так называемых ряжей, представляющих собой цепь деревянных срубов удлинённой формы (8×2,5 м), заполненные землёй и щебнем. Они, расположенные по нижнему склону берега, предназначались для укрепления его от размывов вешними и дождевыми водами. Дренажно-ряжевая система сооружений обеспечивала безопасность находившихся в подгорной части города монументальных кирпично-каменных построек, устраняла угрозу затопления территории во время весеннего снеготаяния и сильных ливней в летнее время.

Детальное изучение внутренней планировки города, направленное на выявление уличной сети и площадей, ремесленных слобод и других элементов городского пространства – дело трудоёмкое и требующее раскопок на широких площадях. Однако многолетними систематическими исследованиями городища, начатыми в 1938 г., получен огромный материал по интересующей нас теме. Первый же год раскопок в районе централь-



*Д.И. Архангельский. Болгары. Водоотводной канал дренажной системы в подгорной части городища. 1951. Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Д.И. Архангельский. Болгар. Шәһәрлекнең тауасты өлешендә дренаж системасына караган суүткәргеч канау. 1951. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



*Фрагмент трубопровода. Раскоп Б. 1938. Исследователь А.П. Смирнов*

*Суүткәргеч торбалар. XIII гасыр. 1938 елгы казу эшләре. (А.П. Смирнов буенча)*

калдыклары археологлар тарафыннан 1950 нче елларда, әлеге район Куйбышев сусаклагычы сулары астында калганчы тикшерелә. Шул ук елларда 40 метрга сузылган 8×2,5 м үлчәмендәге агач буралар чылбырын тәшкил иткән, эче исә балчык һәм вак ташлар белән тутырылган ряж (озынча бура. тартма тибындагы гидротехник корылма) калдыклары өйрәнелә. Дренаж-ряж системасы шәһәрнең тауасты өлешендә урнашкан монументаль кирпеч-таш корылмаларның куркынычсызлыгын тәэмин иткән, язын кар эрү һәм җәйге чорда көчле яңгырлар вакытында территорияне су басу куркынычын киметкән.

үзәнен чикләп торган террасса итәген – тау киртләчен ныгыту буенча инженерлык корылмалары булдыру таләп итепә. Проблема су җыю бассейннары, кое һәм каналларны үз эченә алган шактый катлаулы конструкциягә ия булган гидротехник корылмалар төзү юлы белән хәл ителә. Калкулык итәгеннән, сазлыклы урыннардан бәреп чыккан су махсус сузылган торбалар буенча барып, суҗыйгыч коеларга агып төшкән. 60 метрга якын озынлыктагы шундый корылмаларның

Шәһәрнең урам челтәрен һәм мәйданнарны, һөнәр бистәләрен һәм шәһәр киңлегенең башка элементларын ачыклауга юнәлдерелгән эчке планлаштыруны җентекләп өйрәнү – киң мәйданнарда казу эшләре таләп итепә торган эш.1938 нче елда башланган системалы тикшеренүләр

ной части городища выявили участок вымостки из каменных плит, уложенных на щебенистой подсыпке; искусственный водоём, отделанный профилированным камнем, и питающая его система водопровода из керамических труб. Как выяснилось, так была благоустроена площадь перед фасадом большого здания.

При изучении практически всех крупных зданий (общественных бань, мавзолеев) зафиксированы следы мощёных камнем площадей, украшенных иногда фонтаном или искусственным водоёмом. Центральная площадь образовалась перед Соборной мечетью, куда на пятничные намазы шли толпы мусульман не только городских, но и приезжих, которых было много в летние месяцы – сезон ярмарок.

Улицы и площади содержались в чистоте, что характерно практически для всех восточных городов. Об этом свидетельствуют обилие мусорных ям и следы бадрабов (туалетов), выявленных при археологических раскопках.

* * *

В числе городов, упоминаемых в письменных источниках и преданиях татар, значатся, помимо Болгара, Биляр, Джукетау, Кашан, Казань, Елабуга и Кирменчук.

К числу крупных городов Булгарского улуса Золотой Орды относится Биляр. Этот город был полностью уничтожен в 1236 г. и на этом месте не восстанавливался. Биляр золотоордынского времени располагался в другом месте – на левом берегу Малого Черемшана примерно в 3 км от бывшей столицы и занимал площадь более 70 га. Город известен как один из центров чеканки монет. Большинство из них относится к периоду правления хана Менгу-Тимура и обнаружены в кладах 80-х – начала 90-х гг. XIII в.

Раскопки, проводившиеся на территории золотоордынского Биляра в конце прошлого века, представили его как центр высокоразвитого ремесла и торговли. Богатство жителей города XIV в. демонстрируют находки дорогостоящей посуды из нижневолжских городов, ремесленных центров Ирана и даже далёкого Китая.

Одним из немногих булгарских городов, не прекративших своего существования после 1236 года, является ***Джукетау***, археологические остатки которого находятся на левом берегу Камы на западной окраине города Чистополя. Укреплённая часть города, располагавшаяся на высоком мысу, после 1236 г. перестала функционировать, зато ремесленный посад заметно расширился до 150 га. Здесь выявлены остатки черной металлургии в виде горнов для плавки железа, керамического производства (печи для обжига сосудов) и металлообработки (кузницы). Один из кладов, найденный на городище, содержал золотые динары индийских султанов 1340/41 года и ювелирные изделия из золота. Они свидетельствуют о значительной роли Джукетау в международной торговле. Не случайно название города фигурирует на географической карте мира,

нәтиҗәсендә безне кызыксындырган мәсьәләләр буенча күп кенә мәгълүмат тупланды. Шәһәрнең үзәк өлешендә башланып киткән казу эшләренең беренче елында ук таш плитәләр җәелгән борынгы юл, ә якында гына ясалма сулык һәм аның белән тоташкан сусүткәргеч керамик торбалар чылбыры ачыла. Зур бина фасады каршындагы мәйдан шулай төзекләндерелгән булган икән.

Эре җәмәгать биналары тирәсендә фонтан атып торган яки ясалма сулыклары булган, таш түшәлгән мәйданнар барлыкка килгән. Шундый мәйданнарның иң гүзәле Җәмигъ мәчете каршында булган, анда җомга намазларына шәһәр кешеләре генә түгел, җәй айларында – ярминкәләр сезонында чит илләрдән, ерак өлкәләрдән килгән мөселманнар да җыела торган булган.

Урамнарның һәм мәйданнарның чисталыгына нык игътибар биргәннәр – бу барлык Шәрык шәһәрләренә хас. Моны археологик казулар вакытында табылган чүп һәм бәдрәф чокырларының күп булуы да раслый.

* * *

Болгардан кала, рус елъязмаларында, гарәп-фарсы язучыларының әсәрләрендә, татар риваятьләрендә һәм легендаларында Биләр, Җүкәтау, Казан, Алабуга һәм Кирмәнчек кебек шәһәрләр дә телгә алына.

Алтын Урданың Болгар олысы шәһәрләре арасында ***Биләр*** дә бар. Бу шәһәр тулысынча 1236 нче елда юк ителгән һәм үзенең элеккече урынында яңадан торгызылмаган. Алтын Урда чоры Биләре Кече Чирмешән елгасының сул ягында, элеккеге урыныннан 3 чакрым ераклыкта урнашкан һәм 70 гектардан артык мәйданны биләп торган. Шәһәр акча сугу үзәкләренең берсе буларак та билгеле. Ул акчаларның күбесе Мәңге-Тимер ханы идарә итү чорына карый һәм XIII гасырның 80–90 нчы елларында күмелгән хәзинәләрдә табылган.

Алтын Урда Биләре территориясендә узган гасыр ахырында үткәрелгән казу эшләре аны югары үсеш алган һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге буларак күрсәттеләр. Казылмаларда Түбән Идел шәһәрләреннән, Урта Азиянең, Иранның һөнәрчелек үзәкләреннән һәм хәтта ерак Кытайдан китерелгән кыйммәтле савыт-саба табылдыклары чыга.

1236 нче елдан соң яшәүдән туктамаган болгар шәһәрләренең берсе – ***Җүкәтау.*** Монгол яуларыннан соң шәһәрнең ныгытылган өлеше яңадан торгызылмый, аның каравы, һөнәрчелек бистәсе 150 гектарга кадәр киңәйгән. Биредә савыт-саба җитештерү, кара һәм төсле металл эшкәртү кебек һөнәрләр чәчәк аткан. Казу эшләре вакытында тимер кою һәм чүлмәк яндыру мичләре, тимерче алачыгы кебек һөнәрчелек корылмалары ачылган. Җүкәтауда табылган хәзинәләрнең берсендә Һиндстан солтаннарының 1340 нчы елда сугылган алтын динарлары һәм алтын-көмеш бизәнү әйберләре бар. Алар шәһәрнең халыкара сәүдәдәге роле турында сөйли. *Җукәтау* исеме бертуган Пициганилар төзегән дөнья картасына һәм XIV гасырның Каталон атласына очраклы



*Анонимный серебряный дирхем, чеканенный в золотоордынском Биляре. Вторая половина XIII века*

*Алтын Урда чорындагы Биләрдә сугылган көмеш дирһәм һәм аноним акча. XIII гасырның икенче яртысы © Биләр дәүләт тарих-археология һәм табигать музей-тыюлыгы*

составленной братьями Пицигани и в Каталонском атласе XIV в.

Во второй половине XIV в., когда в Улусе Джучи наметились центробежные тенденции в условиях кризиса власти, Джукетау превращается в центр одноименного эмирата – Жукотинского княжества.

Эпоха Улуса Джучи – важный этап в истории ***Казани***. Расположенная в стороне от центральных земель Булгарии, она не подвергалась разорению монголо-татарами. В силу того, что обширные земли Среднего Поволжья и Приуралья оказались в составе Золотой Орды, роль Казани как приграничной крепости была утрачена. Но она не потеряла своего значения как административный и культурный центр обширной округи. Серьёзным фактором в усилении этого региона стал приток населения из южных, закамских, районов, что способствовало формированию знати из пришлого населения. Об этом, в частности, свидетельствуют надгробный камень эмира Хасана второй половины XIV в. на Кабанском городище.

К концу золотоордынского периода Казань благоустраивается, появляются вымощенные деревом улицы, возобновляется каменное строительство, о чем свидетельствуют часто встречаемые в культурном слое поливные облицовочные плитки голубого и бирюзового цвета для наружной облицовки зданий. В посадской части территории города выявлены следы чёрной и цветной металлургии. В целом общеисторическая ситуация этого периода на развитии города сказалась благоприятно.

Ослабление Болгара, особенно после разорительных походов Булак-Тимура (1361) и Фёдора Пёстрого (1431), приводит одновременно к усилению роли Казани в политической жизни Булгарского улуса. Она становится центром монетной чеканки, производившейся на рубеже XIV–XV вв. от имени Гийас ад-Дина. Ш. Марджани писал:



*Браслет. Золотая Орда. XIV век. Происходит из т.н. Джукетаусского клада, найденного близ г. Чистополя в 1924 году (по К.А. Руденко) Государственный Эрмитаж. Санкт-Петербург*

*Алтын беләзек. XIV гасыр. 1924 елда табылган Җүкәтау хәзинәсеннән © Дәүләт Эрмитажы. С. Петербург*



*Джукетау. План городища с окрестностями. Глазомерная съемка Н.Ф. Калинина. 1928. Отдел письменных источников Государственного Исторического музея, Москва. Ф. 598. Д. 61. Л. 1*

*Җүкәтау шәһәрлеге һәм аның тирә-юне планы (Н.Ф. Калинин буенча) © Дәүләт Тарих музееның язма документлар бүлеге. (Ф. 598, д. 61, л. 1)*

рәвештә генә төшерелмәгәндер инде.

XIV гасырның икенче яртысында, Җучи Олысында хакимият кризисы (көрчеге) башланып, Сарайдан аерылып чыгу тенденцияләре тәгаенләнгәч, Җүкәтау шул ук исемдәге билек (кенәзлек) үзәгенә әверелә.

Алтын Урда чоры – ***Казан*** тарихында да мөһим этап. Болгарның үзәк җирләреннән читтә урнашкан шәһәр монголлар тарафыннан җимерелми. Әмма биредә сизелерлек үсеш тә күзәтелми. Урта Идел һәм Урал төбәкләренең Алтын Урда составында булуы сәбәпле, Казанның чик буе ныгытмасы буларак тоткан роле югала. Әмма ул үзенең тирә-юнендәге төбәкләрнең административ һәм мәдәни үзәге буларак әһәмиятен саклап кала. Казан төбәгенең көчәеп китүендә монголлар тарафыннан таланган Кама аръягы җирләреннән килеп урнашкан халыкның күбәеп китүе дә җитди роль уйнаган, әлбәттә. Хакимият тирәсендәге кешеләрнең низаглары нәтиҗәсендә сәяси көрәшләрдә җиңелгән бәкләрнең шау-шулы Болгардан тыныч Казанга күчеп килүе тиздән бу каланы феодал билекнең үзәгенә әверелдерә. Шушы низагларда катнашкан «бөек һәм данлыклы хаким, хакимнәр ярдәмчесе, хөрмәтле һәм җиңелмәс әмир» Мир-Мәхмүт улы Хәсәнбәкнең Кабан шәһәрлегендәге каберенә XIV гасырның икенче яртысында куелган таш бу хакта ачык сөйли.

Алтын Урда чоры ахырына Казан әкренләп төзекләндерелә, калын агач такталар, вак ташлар белән түшәлгән урамнар барлыкка килә, таштан һәм кирпечтән салынган биналар калкып чыга (казылмаларда еш кына шундый бай йорт диварларына ябыштырыла торган полихром плитәләр табыла). Шәһәр территориясенең һөнәрчелек бистәләрендә кара һәм төсле металлургия эзләре ачыкланды. Гомумән алганда, бу чорның сәяси торышы шәһәр үсешендә уңай чагылыш таба

Алтын Урданың таркала башлавы шартларында БулатТимернең (1361) һәм Фёдор Пёстрыйның (1431) җимергеч яуларыннан соң Болгар олысының сәяси тормышында Казанның роле көчәя. Ул әле XIV–XV гасырлар чигендә үк акча сугу үзәгенә әве-

*«Из-за многочисленных смут и бед, обрушившихся на Болгар, его прежнее благополучие пошло на убыль, постепенно все это перешло на Казань, которая и стала наследницей всего этого былого величия».*



***Вымостки из каменных плит и водоём XIII века на одной из улиц в центральной части Болгара, на склоне коренной волжской террасы (по А.П. Смирнову)***

***Болгарның үзәк өлешендәге урамнарның берсендә, Идел яры битләвендә, таш плитәләрдәр түзелгән түшәү һәм су җыю коесы. XIII гасыр. 1938 елгы казу эшләре (А.П. Смирнов буенча)***



***Участок водопровода к бассейну XIII века. Раскопки 1938 года (по А.П. Смирнову)***

***Бассейнга килеп тоташа торган суүткәргеч торбалар. XIII гасыр. 1938 елгы казу эшләре. (А.П. Смирнов буенча)***

релә: Гийас ад-Дин исеме язылган тәңкәләрне нумизматлар Казанда сугылган дип раслыйлар. Мәшһүр тарихчыбыз Шиһабетдин Мәрҗани язганча, *«Болгар өстенә килгән күпләгән фетнәләр һәм бәла-казалар аркасында аның элеккеге муллыгы, иминлеге бетүгә йөз тота, әкренләп боларның барысы да Казанга күчә һәм Казан элеккеге бөеклекнең варисына әверелә»*.



*Джукетау – «Липовая гора». Современная фотография*
*Тау башында – Җүкәтау каласы. Бүгенге күренеше*

## Болгар ал-Джадид – столица Казанского ханства

«Новым Болгаром» названа на монетах Гийас ад-Дина Казань – столица ханства, образованного на землях бывшей Волжской Булгарии и Булгарского улуса Золотой Орды. Казанское ханство стало прямым наследником этих государств и переняло у своих предшественников систему государственного устройства, организации экономической и культурно-идеологической жизни общества.

Образование Казанского ханства связано с изменением политической ситуации в Золотой Орде в конце XIV – начале XV в., когда стал явственным распад Джучиева Улуса, сопровождаемый междоусобными войнами. Усиливающиеся центробежные тенденции проявились, в частности, в борьбе *«Хасана-бека сына Мир-Махмуда, великого и знатного повелителя, помощника повелителей, эмира чтимого, победоносно-*





1. هوالحی الذی لا یموت[وکل حی سیموت]
2. هذا مرقد السلطان الاکبر الاکرام عوث السلا طین
3. الامیر لمکرام . . . . . . . . . .
4. المظفر . . . . . . . . . . .
5. الکرام والاجالیل العظام العلم
6. الی المظفر . . . . . . . . . .
7. الشرفین مفخر ال . . . . . . .
8. والدین . . . . ظ . . . الله العالمین
9. حسن بك بن میر محمود

Дата: предположительно конец XIII в.

„1. Он живой, который не умирает [все живущее умрет].
2. Это место погребения великого и знатного повелителя, помощника повелителей
3. эмира чтимого . . . . .
4. победоносного . . . . .
5. почтенных и великих, знамени . . .
6. к победоносному . . . . . . . . . . .
7. двух почестей . . . гордости рода . . .
8. и веры, тени господа миров
9. Хасан-бек сын Мир-Махмуда".

***Намогильный камень с именем эмира Хасана Вторая половина XIV века. Найден на Кабанском городище (по Г.Ф. Юсупову)***

***Болгар әмире Хәсән исеме язылган кабер ташы. XIV гасырның икенче яртысы (Кабан шәһәрлегендә табылган. Казан) Һ.В. Йосыпов буенча***

## Болгар әл-җәдид – Казан ханлыгы башкаласы

Гийас ад-Дин акчаларында Болгар әл-Җәдид, ягъни Яңа Болгар дип Казан – элеккеге Идел буе Болгары һәм Алтын Урданың Болгар олысы җирләрендә төзелгән ханлык башкаласы аталган. Казан ханлыгы бу дәүләтләрнең турыдан-туры варисы була һәм үз элгәреләреннән дәүләт төзелеше, җәмгыятьнең икътисадый һәм мәдәни-идеологик тормышын оештыру системасын кабул итеп ала.

Казан ханлыгының барлыкка килүе XIV гасыр ахырында – XV гасыр башында Алтын Урдадагы сәяси вәзгыятьнең үзгәрүенә бәйле.

Алтын Урдадан бәйсез, үзенең мөстәкыйль тормышы белән тыныч кына яшәп ятучы Казан билеге (кенәзлеге) тарихында борылыш чоры 1437 нче елда башлана. Шул елда Алтын Урда тәхетеннән куылган Олуг Мөхәммәт хан Кырымдагы биләмәләрен ташлап, Мәскәү Русенең көньяк-көнбатыш чигендәге Ука елгасы янына урнашкан Белёв шәһәрен ала һәм Урта Иделдә Казан кенәзлеге нигезендә яңа дәүләт төзергә омтыла. Тик ул үз планын тормышка ашырырга өлгерми, 1445 нче елда Курмыш шәһәрендә вафат була. Рус елъязмачылары хәбәр иткәнчә, шул ук елның көзендә *«Олуг Мөхәммәт улы Мамотек (Мәхмүтәк, Мәхмүт) Казанны яулап ала, аның вотчичы (кенәзе) Либәйны (Алибәй, Галимбәк) үтерә, үзе патшалык итә башлый»*. Рус елъязмачысына ышансаң, Казан җире халыклары – нигездә (шул исәптән составына Идел буе болгар һәм Урданың төрле өлкәләреннән Идел-Чулманга күчеп килгән төрки-татар нәсел-нәсәпләре кергән) татар халкыннан торган, шулай ук Идел-Урал буе финнары да булган – барысы да Казанда Мәхмүт ханның хакимлек итә башлавын «сөенеп каршы алганнар». Казан ханлыгы чорында элеккеге болгарларны Бату хан гаскәрләре составында монголлар белән бергә Көнчыгыш Европа далаларына килеп утырган татарлар исеме белән атау гадәткә керә.



***Монета хана Пулада, чеканенная на монетном дворе Булгара ал-Джадида – Нового Булгара (по А.И. Бугарчеву и А.З. Сингатуллиной)***

***Болгар әл-Җәдид – Яңа Болгарда сугылган Пулат (Булат) хан акчасы. А.И. Бугарчев һәм А.З. Сингатуллина буенча***

### *XVI гасыр Казаны*

Халыкара сәүдә үзәге буларак, Шәрык һәм Көнбатыш Европа ил-




*Казанское ханство. Художественное воспроизведение карты.*
*Авторы: И. Артамонов, А. Леухин, Ф. Валиуллин,*
*Р. Шигабутдинов, И. Щетинин.*
*Музей Болгарской цивилизации, Болгар*

*Казан ханлыгы. Картаның сәнгатьчә эшләнеше.*
*Авторлар: И. Артамонов, А. Леушин,*
*Ф. Вәлиуллин, Р. Шиһабетдинов, И. Щетинин.*
*© Болгар цивилизациясе музее*





***Казань в первой половине XVI века. Реконструкция Н.Ф. Калинина.***
***1 – Булак; 2 – Казанка, 3 – ворота Нур-Али; 4 – дворец; 5 – Большая северо-восточная башня; 6 – Соборная мечеть; 7 – Тезицкий ров; 8 – кладбище; 9 – Большие ворота; 10 – ров XVI века; 11 – Посад; 12 – Аталыковы ворота; 13 – Теменские ворота; 14 – Даирова баня***

***Казан XVI йөзнең беренче яртысында. Н.Ф. Калинин реконструкциясе.***
***1 – Болак; 2 – Казансу; 3 – Нурали капкасы; 4 – Сарай; 5 – Төньяк-Көнчыгыш башнясы; 6 – Җәмигъ мәчет; 7 – Таҗик чокыры; 8 – зират; 9 – Олы капка; 10 – XVI гасыр чокыры; 11 – бистә (посад); 12 – Аталык капкасы; 13 – Төмән капкасы; 14 – Таһир (Даир) мунчасы***

*го, гордости рода и веры, тени господа миров»*[10], за самостоятельность Болгара от Орды. В результате конфликта он вынужден был покинуть Болгар и жить до последних своих дней в Казани.[2]

Переломный момент в истории княжества наступил с приходом в Волго-Окский регион в 1437 г. бывшего золотоордынского хана Улуг Мухаммада – дальновидного политика, стремившегося основать на базе Казанского княжества новое государство. Но он не успел осуществить свой план до конца. Русские летописцы сообщают, что в 1445 году казанский престол занял его сын, Махмуд: «*Той же осени царь Мамотек, Улу-Магометов сын, взял город Казань, вотчича казанского князя Либея убил, а сам сел в Казани царствовати*». Народы Казанской земли – это были в основном были татары, состоявшие в том числе и из потомков волжских булгар и тюрко-татарского населения переселявшиеся в Волго-Камье из разных областей Золотой Орды, а также поволжско-прикамские финны, – «рады быша» воцарению в Казани хана Махмуда, если верить русским летописцам. Территория Казанского ханства охватывала обширные земли Верхнего Прикамья до Самарской Луки с севера на юг, а также от Посурья до Белой с запада на восток.

Сельское население ханства как и в прежние времена в Среднем Поволжье занималось в основном земледелием и животноводством, в городах развивалось ремесленное производство. Особую группу составляли строители, руками которых возво-

[10] Из эпитафии на надгробном камне, находившемся на Кабанском городище в Казани.

ләрендә дә билгеле булган ханлык башкаласы Казан, бүгенге күзлектән чыгып караганда, артык зур шәһәр булмаган. Аның тау башында урнашкан һәм көчле ныгытмалар белән уратып алынган өлеше (кала – кремль) якынча 10 гектар мәйданны biләп торган. Шул заман кешеләре: «*Казан кирмәне бик нык – таш тау кебек*», – дип язып калдырганнар (А. Курбский). Елъязмачы сүзләренә караганда, хәтта рус патшасы Иван IV Васильевич та, 1552 нче елның август ахырында шәһәргә килеп, «*барын да күздән кичергәч, крепость стеналарының гадәттән тыш матурлыгына һәм ныклыгына соклана*». Казансу һәм Болак ягыннан әлеге стеналарның калынлыгы 5–6 метрга җиткән. «*Ул урыннар һичкем дә ала алмаслык*» саналган. Кирмән стеналарында башнялар һәм капкалар да булган: Зур капка – Хан капкасы (хәзерге Спас башнясыннан төньяктарак), Түбән капкасы (хәзерге Преображение башнясы тирәсендә), Нурали (хәзерге Тайницкая башнясы тирәсендә), Елгабуе (Елбугина, хәзерге Воскресение башнясы урынында) һәм башка капкалар.

Кирмәннең төньяк өлешендә ак таштан салынган һәм тәбәнәк кенә стена белән ныгытылган хөкүмәт резиденциясе урнашкан була. Биредәге Хан сарае башка биналардан үзенең матурлыгы һәм архитектурасының камиллеге ягыннан аерылып торган. Хан сарае каршында, 1565–1568 нче елларда төзелгән «Теркәү китабы»нда («Писцовая книга») күрсәтелгәнчә, «Большая палата» исемле соңгы елларда археологлар тарафыннан тикшерелгән ак ташлы бина (18×24 м) урнашкан. Хан сараеннан ерак түгел, көньяк-көнбатыш якта, хәзерге Сөембикә манарасы янында, Хан һәм, тагын да ерактарак, Нур-Али мәчетләре калкып торган. Хан мәчете янында гына ханнар зираты барлыкка килгән. Археологлар казып тикшергән таш төрбәдә Олуг Мөхәммәт (1445 нче елда вафат), Мәхмүт (1464 нче елда вафат) һәм Мөхәммәт Әмин (1518 нче елда вафат) исемле ханнарның каберләре табылды.

Хан резиденциясе каршында, әмма аннан читтәрәк урнашкан мәйданда, сигез манаралы Җәмигъ мәчете торган. Хан сарае һәм Җәмигъ мәчетеннән бераз ераграк шәһәрнең мөселман руханилары башлыгы, күренекле дәүләт эшлеклесе һәм шагыйрь Кол Шәриф исеме белән аталган тагын бер мәчет булган һәм анда ул заманнарда югары мәктәп вазыйфасын үтәгән мәдрәсә эшләп килгән. Археологлар аның харәбәләрен Благовещение соборы каршындагы бакчада таптылар. Мәчет нигезе астына 1552 елның фаҗигале көзендә зур гына ике акча хәзинәсе күмеп куйганнар. Ул хәзинәләрнең берсендә бөек кнЯзьләр Иван III (1462–1505) һәм аның улы Василий III (1505–1533) идарә иткән чорда Мәскәү, Псков, Тверь, Рязань, Можайск һәм кайбер башка рус шәһәрләрендә сугылган 1449 көмеш тәңкә, икенчесендә күн янчыкка төрелгән 556 тәңкә яшерелгән иде.

Казан кирмәненең калган территориясен дәүләт идарәсенә якын

дились не только деревянные дома, стены и башни городских укреплений, но и «полаты царские и мечети зело высокие, мурованные (каменные)».

В мирных условиях развивалась торговля. По словам одного из западноевропейских купцов и путешественников Иосафато Барбаро, Казань – *«это торговый город; оттуда вывозят громадное количество мехов, которые идут в Москву, в Польшу, в Персию и во Фландрию. Меха получают с севера и северо-востока, из областей Дзагатаев и из Мордовии»*. Следуя традициям Волжской Булгарии и Золотой Орды, Казань стала крупным центром транзитной торговли по Великому Волжскому пути. К ней тянулись восточные и западные торговцы, приезжавшие на международную ярмарку, которая ежегодно устраивалась на Гостином острове. Они обменивались товарами или продавали их крупными партиями. Всемирно известная Казанская ярмарка, преемница Ага Базара Болгара, на этом острове просуществовала до 1525 г. Позднее, в период резкого осложнения казанско-московских отношений, великий князь Василий III запретил купцам ездить на Гостиный остров и перенёс ярмарку в Макарьевский монастырь.

Казань занимала территорию, включая торгово-ремесленные посады и пригородные поселки, около 300 гектаров, и в ней проживало 15–20 тысяч человек. Город состоял из нескольких частей. На высоком мысу у живописного берега Казансу располагалась крепость со сторожевой башней в центре. Мощные оборонительные стены и башни, построенные из дубовых бревен, защищали площадь около 70 гектаров. Очевидцы писали: «Град же Казань крепок – подобен каменной горе». Русский царь Иван IV Васильевич, подступив к городу в конце августа 1552 г. и «смотряше стенныя высоты и мест приступных, и увидев, удивися необычайной красоте стен крепости».

В северной части «града» располагался Ханский двор, укрепленный белокаменной стеной, правда, не такой мощной, как стены самой крепости. В центре Ханского двора своей красотой и великолепием выделялся белокаменный дворец – резиденция правителя, упомянутый в Писцовой книге 1565–1568 гг. под названием «Большая палата» белокаменное здание (18×24 м), исследованный археологами. Рядом с Ханским дворцом, с юго-западной стороны, в районе современной башни Сююмбике, красовались две мечети – Ханская и Нур-Али. Остатки первой из них были открыты археологами. Развалины этой мечети частично уходили под северо-восточный угол башни Сююмбике, построенной не ранее конца XVII века. Любопытно, что башня Сююмбике, стоит, как выяснилось, на развалинах Ханской мечети и практически до сих пор в устной народной традиции татар увязывается с захоронением мусульманских святых или ханов. Оказалось, что не без основания. Здесь выявлены фундаменты белокаменного мавзолея –

торган аксөякләрнең, замандашлары язганча, «бик матур һәм гаҗәпләнүгә лаек» бай утарлары биләп торган, сарай хезмәткәрләре яши торган гади генә йортлар, ашлык саклау амбарлары тезелеп киткән. Шәһәр каласында, Кремльдә, Нурали (Нургали) исемен йөртүче тагын бер мәчет эшләп торган. Аның кайда урнашкан булуы әлегә билгеле түгел, Нурали (хәзерге Тайницкая) башнясы янындарак түгел микән дигән фараз гына бар.

Шәһәрнең төп өлеше, әлбәттә, сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр бистәсеннән гыйбарәт булган. Ул көнбатыштан Болак елгасы, көнчыгыштан Кара, Ак, Мунча, Шакшы (Поганое) күлләре, көньякта исә хәзерге Лобачевский һәм Астрономия урамнары белән чикләнгән 60 гектар чамасы мәйданны биләп торган.

Ханлык чорында шәһәр бистәсе дә кереп-чыгып йөрү өчен 9–10 башнясы булган имән диварлар белән әйләндереп алына. Ныгытмалар 3–4 метр биеклектәге җир үрләр өстенә бер-берсенә терәтеп утыртылган агач буралардан гыйбарәт булган. Буралар эченә туфрак һәм эреле-ваклы таш тутырганнар. Бистә ныгытмалары кирмәннең Нурали башнясыннан (Түбән башнясыннан да булырга мөмкин) Болакка кадәр төшкән, андагы Аталык капкасыннан елганың уңъяк яры буйлап барып, Кырым һәм Көрәеш капкаларына тикле сузылган, аннары, көнчыгыш тарафка борылып, Арча кыры ягына күтәрелгән. Арча кыры капкасыннан стена күлләр янынннан төньякка таба дәвам иткән һәм кирмәннең төньяк-көнчыгын ягындагы Елгабуе капкасына барып тоташкан.

Бистәнең Казансуга якын өлешендә кара һәм төсле металл кою мичләре, тимерчеләрнең, чүлмәкчеләрнең, тире-күн эшкәртүчеләрнең күпсанлы остаханәләре, ә Болак тирәсендә, Нурали манарасыннан ерак түгел җирдә, Таһир мунчасы («Даирова баня») урнашкан була. Хәзерге Үзәк стадионга каршы якта, элеккеге Ташаяк урамы тирәсендә, даими эшләп торучы зур гына базар булган.

Башка урыннарны гади агач йортларда яшәүче шәһәр кешеләре, сәүдәгәрләрнең һәм һөнәрчеләрнең утарлары алып торган. Алар арасында мөлкәтле кешеләрнең, бай сәүдәгәрләрнең агач бүрәнәләрдән, сирәк булса да кирпечтән салынган, шул заман кешеләре язганча, икешәр катлы «гаҗәпләндерерлек матур» йортлары аерылып торган. Кызганыч, язма чыганакларда Казан бистәләрендәге мәчетләр һәм башка җәмәгать биналары турында хәбәрләр сакланмаган. Алар да булган, әлбәттә. Мөселман шәһәрен диварлары төсле чынаяк плитәләр белән капланган мәчетләр һәм аларның югарыга омтылган манараларыннан башка күз алдына да китереп булмый. Шул мәчетләре бит инде шәһәргә үзенә бер төрле матурлык биреп торган һәм чит ил кешеләре аны «искиткеч шәһәр», «Шәрыкнең башкаласы» дип атаганнар.

Шәһәр яны бистәләрендә дә тормыш кайнап торган. Болак аръягын-




*Р.М. Вахитов. Улу-Мухаммед-хан. 2013*
*Р.М. Вахитов. Олуг Мөхәммәд хан. 2013*



*Махмуд-хан.*
*Реконструкция Т. Балуевой*
*Мәхмүд-хан.*
*Т. Балуева реконструкциясе*



*Мухаммад-Эмин-хан.*
*Реконструкция Т. Балуевой*
*Хан Мөхәммәд-Әмин.*
*Т. Балуева реконструкциясе*

да, хәзерге Мәскәү урамы буйлап, XV йөз урталарында ук Көрәеш бистәсе үсеп чыга. Бистәнең сокланырлык матур Өтәч мәчете (Отучева мечеть) хәтта рус елъязмаларында теркәлеп калган. Көрәешнең археологик эзләре, шул исәптән борынгы зират урыны, хәзерге Колхоз базары тирәсендә ачылды. Көрәеш бистәсеннән арырак, Иделгә таба, Хан болыны башланып киткән, анда җәен зур бәйрәмнәр оештырылган, ат чабышлары уздырылган.

Казансуның Иделгә кушылган урынында балта осталары һәм кораб төзүчеләр бистәсе – Бишбалта барлыкка килә. Шунда ук, Идел култыгында, сәүдә һәм хәрби суднолар тукталышы өчен уңайлы урын да табыла.

Шәһәрнең икенче ягында, Арча кыры белән Кабан күле арасында, Әрмән бистәсе урнашкан була. Өлкән яшьтәге кешеләр әйтүенчә, әле узган гасыр урталарында да Калинин урамы башланган җирдә борынгы зират урынын күрсәтеп торучы әрмән язмалары белән чуарланган кабер ташлары калкып торган.

Гомуми мәйданы чама белән 100 гектарга җиткән шәһәрдә һәм аның тирә-юнендәге бистәләрендә, безнең якынча исәпләүләр буенча, 15–20 мең чамасы кеше яшәгән. Кызганыч, археологик казулар вакытында һөнәрче остаханәләре бик сирәк очрый, әмма алар кулланган инструментлар һәм шул остаханәләрдә җитештерелгән әзер продукция – тимерчеләр ясаган хезмәт һәм сугыш кораллары, күптөрле көнкүреш кирәк-яраклары, бакырчылар ясаган комганнар һәм кувшиннар, ювелир осталары җитештергән алтын-көмеш бизәнү әйберләре, күнчеләр теккән аяк киемнәре, ук савытлары – археологик табылдыклар арасында сирәк түгел. Чүлмәкчеләр аеруча оста һөнәр ияләре саналган. Алар эшләгән югары сыйфатлы балчык савыт-саба һәм дә кош-хайван сурәтендәге уенчыклар матур формалары, үзенчәлекле бизәкләре белән



*Первые лица республики и представители духовенства, принявшие участие в церемонии*

*В центре: муфтий Татарстана Камиль хазрат Самигуллин, Президент Татарстана Рустам Минниханов, верховный муфтий России Талгат хазрат Таджуддин и Государственный советник Республики Татарстан Минтимер Шаймиев*

*Ханнар җәсәден күчереп күмү процессиясендә катнашкан җитәкчеләребез һәм рухани затлар: уртада – Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Президенты Р.Н. Миннеханов, Россиянең Югары мөфтие Тәлгат хәзрәт Таҗетдинов, Татарстан Дәүләт киңәшчесе М.Ш. Шәймиев*

аерылып торган. Хатын-кызлар өчен бизәнү әйберләре ясаганда, ювелирлар бакырга, алтын-көмешкә чокып рәсем төшерү, кыйммәтле ташлар кую, металл үрү кебек катлаулы ысуллар кулланганнар. Алтын-көмеш әйберләр хан сараена аруча күп кирәк булган. Замандашлары язганча, һәр яңа хан үзенә «*кыйммәтле таҗ, алтын-көмештән савыт-саба эшләткән, затлы кием-салым тектергән*». Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында сакланган уникаль «Казан бүреге» кешеләрдә бүген дә зур соклану уята. Аны XVI гасырның беренче яртысындагы татар ювелир сәнгатенең гүзәл үрнәге дип атарга мөмкин.

Һөнәрчеләр арасында төзелеш белән мәшгуль кешеләр аерым бер төркем тәшкил иткән. Алар «*патша пулатлары һәм биек манаралы мәчетләр салучы осталар*» гына түгел, ә төрле төстәге кирпечләр, матур бизәкле гипс плитәләр эшләүче осталар да булганнар. Таш кисүче осталарның байлар заказы буенча искиткеч матур итеп эшләнгән, матур каллиграфия белән гарәпчә текстлар язылган кабер ташлары безне әле дә хәйран калдыра.

Казан ханлыгы икътисадында сәүдә, бигрәк тә тышкы сәүдә зур роль уйнаган. Татар сәүдәгәрләре Мәскәү Русе, Кавказ һәм Урта Азия, хәтта Көнбатыш Европа илләре белән тыгыз элемтәдә торганнар. Иделнең Казанга якын Кунаклар (Гостиный) утравында ел саен даны еракларга таралган Казан ярминкәсе уздырылган. Шул заманның бер кешесе: «*Казанга бөтен Рус иленнән бай сәүдәгәрләр һәм ерактан бик күп чит ил кешеләре җыелып килә һәм кыйммәтле товарлар белән күпләп сату итә*», – дип язып калдырган. –*Сәүдәгәрләр Бохарадан, Шәмәхәдән һәм дә төрекләр, әрмәннәр иленнән, һәм дә башка илләрдән*» килеп йөргән. Чит ил сәяхәтчеләре дә рус елъязмачыларының сүзен раслый. «*Казан – сәүдә шәһәре*, – дип язган XV гасырда яшәгән Венеция сәүдәгәре Иосафато Барбаро. – *Аннан ифрат күп санда мех чыгарыла, алар Мәскәүгә, Польшага, Пруссиягә һәм Фландриягә китә*». XVI гасыр башында яшәгән Австрия дипломаты Сигизмунд Герберштейн Казанга *«Әстерхан, шулай ук Персия/Фарсы һәм Әрмәнстан базарларыннан сәүдәгәрләр»* килүе турында хәбәр итә. Югарыда китерелгән тарихи чыганаклар яктылыгында Казан ханлыгы Европа белән Азия халыклары арасындагы сәүдәдә әһәмиятле урын тоткан дип әйтә алабыз.

Ханлык чоры Казаны элгәреге Алтын Урда һәм Идел буе Болгары шәһәрләреннән зурлыгы ягыннан да, байлыгы ягыннан да күпкә калыша. Биредә Биләр, Болгардагы кебек монументаль архитектура корылмалары юк дияргә була (хуш, аларның бер өлеше соңгы төзелешләр вакытында юкка чыккан дип уйларга да нигез бар). Икътисад үсешен югары бәяләгән очракта да, әлеге күренеш Казан өчен генә хас дип уйларга нигез бар, чөнки Арча, Лаеш, Тәтеш һәм башка шәһәрләр бик кечкенә, шунлыктан алар һөнәрчелектә сизелерлек роль уйнамаганнар.



*Джаназа-намаз у мечети Кул-Шариф читают представители духовенства во главе с верховным муфтием России Талгатом хазратом Таджуддином*

*Кол Шәриф мәчете янында җеназа намазын Россиянең Югары мөфтие Тәлгат Таҗетдин җитәкчелегендәге мөселман руханилары вәкилләре укыйлар*

*Перенос останков в специально обустроенный мавзолей у подножия башни Сююмбике*

*Ханнар җәсәден Сөембикә манарасы янында махсус төзелгән төрбәгә күчереп күмү процессиясе*





*Церемония перезахоронения казанских ханов Махмуда и Мухаммед-Эмина, а также двух членов их семей, обнаруженных в результате археологических раскопок в 1977 году. Первый табут в числе представителей духовенства несут верховный муфтий России Талгат хазрат Таджуддин и муфтий Татарстана Камиль хазрат Самигуллин. 19 мая 2017 года*

*1977 елгы казу эшләре вакытында табылган Казан ханнары Мәхмүд һәм Мөхәммәд-Әминнең, аларның гаилә әгъзаларенең җәсәдләрен күчереп күмү церемониясе. Беренче табутны Россиянең Югары мөфтие Тәлгат хәзрәт Таҗетдин һәм Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин күтәреп баралар. 2017 елның 19 мае*

*За ходом церемонии наблюдают директор Музея-заповедника «Казанский Кремль» З.Р. Валеева и министр культуры Республики Татарстан А.М. Сибагатуллин.*

*Церемониядә катнашучылар арасында «Казан кремле» музей-тыюлыгы директоры З.Р. Вәлиева һәм Татарстан Мәдәният министры А.М. Сибагатуллин бар иде*





*Ханская мечеть.*
*Графическая реконструкция Н. Халитова и Н. Хазиахметова, художник Р. Газеев.*
*Источник: realnoevremya.ru*

*Хан мәчете. График реконструкция авторлары Н. Халит һәм Н. Хаҗиәхмәтов, рәссам Р. Газиев*



*Ханский мавзолей. Рисунок из рукописи «Казанский летописец».*
*Источник: realnoevremya.ru*

*Хан төрбәсе. «Казан елъязмачысы» кулъязмасыннан алынган рәсем.*
*Чыганак: realnoevremya.ru*



*Памятный камень, посвященный хану Мухаммад-Эмину на аллее Правителей в Музейном парке Болгара*

*Мөхәммәд-Әмин ханга багышланган истәлек ташы. Болгар. Музей паркының Идарәчеләр аллеясы*

*Ф. Халиков. Древняя Казань. 2002*

*Ф.Г. Халиков. Борынгы Казан. 2002*





*Казанская шапка в Оружейной палате Московского Кремля*

*Казан ханнарының таҗы – рус патшалары регалийларының иң күренеклеләреннән © Кораллар палатасы. Мәскәү кремле музее*



*Н.Т. Хазиахметов*
*Портрет Кул-Шарифа*

*Н.Т. Хаҗиәхмәтов*
*Кол Шәриф портреты*




***Ситуационный план раскопов II–III 1995–1997 годов, во время которых были найдены фрагменты фундамента мечети Кул-Шариф.***
*Хронологическая картограмма объектов: а – I слой XIX– XX веков; б – II слой второй половины XVI–XVIII веков; в – III слой второй половины XV – первой половины XVI веков (фундамент мечети Кул Шариф); г – IV слой второй половины XIII – первой половины XV веков; д – V слой XI – первой половины XIII веков; е – насыпь вала конца X – начала XI веков; ж – местонахождение клада (по Ф.Ш. Хузину и А.Г. Ситдикову).*

***1995–1999 елларда Кол Шәриф мәчете хәрабәләре табылган казылмаларның ситуацион планы. Объектның хронологик картограммасы:*** *а) I катлам (XX–XIX гасырлар); б) XVI гасырның икенче яртысында – XVIII гасырда тупланган II катлам; в) XV гасырның икенче яртысына – XVI гасырның беренче яртысына караган III катлам; г) XIII гасырның икенче яртысына – XV гасырның беренче яртысына караган IV катлам; д) XI – XIII гасырның беренче яртысында тупланган V катлам; е) X гасыр ахыры –XI гасыр башынна караган саклану ныгытмасы эзләре; ж) акча хәзинәләре табылган урын. (Ф.Ш. Хуҗин һәм А.Г. Ситдыйков буенча).*



*Мечеть-медресе Кул-Шариф
Реконструкция Н. Халитова.
Источник: realnoevremya.ru*

*Кол Шәриф мәчет-мәдрәсәсе
Н. Халит реконструкциясе
Чыганак: realnoevremya.ru*



*Мавзолей Казанских ханов. Место захоронения
Махмуд-хана (ум. 1465). Современный вид*

*Казан ханнары төрбәсе. Мәхмүд-хан күмелгән
урын (1465). 2000 нче еллар башы*

усыпальницы казанских ханов. В мавзолее лежали погребения ханов, три из которых принадлежали, предположительно, Улуг-Мухаммаду (ум. 1445), Махмуду (ум. 1464) и Мухаммад-Эмину (ум. 1518).

Перед Ханским двором, но уже за его пределами, располагалась большая площадь, где возвышалась Соборная мечеть города. По описаниям источников, она была очень красивая и имела восемь минаретов с полумесяцами. Еще чуть далее от Ханского двора и Соборной мечети располагалась еще одна мечеть, названная по имени главы мусульманского духовенства, выдающегося государственного деятели и поэта Кул Шарифа. Остатки исторической мечети Кул Шарифа, включавшей в себя и высшее учебное заведение – медресе, удалось выявить в виде нескольких почти примыкающих друг к другу каменных построек, расположенных в сквере перед Благовещенским собором. Зафиксирована часть кладки нижних рядов, а также архитектурные детали в виде фигурных камней, кирпичей, облицовочных плит, покрытых бирюзовой поливой, и пр.

*Р.Г. Загидуллин. В Казанском посаде. 2001*
*Р.Г. Заһидуллин. Казан бистәсендә. 2001 ел*





*Русские монеты из клада конца XV – начала XVI века из раскопок на территории Казанского кремля*

*Казан кремле территориясендә табылган рус акчалары хәзинәсе © Татарстан Милли музее. Казан*



*Бронзовый подсвечник XIV–XV веков из раскопок на территории Казанского кремля*

*Казан кремле территориясендә табылган бронза шәмдәл. XIV–XV гасырлар. © Татарстан Милли музее. Казан*



*Бронзовое зеркало XIV–XVI веков из раскопок на территории Казанского кремля*

*Казан кремле территориясендә табылган бронза көзге. XIV–XVI гасырлар. © Татарстан Милли музее. Казан*

Под фундаментом мечети были обнаружены два больших клада серебряных монет, зарытых в тревожные дни осени 1552 г. В большом кладе, спрятанном в берестяном туеске, насчитали 1449 монет, чеканенных в Москве, Пскове, Твери, Рязани, Можайске и некоторых других русских городах в период правления великих князей Ивана III (1462–1505) и его сына Василия III (1505–1533). Малый клад, спрятанный в кожаном кошеле, содержал 556 монет того же времени.

Остальную территорию Казанской крепости занимали усадьбы правящей знати, которые, как писали современники, «очень красивы и удивления достойны». За высокими стенами крепости начинался торгово-ремесленный посад, обнесённый укреплениями в виде глубоких рвов и земляных валов. За посадскими стенами жизнь текла в пригородных посёлках – слободах.

Уровень городской жизни Казани был довольно высок. Это создавало ей славу богатого и изобильного города. Величавая крепость на горе, Ханский двор с его роскошными зданиями, устремлённые в небо высокие минареты мечетей, красивые дома богатых горожан придавали городу облик восточного города. Недаром иностранцы называли Казань «дивным городом», «столицей Востока».

* * *

Что стало в эпоху ханства с Болгаром? После событий 1431 года, связанного с разорительным походом русского князя Фёдора Пёстрого, он практически перестал существовать как город. Однако окончательно не был брошен. С XV в. Болгар превращается в центр религиозного поклонения и паломничества к этим святым местам. Об этом свидетельствуют скупые находки из небольшого по мощности культурного слоя Болгара, накопленного в период ханства. В опустевшем городе осталась жить небольшая часть горожан, считающих своей святой обязанностью сохранение уцелевших от полного разрушения культовых сооружений – мечетей, мавзолеев-усыпальниц и кладбищ с надгробными камнями. Со времен Казанского ханства Болгар приобрел значение выдающегося культового и духовного центра, священного места поклонения древним постройкам, которые на долгие времена сохранились в болгаро-татарской устной народной традиции как памятники ислама и болгаро-татарской государственности. Кстати, охранялись также «святые места» Биляра и Балынгуза, судя по архивным документам, в которых сохранились сведения о людях небольшой деревни, занятых этим богоугодным делом.

Имеются исторические сведения, указывающие на захоронение некоторых казанских «ханов», скорее всего, представителей высшего духовенства и феодальной знати, в особо почитаемых мусульманами местах – в Болгаре и на горе Балынгуз близ Биляра.

* * *

Казанское ханство, став достойным преемником достижений Золотой Орды, продолжало дальше раз-

Казанда тормыш дәрәҗәсе шактый югары булган. Бу аңа бай һәм мул тормышлы дигән дан китергән. Тау өстендәге мәһабәт кирмән, Хан сараеның зиннәтле биналары, алъяк (фасад) диварлары төсле чынаяк плитәләр белән бизәлгән мәчетләрнең биек манаралары, байларының матур йортлары белән Казан атаклы Шәрык шәһәрләренә охшап торган. Чит ил кешеләре аны юкка гына «гаҗәеп шәһәр» («дивный город»), «Шәрык башкаласы» («столица Востока») дип атамаганнардыр инде.

* * *

Ханлык чорында безнең ***шәһри Болгар*** ни хәлдәрәк була соң? Рус кенәзе Фёдор Пёстрыйның 1431 нче елгы җимергеч явыннан соң ул шәһәр буларак яшәүдән туктый. Әмма аны тулысынча ташлап китмәгәннәр. XV гасырдан башлап, Болгар гыйбадәт кылу һәм әлеге изге урыннарга зиярәт кылу үзәгенә әйләнә. Болгарның ханлык чорында тупланган әллә ни калын булмаган культура катламыннан табылган әйберләр шул хакта сөйли. Ташландык шәһәрдәге мәчетләрне, төрбәләрне, кабер ташлары куелган зиратларны җимерелүдән саклап калуны изге бурыч дип санаучы шәһәр кешеләре була алар. Бу эш Казан ханлыгы чорында да туктамый. Чынлыкта, Болгар – татар авыз иҗатында сакланган Ислам һәм болгар-татар дәүләтчелеге һәйкәленә әверелеп, борынгы биналарга изге гыйбадәт кылу урыны буларак яши, мәшһүр дини һәм рухи үзәк ролен башкара. Сүз уңаеннан, борынгы актлар тупланган Россия дәүләт архивында Биләр белән Болын хуҗа тавындагы «изге урыннар»ны саклау кебек изге эш белән мәшгуль кечкенә татар авылы кешеләре турында мәгълүмат теркәлеп калган. Ул документ XVII гасырга карый. Мөселманнарның изге урыннарын саклап-чистартып тору гамәле татарларда шул заманнарда формалашкан, күрәсең.

Казанның кайбер «ханнарын», чынбарлыкта исә югары катлау руханиларын һәм зыялыларын мөселманнар аеруча хөрмәт иткән изге урыннарда – Болгарда һәм Биләр янындагы Болын хуҗа тавында күмүләре турында тарихи мәгълүматлар сакланган. Моның белән без шәһри Болгар да, Биләр дә, җимерелеп, яшәүдән туктауга карамастан, бүгенге көнгә кадәр халык игътибарыннан читтә калмаган дип әйтергә телибез.

### *Казан ханлыгында мәдәният*

Казан ханлыгы, Алтын Урда казанышларының лаеклы варисы булып, Идел буенда Ислам мәдәниятен дә үстерүне дәвам итә. Ул әле Болгар чорыннан ук халык аңында ныгып, Ислам диненең күп гасырлык традицияләренә нигезләнә.

Дәүләт тормышында Ислам дине ролен Ибраһим һәм Сәхип-Гәрәй ханнар исеменнән 1470 һәм 1523 нче елларда язылган, Аллаһ исеме белән башланып киткән һәм «әмирләргә, бөек сәетләргә һәм кадияләргә» мөрәҗәгать иткән хан ярлыклары ачык гәүдәләндерә. Сәетләр, Мөхәммәт пәйгамбәр нәселеннән буларак, бөтен ил масштабында дин башлыклары функцияләрен үтәгәннәр һәм халык арасында зур абруй казанган-



*Исследования Балынгузского кладбища Билярской археологической экспедицией Института археологии им. А.Х. Халикова АН РТ в 2019 году (по З.Г. Шакирову)*
*А.Х. Халиков исемендәге Археология институтының Биләр экспедициясе тарафыннан Балынгуз зиратында алып барылган казу эшләре. 2019 ел. (З.Г. Шакиров буенча)*

вивать и мусульманскую культуру в Поволжье. Она основывалась на многовековых традициях ислама, закрепившихся в сознании народа ещё с булгарских времён.

Роль ислама в жизни государства ярко иллюстрируют ханские ярлыки Ибрагима (1470-е гг.) и Сахиб-Гирея (1523 г.), которые начинались именем Аллаха и далее обращались «к эмирам, великим сеидам и кадиям». Сеиды, как потомки пророка Мухаммада, выполняли функции главы духовенства в масштабах всей страны и пользовались огромным авторитетом среди населения. Австрийский посол Сигизмунд Герберштейн, посетивший Московское государство в начале XVI в., говоря о казанском сеиде как высшем духовном лице, писал, что *«он пользуется у них таким уважением и почётом, что при его приближении даже цари выходят ему навстречу; стоя протягивают руку ему, сидящему на лошади, и, наклонив голову, прикасаются к ней; это представлено одним только царям, ибо князья касаются не руки его, а колен, знатные лица – ног, а простой народ прикасается рукою*

нар. 1517 нче һәм 1526 нчы елларда Мәскәү дәүләтенә килеп, озак кына яшәп киткән Австрия илчесе Сигизмунд Герберштейн, Казан сәете турында дәүләтнең иң югары рухани заты буларак сөйләгәндә, шаккатып, болай дип яза: *«Ул аларда шундый хөрмәт һәм ихтирам казанган ки, аңа якынайганда хәтта патшалары (ханнары) да аңа, атка атланып баручы сәеткә, атларыннан төшеп каршы чыгалар, аягүрә басып кулларын сузалар, башларын иеп, кул биреп исәнләшәләр; болай итеп исәнләшү патшаларга гына рөхсәт ителә; аларның кенәзләре (бәкләре) сәетнең кулына түгел, тезләренә генә кагылалар, башка аксөяк затлар аның аягына, ә гади халык исә киеменә яисә атына гына кагыла»*. Сәетләрнең абруен ханнар еш кына дипломатик максатларда кулланганнар. Ш. Мәрҗани мәгълүматларына караганда, *«рус кенәзләре Казан ханнарына үз илчеләре аша хатлар җибәргәндә, сәет Шәрифколга (Кол Шәрифкә) аерым хат һәм бүләкләр җибәрә торган булалар»*.

Казан ханлыгында традицион рәвештә Ислам тәгълиматлары таләп итә торган грамоталылык гади халык арасында да югары дәрәҗәгә ирешкән. Дини белемгә генә түгел, дөньяви мәгарифкә дә омтылышны дин әһелләре Аллаһка яраклы эш дип санаганнар. Хәтерегездә булса, без әле, монгол яуларына кадәр яшәгән болгарлар да балаларына мәктәп-мәдрәсәләрдә дөньяви предметлардан башлангыч белем биргәннәр, дигән идек. Бу традиция ханлык чорында да дәвам иткән. Югарыда телгә алынган австрияле дипломат Сигизмунд Герберштейн сүзләренә караганда, *«татарлар (Идел буенда яшәүче) башка халыкларга караганда белемлерәк»*. Һөнәрчеләр арасында грамоталылыкның таралган булуын Мөхәммәт Әмин ханның гаскәр башлыгы Күбәк баһадирга аталып ясалган җиз комганга гарәп хәрефләре белән уеп язылган шигырь юллары да раслый. Аның тоткасына шул комганны ясаган останың исеме дә язылган: «(Мөхәммәт) Әмин хан бакырчысы Насыйр».

Казан ханлыгы чорыннан дистәләрчә кабер ташлары сакланып калган. Аларның чокып язылган




***Сигизмунд Герберштейн. Гравюра 1517 года***

***Сигизмунд Герберштейн. 1517 елгы гравюра. Иллюстрация китаптан: Rerum Moscoviticarum Commentarii. 1549 (Записки о московитских делах. СПб., 1908)***



*Кувшин, изготовленный придворным мастером хана Мухаммад-Амина Насиром. Начало XVI века*

*Мөхәммәд-Әмин ханның Насыйр исемле сарай һөнәрчесе тарафыннан ясалган бакыр кувшин. XVI гасыр башы*
*© Татарстан Милли музее. Казан*



*Тарханный ярлык казанского хана Сахиб-Гирея 1523 года.*
*Документ был обнаружен в 1912 году татарским археографом С.Г. Вахидовым в деревне Мамалаево Мамадышского уезда (ныне Сабинский район РТ) у крестьянина Рахматуллы Ахмарова, который хранил его как лечебный талисман*

*Казан ханы Сәхиб-Гәрәйнең тарханлык ярлыгы. 1523 ел.*
*© Татарстан Милли музее. Казан.*
*Документ 1912 елда татар археографы С.Г. Вахидов тарафыннан Мамадыш өязенең (хәзер Татарстанның Саба районы) Мамалай авылында яшәүче Рәхмәтулла Әхмәтов исемле кешедән табып алына*



*Р.Г. Шамсутдинов. Поэт Мухаммадьяр*
*Р.Г. Шәмсетдинов. Мәхмүд Мөхәммәдьяр – XVI гасырның беренче яртысында иҗат иткән күренекле татар шагыйре*

матур, җыйнак һәм тирән мәгънәле җөмләләрендә ник бер хата булсын! Димәк, байларның каберләренә куела торган ташлар ясау белән шөгыльләнүче осталар, һичшиксез, укый-яза белгәннәр. Коръән сүрәләреннән башка, алар шул заман шигъриятен да яхшы үзләштергәннәр кебек: каберташларның ян-якларында еш кына уеп язылган шигырь юлларын очратырга мөмкин.

Атаклы дин әһеле һәм шагыйрь Кол Шәрифнең мәчет имамы гына түгел, ә шул мәчет каршындагы югары уку йортының – мәдрәсәнең мөдәррисе, сәләтле шәкертләрнең яраткан остазы булуын күпләр беләдер инде. Бу шәкертләр бит, мәдрәсәдә укуларын тәмамлагач, мәчет муллалары гына булып китмәгән. Нәкъ менә шулар арасыннан хан канцеляриясендә эшләүче белгечләр, дипломатлар, илчеләр сайлап алынган. Шәкертләрнең бер өлеше язучылар, шагыйрьләр, галимнәр булып өлгергән.

Дини мәктәпләрдә бай кульязма әдәбият тупланган китапханәләр булган, шунда ук китап күчерүчеләр һәм каллиграфлар эшләгән. Хан сараенда канцелярия эшләрен башкару чиновниклардан югары стиль белән хатлар яза белү осталыгын, тарих, тел, каллиграфия сәнгатен тирәнтен белүне таләп иткән. Аларны монда Урта Азия, Кырым, Якын Көнчыгыш шәһәрләреннән махсус чакыртылган профессионаллар өйрәткән. Дини һәм дөньяви фәннәргә караган китапларны сәүдә кәрваннары белән хәтта ерак Шәрык илләреннән кайтартканнар. 1552 нче елда Казан басып алынганнан соң, Явыз Иван тарафыннан Мәскәүгә озатылган Хан китапханәсендә генә дә меңнәрчә том китаплар булган, сирәк кульязмалар сакланган.

Казанда татар әдәбияты, бигрәк тә поэзия үсә. Ханлык чорында иҗат ителгән әдәби әсәрләрдән Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге») һәм «Нуры содур» («Күңел нурлары») исемле поэмалары, Өмми Камал, Кол Шәриф, Мөхәммәт Әмин, Гарифбәкнең аерым шигырьләре сакланып калган. Казанда болардан кала да искиткеч фикер ияләре, шагыйрьләр һәм язучылар яшәгән һәм иҗат иткән. Кызганыч, алар калды-

*только к платью его или к лошади»*. Авторитет сеидов часто использовали ханы в дипломатических целях. По сведениям Ш. Марджани, *«русские князья, отправляя письма казанским ханам через своих послов, лично для сеида Шарифкола [Кул Шарифа] прилагали отдельное письмо и подарки»*.

В Казанском ханстве традиционно на высоком уровне находилась грамотность всех слоев населения, требуемая предписаниями ислама. Стремление к знаниям, образованию, причём не только к религиозному, считалось богоугодным делом и поощрялось духовенством. По словам вышеупомянутого Сигизмунда Герберштейна, «эти татары образованнее других [народов края]». О распространении грамотности среди ремесленников свидетельствуют гравированные арабской вязью поэтические строфы и надпись на ручке кувшина – «медник Эмин-хана – Насыйр».

При духовных школах имелись библиотеки с богатой рукописной литературой, там же работали переписчики книг, каллиграфы. Делопроизводство, которое велось при ханском дворе, требовало от чиновников высокого стиля письма, познаний в области истории, языка, владения искусством каллиграфии. Этому учили профессионалы, специально приглашённые из городов Средней Азии, Крыма, Ближнего Востока.

Развивалась татарская литература, особенно поэзия. Из литературных произведений времён Казанского ханства сохранились знаменитые поэмы «Тухфаи мардан» («Дар мужей») и «Нуры содур» («Свет сердец») Мухаммадьяра, отдельные стихи Кул Шарифа, Мухаммад-Эмина, Гариф-бека. В Казани жили и творили другие замечательные мыслители, поэты и писатели. К сожалению, многое из их наследия оказалось безвозвратно утраченным.

Наиболее ярким продолжением наследия золотоордынских поэтов в Казанском ханстве стало творчество великого поэта Мухаммадьяра. Его поэзия проникнута глубокими нравственными нормами, духом справедливости и патриотизма. Как гуманист, Мухаммадьяр сочувствовал трудной доле простых людей, адресуя «доброе слово обездоленным», провозглашая равенство всех независимо от их имущественного положения. Он считал, что общество должно быть устроено на началах справедливости, которая «всех молитв важнее». В поэме «Нуры содур» говорилось и о таких добродетелях, как милосердие, щедрость, скромность, стыдливость, честность, правдивость, верность слову, великодушие. Эти добродетели являются непреходящими духовными ценностями.

рган мирас безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән.

Казан ханлыгында Алтын Урда шагыйрьләре мирасының иң якты дәвамы булып 1552 нче елда Явыз Иван Казанны камаган вакытта һәлак булган бөек шагыйрь Мөхәммәдьяр иҗаты тора. Үз ватанының тугрылыклы улы буларак, ул ил өстенә ябырылып килгән һәлакәтне авыр кичергән. Аның шигърияте тирән әхлакый нормалар, гаделлек һәм патриотизм рухы белән сугарылган. Гуманист буларак, Мөхәммәдьяр гади кешеләрнең хәлен, авыр язмышын күреп-сизеп торган, матди байлыгына карамастан, һәркемнең тигезлеген икърар иткән. Ул, җәмгыять гаделлеккә нигезләнергә тиеш, чөнки гаделлек «барлык догалардан да кыйммәтрәк» дип санаган. «Нуры содур» поэмасында шәфкатьлелек, юмартлык, тыйнаклык, оят, намуслылык, сүзгә тугрылык, киң күңеллелек кебе игелекләр турында да әйтелә. Бу игелекләр мәңгелек рухи кыйммәтләр булып саналалар.

Халкыбыз күңелендә Кол Шәриф үзенең илһамлы шигърияте, рухи биеклеккә өндәүче әсәрләре белән урын алган. Аның бүгенгә кадәр сакланып калган әсәрләре аз: безгә аның бары дүрт-биш шигыре, шул исәптән «Кыйссаи Хөбби Хуҗа» исемле зур күләмдәге поэмасы һәм дә «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» («Казан иленең җиңүе») дигән чәчмә әсәре генә билгеле.

Кол Шәрифне әдәбият белегечләре суфи шагыйрьләр рәтенә кертәләр. Кол Шәриф үзенең остазлары итеп XII гасырда Урта Азия якларында яшәп иҗат иткән бөек шәхес Әхмәт Ясәвине һәм аның шәкерте Сөләйман Бакырганины саный. Аларның әсәрләре Казан ханлыгы чорында безнең якларда да бик киң таралган була.

Шигырьләрендә Кол Шәриф Аллаһы Тәгаләгә дан җырлый, аны олыларга өнди, фани дөньяда намус белән, нәфескә бирелмичә яшәп, Аллаһ каршына гөнаһсыз булып барырга чакыра.

Халык арасында Алтын Урданың катлаулы һәм каршылыклы таркалу чоры турында сөйләүче «Идегәй» дастаны тарала башлый. Зыялылар арасында күп кенә төрек, азәрбайҗан, үзбәк, төрекмән шагыйрьләренең әсәрләре уңыш казана. Җәмгыятьнең мәгърифәтле вәкилләре гарәп һәм фарсы телендәге фәлсәфә һәм табигать фәннәре буенча язылган хезмәтләргә еш мөрәҗәгать итә.

Халык риваятьләр, хикәят, дастаннар уйлап чыгарган һәм аларны буыннан-буынга тапшыра торган. Халык авыз иҗатындагы «Алпамша», «Чура батыр», «Әхмәт турында хикәят», «Җик Мәргән» кебек әсәрләр беркемне дә битараф калдырмаган. Гасырлар үткәч, «Җик Мәргән» дастанының сюжеты күренекле татар композиторы Нәҗип Җиһановның Муса Җәлил либреттосына язылган «Алтынчәч» операсы нигезенә ятты.

# ГЛАВА 3

# БОЛГАР – СИМВОЛ ЕДИНСТВА МУСУЛЬМАН РОССИИ

## Мусульманская культура татар в Российском государстве

Годы противостояния Казанского ханства и Московской Руси завершились 2 октября 1552 г. падением Казани и включением ханских владений в состав Русского государства. Завоевание Казани предрешило судьбу ещё одного постзолотоордынского государства – Астраханского ханства, подчиненного Иван IV в 1556 г. В результате границы русских земель значительно расширились в южном направлении и дошли до Каспийского моря. Россия стала многонациональной и многоконфессиональной страной.

Сразу же после взятия Казани начались восстановительные работы. Появилась новая крепость – белокаменный кремль. На месте поселений и городов ханского времени – в Арске (Арча), Лаишево (Лаеш), Тетюшах (Тэтеш) и других – возникли новые крепости, которые заселялись русскими служилыми людьми.

В это время Болгар в запустении, но считать его полностью оставленным было бы неправильно. Там находились здания мечетей и ханские усыпальницы, кладбища с надгробными камнями, к которым окрестное мусульманское население относилось с особым почтением – их сохраняли, приходили совершать молитвы не только по религиозным праздникам, но и в будничные дни, особенно летом. В глазах мусульман Поволжья Болгар начал превращаться в центр паломничества, а древние памятники приобретали характер «святых мест».

Есть сведения о том, что на развалины Соборной мечети и на могилы святых у Ханской усыпальницы приезжали даже из далёкой Средней Азии, где суфийский тарикат ханифитского мазхаба ислама был весьма популярным, как и у булгаро-татар Среднего Поволжья. Как писал поэт и религиозный деятель, последователь суфийского тариката Ахмеда Ясави, Мавля Колый, поселившийся в 1670-х гг. недалеко от Болгара и активно занимавшийся здесь религиозно-просветительской деятельностью, *«на этом самом месте приезжающие из разных мест мухаммедане*

# ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

# БОЛГАР – РОССИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ РУХИ ХӘТЕРЕ СИМВОЛЫ

## Россия дәүләте составындагы татар халкының мөселман мәдәнияте

Казан ханлыгы һәм Мәскәү Русе арасында озак еллар буена барган көрәш 1552 нче елның 2 октябрендә Казанны басып алу һәм хан биләмәләрен Рус дәүләтенә кушу белән тәмамланды. Казанның җимерелүе 1556 нчы елда бәйсезлеген югалткан Алтын Урда дәүләте – Әстерхан ханлыгының да язмышын хәл итә. Нәтиҗәдә, рус җирләренең чикләре көньяк юнәлештә шактый киңәя һәм Каспий диңгезенә кадәр килеп җитә. Россия күпмилләтле һәм күпдинле илгә әверелә.

Казан алынганнан соң ук, биредә торгызу һәм төзелеш эшләре башлана. Яңа ныгытма – ак ташлы кремль барлыкка килә. Хан заманындагы шәһәрләр һәм җирлекләр урынында – Арчада, Лаешта, Тәтештә һәм башка урыннарда Мәскәү дәүләтенең төрле өлкәләреннән күчеп утырган руслар яшәячәк яңа ныгытма-крепостьлар барлыкка килә. Казан ханлыгы җирләрен үзләштерү башлана. Дәүләтнең сәясәте, беренче чиратта, басып алынган җирләрдә хәрби көчләр урнаштыру, аннан соң шул хәрбиләрнең югары катлавына һәм православие дине әһелләренә җир бүлеп бирүдән гыйбарәт булган.

Бу вакытта Болгар ташландык хәлдә ята. Тик аны тулысынча калдырып китkәннәр дип санау дөрес булмас иде. Анда мәчетләрнең биналары һәм хан төрбәләре, кабер ташлары куелган зиратлар... Аларга тирә-юньдә яшәүче мөселман халкы аерым хөрмәт белән караган, үткән буыннар хәтерен саклаучы корылмаларны төзәтеп, тәртипкә китереп торырга тырышканнар, дини бәйрәмнәрдә генә түгел, елның теләсә кайсы фасылында, бигрәк тә җәй көннәрендә, ярымҗимерек Болгар мәчетенә килеп, изге урыннарны йөреп чыгып, намаз кылып, догалар укып киткәннәр. Идел буе мөселманнары күз алдында Болгар үзенчәлекле хаҗ кылу (дини яктан болай дип әйтү ярамаса да, чынлыкта шулай) үзәгенә әверелә башлады, ә борынгы һәйкәлләр «изге урыннар» төсен алды.

Җәмигъ мәчете җимерелгән урыннарга һәм изге Хан төрбәсе каберләренә хәтта ерак Азиядән дә

– *казанские татары, башкиры, бухарцы, хивинцы и др. – совершают своё моление»*; описывал проведение ремонтных работ почитаемых мавзолеев на пожертвования казанских купцов-мусульман.

Напомним, что в одной из версий о назначении «Чёрной палаты» она названа пристанищем для дервишей. Эта версия, кажется, недалека от действительности: отслужив свой срок в качестве судной палаты, позднее постройка вполне могла превратиться в обиталище паломников. Конечно, паломники наверняка знали и о легендарных сахабах Мухаммада, могилы которых, по их убеждению, находились в Болгаре у Малого минарета, где на месте легендарных захоронений были посажены три дерева: береза, сосна и липа, которые регулярно обновлялись мусульманами новыми саженцами. Присутствие почитаемых захоронений служило немаловажным стимулом для посещения достопримечательностей святого Болгара.

Обеспокоенный неожиданным наплывом паломников, в 1712 г. Казанский и Свияжский митрополит Тихон обратился к губернатору Апраксину с предложением построить монастырь на месте «Болгарского мусульманского городища, которое весьма преславно и прекрасно», где нет ничего, кроме «древних каменных зданий». Таким образом, митрополит хотел положить конец посещению мусульман «святых мест» Болгара,

Губернатор одобрил план и поручил дьяку Андрею Михайлову составить опись мест, которые должны были остаться под монастырём. Отчёт Михайлова содержит описание 70 древних зданий и сооружений, в числе которых «четыре палаты круглых», «всходный столп, которого ещё и ныне в вышину одиннадцать сажен», «возле тех четырёх палат пятая круглая, в которой ныне назначена Никольская церковь», «ещё палата четырёхугольная, в которой есть каменья кладбищныя с татарской надписью», «всходный столп




***Российское государство в середине и второй половине XVI века***

***Россия дәүләте XVI гасырның икенче яртысында***



*Угрюмов Г. И. Взятие Казани Иваном Грозным в 1552 году*
*Угрюмов Г. И. 1552 елда Казанның алыну*



*Штурм Казани. Миниатюра из Лицевого летописного свода. XVI век*

*Казанны штурмлау. Рәсемле рус елъязмасыннан миниатюра. XVI гасыр*

вышины семь сажен, у того столпа две мечети четвероугольные», «палата четверугольная без своду, та была наперёд сего церковью, потому что около ея много есть кладбищные каменья с подписьми, а подписи походили на армянские письмена».

Император Пётр I, посетивший Болгар в 1722 году по пути следования на Персидский поход, увидев, что «у старинного болгарского строения башни (или колокольня) фундамент испортился и оный подлежит подделать вновь», велел казанскому губернатору прислать *«человек двенадцать или пятнадцать с их инструментами и несколько бочек извести <…> и чинить их». Император велел также собрать валяющиеся на земле надмогильные камни «с арапскими письменами»* и списать тексты эпитафий с их переводами для Кунсткамеры в Санкт-Петербурге.

Распоряжения были выполнены: каменные надгробия заняли место в Северном мавзолее, верхняя часть Большого минарета Соборной мечети была окована железными обручами и покрыта дощатой крышей. Но вслед за этим, в 1732–1734 гг., буквально у развалин Соборной мечети была воздвигнута Успенская церковь с колокольней. В кладке его фундамента использовали строительные камни из развалин



*Старая Татарская слобода на карте Казани 1850 года*

*1850 елгы Казан картасында Иске Татар бистәсе*




*Вид города Лаишева*
*Лаеш шәһәре күренеше*

бару юлында бераз вакыт табып, император Петр I кереп чыга. Борынгы Болгар манарасының җимерек нигезен күреп һәм аны ремонтларга кирәклеген аңлап, Казан губернаторына бирегә *«үзләренең кораллары белән унике яки унбиш кеше һәм берничә мичкә известь җибәрергә* <...>




***Казанские татары в национальной одежде. Ил. из кн.: Георги И.И. Описание всех в Российском государстве обитающих народов. СПб., 1776. Ч. 1***

***Казан татарлары милли киемнәрдә. И.И. Георгиның «Описание всех в Российском государстве обитавших народов» (СПб., 1776. Ч. 1) китабыннан иллюстрация***




*Тетюши. Гравюра из книги А. Олеария «Описание путешествия в Московию и через Московию в Персию и обратно»*

*Тәтеш шәһәре. А. Олеарийның «Описание путешествия в Московию и через Московию в Персию и обратно... в 1633, 1636 и 1639, 1663» (СПб., 1906) китабыннан гравюра*




*Никольская церковь в здании Восточного мавзолея Ил. из «Альбома» А. Шмита. 1832*

*Көнчыгыш төрбә бинасында Никольский чиркәве. «Архитектурные чертежи развалин древних Болгар. Сняты с натуры в 1827 г. архитектором А. Шмитом» (СПб., 1832) китабыннан иллюстрация*



*Чёрная палата. Ил. из кн.: Рагозин В. Волга от Оки до Камы. Т. 3. СПб., 1890*

*Кара пулат. В. Рогозинның «Волга от Оки до Камы» (СПб., 1890. Т. 3) исемле китабыннан*




*Казанский кремль на карте 1750 года*
*1750 елгы картада Казан кремле*



*Реконструкция панорамы Казанского кремля второй половины XVI века (по С. Мамлеевой)*
*Казан кремле XVI гасырның икенче яртысында. Панорама. С. Мамлеева реконструкциясе*



*Успенский монастырь на плане села Болгары. Первая четверть XIX века. Российский государственный военно-исторический архив*

*Болгар авылы планында Успение монастыре. XIX гасырның беренче чиреге. © Россия дәүләт хәрби-тарих архивы*



*Ф.Х. Эрдман. Успенская церковь рядом с руинами Соборной мечети и Большим минаретом. Ил. из кн.: Die Ruinen Bulgars, 1820. Taf. II («Neue allgem. geographische Ephemeriden», Bd. VII)*

*Ф.Х. Эрдман. Җәмигъ мәчете һәм Олы манара янәшәсендә Успение чиркәве. «Die Ruinen Bulgars» (1820. Т. 2) китабыннан иллюстрация*



*Р.Г. Загидуллин. Странник. 2005*

*Р.Г. Заһидуллин. Мөсафир. 2005*



*План экономическому селу Болгары, что внутри земляного вала. Первая четверть XIX века. Российский государственный военно- исторический архив*

*Болгар шәһәрлегенең саклану нығытмалары эчендәге планы XIX гасырның беренче чиреге. © Россия дәүләт хәрби-тарих архивы*






*Портрет императора Петра Великого. Гравюра Меку по оригиналу Ж. Беннера. 1817. Копия. Подлинник: Московский государственный объединенный музей-заповедник*

*Император Петр Беренче портреты. Ж. Беннер оригиналы буенча Меку гравюрасы. 1817. Копия. Төп нөсхәсе Мәскәү дәүләт берләштерелгән музей-тыюлыгы фондларында саклана*

булгарских зданий и надгробия рядом расположенного мусульманского кладбища.

Постройка на территории городища монастыря и образование селения в пределах бывшего города усилили процесс разрушения древних памятников. Жители с. Успенского растаскивали камни старинных зданий на хозяйственные нужды, занимались кладоискательством. К 1760-м гг. на территории городища оставалось 44 древних сооружения из 70, зафиксированных в начале XVIII в. Исследователи и путешественники последующих времён отмечали лишь жалкие кучи камней там, где ещё недавно стояли здания.

Мусульманское население края не принимало эти «новшества». В этих условиях город Болгар с сохранившимися элементами мусульманской культуры в виде развалин минаретов, мавзолеев и кладбищ с надгробиями стал особенно остро восприниматься как место появления ислама на Волге, а потому богоугодное для выполнения особых проявлений почитания и религиозного паломничества.



*Успенская церковь. Современная фотография*

*Успение чиркәве. Бүгенге күренеше*



*Указ Петра I о сохранении Болгарских руин. Копия. Подлинник: Российский государственный архив древних актов. Ф. 9. Кабинет Петра I. Отд. II. Кн. 93. Л. 362*

*Петр I нең Болгар хәрабәләрен саклау турындагы фәрманы. Копия. Төп нөсхәсе Россия дәүләт борынгы актлар архивында саклана (ф. 9, Петр I кабинеты, II бүлек, 93 китап, 362 б.)*

*һәм әлеге корылманы төзәтергә боера»*. Император шулай ук җирдә аунап яткан кабер ташларын җыярга һәм андагы «арап язулы» текстларны тәрҗемә итеп, Санкт-Петербургтагы Кунсткамерага тапшырыга әмер биреп китә.

Боерыклар үтәлә: каберташлар Төньяк төрбәгә урнаштырылалар, Җәмигъ мәчете янындагы Олы манараның өске өлеше тимер кыршаулар белән ныгытыла, түбәсе калай белән каплана. Әмма озак та үтми, 1732–1734 нче елларда Җәмигъ мәчете харәбәләре янында гына Успение чиркәвен һәм аның чаң башнясы – колокольня төзеп куялар. Әлеге биналарның нигезен салуда Болгар биналарының җимерелгән урыннарыннан җыелган таш блоклар һәм мөселман зиратындагы каберләр өстеннән умырып алынган «арап язулы» ташлар кулланылган.

Борынгы шәһәр территориясендә монастырь салу һәм аның тирәсендә рус авылы барлыкка килү



*Намогильные камни в фундаменте Успенской церкви. Современная фотография*

*Успение чиркәве нигезендә болгарларның борынгы кабер ташлары*



***Первая соборная мечеть Уфы. 1830. Строил её на добровольные пожертвования купец первой гильдии Муктамин Тагиров (Хазмитев). В настоящее время – мечеть при Духовном управлении в Уфе, объект культурного наследия России регионального значения***

***Уфаның Беренче Җәмигъ мәчете. 1830. Аны беренче гильдия сәүдәгәре Моктәмин Таһиров (Халмитов) үз акчасына төзеткән. Бүгенге көндә – Уфа Диния нәзарәте каршындагы мәчет. Россиянең мәдәният мирасы объекты***

К этому времени относится призыв суфия муллы Мурада к возрождению Болгар в середине XVIII в. как места духовного обновления и возрождения ислама, выразившееся в проведении в 1769 году в Болгаре собрания своих сподвижников. Почитание этих мест мусульманами окончательно превратило его в сакральный центр, своеобразный символ прежней славы предков.

Этот факт отмечала в своих записках императрица Екатерина II, посетившая развалины Болгара в 1767 году: «*…татары же великое почтение имеют к сему месту и ездят богу молиться в сии развалины. Сему один гонитель, казанский архиерей Лука, позавидовал и много разломал, а из иных построил церковь, погреба и под монастырь занял, хотя Петра 1-го указ есть не вредить и не ломать сию древность*». Десять лет спустя, об этом посещении императрица писала и знаменитому французскому философу Вольтеру: *«Во время моего путешествия по Волге я оставила мою барку и высадилась, чтобы посетить развалины древнего города Болгар <…> Я нашла здесь семь или восемь каменных домов и столько же минаретов, весьма прочно устроенных. Я подошла к одной из этих развалин, вблизи которой стояло сорок татар, из которых некоторые были в молитвенном положении. Начальник губернии сказал мне, что место это считается татарами священным: они во множестве приходят сюда».*

* * *

Поворот в религиозной политике Российского государства начинается в период правления императрицы Екатерины II (1762–1796). Заметим, однако, что ещё императрица Елизавета Петровна (1741–1742) своим указом 1756 года разрешила татарам строить мечети после долгих лет запретов. При Екатерине II была упразднена Контора новокрещенских дел (учреждена в 1740 г.). В 1773 году Екатерина II издала указ о терпимости для мусульман.

Огромным событием в жизни российских мусульман стало открытие в 1789 г. в Уфе Духовного собрания магометанского закона – муфтията, которому предоставлялись обширные права решать религиозные вопросы среди мусульман России. Прави-



*Неизвестный художник. Портрет императрицы Елизаветы Петровны. 1740–1760-е годы. Ярославский художественный музей*

*Билгесез рәссам. Императрица Елизавета Петровна портреты. 1740–1760 еллар © Ярославль сынлы сәнгать музее*

да Болгарга сәяхәт кылучы галимнәр әле күптән түгел генә борынгы биналар торган урыннарда хәзер кызганыч таш-кирпеч өемнәре генә калганын билгеләп үткәннәр.

Төбәкнең мөселман халкыда әлеге «яңалыкларны» кабул итмәде. Шушы шартларда, җимертелгән архитектура һәйкәлләре, зиратлардагы каберташлар рәвешендә булса да борынгы мөселман цивилизациясе, югары үскән болгар мәдәнияте элементларын саклап кала алган Болгар шәһәре Ислам дине кабул ителгән, гыйбадәт һәм «кече хаҗ» кылу өчен Аллаһ үзе күрсәткән изге урын буларак кабул ителә башлый. Татарларның әлеге җиргә табынуы Болгарны үзенә ниндидер бер тылсымлы көч белән җәлеп итеп торучы сакраль үзәккә, ата-бабаларыбызның элеккеге даны символына әйләндереп куя.

борынгы һәйкәлләрне җимерү процессын көчәйтә. Успенское авылында яшәүчеләр борынгы биналарны сүтеп алынган ташларны хуҗалык ихтыяҗлары өчен файдаланалар, хәзинәләр эзләү белән шөгыльләнә башлыйлар. 1760 елларга шәһәр территориясендә XVIII гасыр башында теркәлгән 70 корылманың 44е генә сакланып кала. Аннан соңгы еллар-

Бу фактны 1767 елда Болгар харәбәләренә сәяхәт кылган патшабикә Екатерина II үзенең язмаларында билгеләп үтә: *«...татарлар бу харәбәләргә олы хөрмәт күрсәтәләр*




**Высочайшее повелѣніе ИМПЕРАТРИЦЫ ЕКАТЕРИНЫ II, объ учрежденіи Оренбургскаго Магометанскаго Духовнаго Собранія.**

Г. Генералъ-Поручикъ, Баронъ Игельстромъ, принявъ за благо представленіе Ваше, чтобъ муллы и прочіе духовные чины магометанскаго закона между народами, оный въ Имперіи НАШЕЙ исповѣдующими, опредѣлялись неинако, какъ по учиненіи имъ надлежащаго испытанія и съ утвержденія намѣстническаго правленія, повелѣваемъ Вамъ произвесть сіе въ дѣйство и вслѣдствіе того учредить въ Уфѣ Духовное Собраніе Магометанскаго закона, которое, имѣя въ вѣдомствѣ своемъ всѣхъ духовныхъ чиновъ того закона, въ разныхъ губерніяхъ пребывающихъ, исключая Таврической области, гдѣ особое есть Духовное Управленіе, въ случаѣ надобности опредѣлять ихъ куда либо вновь, сіи люди были предварительно испытываемы и неинако опредѣляемы, какъ когда признаны будутъ достойными, со стороны же НАШИХЪ генераловъ-губернаторовъ, правящихъ ту должность, въ отсутствіи же ихъ—губернаторовъ, наблюдать, дабы къ исправленію духовныхъ должностей магометанскаго закона употребляемы были люди въ вѣрности надежные и добраго поведенія. Въ Духовномъ Собраніи помянутомъ предсѣдательствовать первому ахуну Мухаметьзяну Гусеинову, коего МЫ Всемилостивѣйше жалуемъ Муфтіемъ съ производденіемъ ему жалованья по тысячи пятисотъ руб. на годъ и съ нимъ засѣдать двумъ или тремъ мулламъ изъ Казанскихъ татаръ, въ вѣрности къ НАМЪ и въ добропорядочномъ поведеніи ихъ испытаннымъ, съ жалованіемъ по сту по двадцати рублей на годъ. О чемъ представляемъ Вамъ снестись съ генералами-губернаторами и правящими ихъ должность тѣхъ губерній, въ коихъ народы магометанской вѣры обитаютъ, пребываемъ въ прочемъ Вамъ благосклонны.

На подлинномъ подписано собственною ЕЯ ИМПЕРАТОРСКАГО ВЕЛИЧЕСТВА рукою тако: „ЕКАТЕРИНА". Въ С.-Петербургѣ, Сентября 22-го дня 1788 года. Съ подлиннымъ свидѣтельствовалъ Генералъ-Поручикъ, Баронъ Игельстромъ.



*Неизвестный художник. Портрет императрицы Екатерины II (1729—1796). По оригиналу Ф.С. Рокотова 1763 года*

*Билгесез рәссам. Императрица Екатерина II (1729–1796) портреты. Ф.С. Рокотов оригиналы буенча. 1763*

*киттем < ... > > Мин монда җиде яки сигез таш бина һәм шул кадәр үк манаралар күрдем. Мин янында кырыклап татар басып торган харәбәләрнең берсенә килдем. Губерна башлыгы бу урынның татарлар өчен изге булып саналуын әйтте: алар монда бик күп киләләр».*

* * *

Россия дәүләтенең дини сәясәтендә борылыш императрица Екатерина II идарә иткән чорда (1762–1796) башлана. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: 1742 нче елда «Казан губернасында мәчетләр төзүгә юл куймау, губернаторларга һәм воеводаларга яңа чукындырылган кешеләрнең мөселман диненә кире кайтуын тикшерү турында»гы фәрманга кул куйган император Ели-

*Высочайшее повеление императрицы Екатерины II об учреждении Оренбуржского магометанского Духовного собрания 22 сентября 1788 года*

*Императрица Екатерина II нең Оренбург Диния нәзарәте оештыру турындагы бөек фәрманы. 1788 елның 22 сентябре*



*Казанский Кремль. С гравюры Э.П. Турнерелли. 1839. Литография из альбома «Виды Казани»*

*Казан кремле. Э.П. Турнерелли гравюрасы. 1839. «Казан күренешләре» альбомыннан литография. 1855*



*Мусульманские паломники у Малого минарета и Ханской усыпальницы. Фотография 1894 года. Копия. Фотоальбом «Волга от Истока до Каспия», 1903*

*Мөселман мөсафирлары Кече манара һәм Хан төрбәсе янында. 1894. П. Ивановның «Волга от истока до Каспия» исемле альбомыннан фотокопия. 1903 ел*



*Святой ключ в Билярске. Современный вид*

*Биләрдә Изге чишмә. Бүгенге күренеше*



*Башня Сююмбике. С гравюры Э.П. Турнерелли. 1839. Литография из альбома «Виды Казани»*

*Сөембикә манарасы. Э.П. Турнерелли гравюрасы. 1839. «Казан күренешләре» альбомыннан литография. 1855*



*Памятный знак на месте Хуҗалар тавы (Гора хозяина) в Билярске. Современный вид*

*Биләрнең Хуҗалар тавында истәлек билгесе. Бүгенге күренеше*



*Братья Габдельвали и Мухаммадгали Ахметовы. Шамаиль с изображением булгарских памятников. Литография, бумага. 1901 г. Национальный музей Республики Татарстан*

*Бертуган Габделвәли һәм Мөхәммәтгали Әхмәтовларның Болгар истәлекләрен сурәтләгән шамаиле. Литография, кәгазь. 1901. © Татарстан Милли музее*

тельство вынуждено было, особенно после недавних событий, связанных с Пугачёвским восстанием, заботиться о том, чтобы его подданные жили в «любви, тишине и согласии».

Размышления о месте Болгара и его мусульманском духе находили свое отражение в XIX – начале XX вв. в произведениях Хисамутдина бин Шарафуддина Муслими «Таварихи Болгария», Багаутдина Ваисова «Тарихи ходжагон» и других татарских богословов, которые в своих текстах идеализировали ушедшую эпоху. Образ Болгара как центра мусульманской культуры и его особого места в исламе в России находил отражение в фундаментальных научных трудах крупных татарских богословов и историков, лично посещавших Болгар и оставивших свои размышления о роли Болгара в формировании мусульманских традиций: Ш. Марджани, Р. Фахретдин, Х. Аталаси, Г. Губайдуллин и др.

Советская власть уравняла в правах, в том числе и религиозных, все народы страны: в условиях господствующей коммунистической идеологии, частью которой являлся атеизм, практически все религиозные учреждения – православные храмы, мечети и синагоги, учебные заведения – были закрыты.



*Паломницы-татарки в Болгарах. Фотография С.С. Айдарова. 1960–1970-е годы. Музей археологии Республики Татарстан Института археологии Академии наук Республики Татарстан, Казань*

*Болгарга сәяхәт кылучы татар хатын-кызлары. 1960–1970 нче еллар. С.С. Айдаров фотографиясе. © Татарстан Фәннәр академиясенең Археология институты каршындагы Археология музее. Казан*

бигрәк тә Пугачёв восстаниесе белән бәйле вакыйгалардан соң, Россия халыкларының «мәхәббәт, тынычлык һәм татулыкта» яшәве турында кайгыртырга мәҗбүр булган.

Чынбарлыкта исә мөселман халыкларын христианлаштыру сәясәте 1917 нче елның октябрь вакыйгаларына кадәр дәвам итә. Совет власте исә илебездәге бөтен халыкларны – мөселманнарны да, христианнарны да һ.б. барлык хокукларында, шул исәптән дини хокукларында да, бик үзенчәлекле рәвештә тигезли: бердәнбер коммунистик идеология һәм аның состав өлеше булган сугышчан атеизм хөкем сөргән шартларда барлык дини учреждениеләр – мәчетләр һәм чиркәүләр барысы да ябыла.

Әмма татар халкы Болгарын онытмый. Аңлашыла ки, «хаҗилар» агымы сизелерлек дәрәҗәдә кими. Тик әлеге катаклизмнар халыкта Аллаһы Тәгаләгә булган ышанычны юкка чыгара алмый. Авыр вакытларда, болганчык заманнарда халык күңел тынычлыгы эзли һәм аны Коръән сүрәләрендә һәм аятьләрендә таба. Мәчет-мәдрәсәләрдән мәхрүм ителгән халык яңадан үзенең тамырларына, беренче чиратта, әлбәттә, аның мокатдәс һәйкәлләре сакланган Болгарга, Изге чишмә янында тыныч

Однако Болгар не был забыт. Понятно, что поток «паломников» заметно поубавился. Но эти катаклизмы не могли искоренить у населения веру во Всевышнего, наоборот, души искали покой и находили его в сурах и аятах Корана. Лишённый мечетей и других религиозных заведений, народ тянулся вновь к своим истокам веры – конечно же, в Болгар с его священными руинами мечетей и усыпальниц, в Биляр, где можно было спокойно молиться у знаменитого Святого ключа, к башне Сююмбике в Казанском кремле.

Годы государственного атеизма и борьбы с религией, ее пережитками не прошли бесследно. К 1980-м годам количество людей, прибывающих на богомолье в Болгар заметно сократилось. Практически исчезла традиция посещения *Хуҗалар тавы* и «Святого ключа» в Билярске. В 1970–1980-е гг. у татар-мусульман Волго-Уралья все ещё сохранялись основные элементы традиции посещения мест погребения почитаемых религиозных деятелей для чтения Корана.

кына гыйбадәт кылырга мөмкин булган Биләр шәһәренә, Казан Кремлендәге Сөембикә манарасына тартыла.

Сугышчан атеизмның дин һәм аның «калдыклары» белән көрәш еллары эзсез узмады. 1980 нче елларга кадәр Болгарның изге урыннарына табынырга килүчеләрнең саны сизелерлек кими. Биләрдәге Хуҗалар тавына һәм Изге чишмәгә бару традициясе дә юкка чыгу дәрәҗәсендә иде. 1970-1980 елларда Идел-Урал татарларында дога кылыр өчен изге дин әһелләре каберләренә бару традициясенең төп элементлары бернәрсәгә дә карамастан сакланып кала.

## Изучение и сохранение историко-культурного наследия Болгара

Историко-культурный потенциал Болгара – сохранившиеся руины архитектурных памятников, заключающих в себе тайны тысячелетней истории татар – является важным ресурсом духовного и культурного возрождения Республики Татарстан, а также в воспитания терпимости к другим культурам, бережного отношения к наследию прошлого, особенно подрастающего поколения, обязанного знать и дальше развивать



*Мечеть и медресе «Тысячелетия принятия ислама» («Юбилейная», Закабанная мечеть). Построена в 1924–1926 годах на народные средства по проекту инженера-архитектора А.Е. Печникова, разработанному в 1914 году*

*«Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәчет-мәдрәсә. («Юбилей мәчете», Кабан арты мәчете). 1924–1926 елларда халыктан җыелган хәйрия акчасына инженер-архитектор А.Е. Печниковның 1914 елда эшләнгән проекты буеча төзелгән*

## Болгарның тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү һәм саклау

Болгарның тарихи-мәдәни потенциалы – татарларның меңьеллык тарих серләрен саклап калган борынгы архитектура һәйкәлләре – Татарстан Республикасының рухи һәм мәдәни үсешендә мөһим ресурс булып тора. Һәм ул толерантлык, яшь буынга үткән чорлардан калган мирасыбызга сак караш тәрбияләү һәм Россия халыкларының мәдәниятен



*Торжественная молитва в честь возрождения праздника «Изге Болгар җыены» у Соборной мечети Болгара. 1989*

*Болгарның Җәмигъ мәчете янында Изге Болгар җыенын яңадан торгызуга багышланган тантаналы гыйбәдәт кылу*



*Председатель Духовного управления мусульман Европейской части СССР и Сибири Талгат Таджуддин и муфтии республик и областей России на торжественной молитве в честь возрождения праздника «Изге Болгар җыены» у Соборной мечети Болгара. 1989*

*СССР мөселманнарының Европа өлеше һәм Себер Диния нәзарәте Рәисе Тәлгать Таҗетдин һәм Россия төбәкләреннән килгән мөфтиләр Болгарның Җәмигъ мәчете янында «Изге Болгар җыены»н яңадан торгызуга багышлап гыйбәдәт кылалар. 1989 ел*



*Талгат Таджуддин с участниками праздника. Болгар, 1989*

*Тәлгать Таҗетдин бәйрәм кунаклары арасында. Болгар. 1989*



*Первые лица Республики Татарстан и представители духовенства на открытии праздника «Изге Болгар җыены». В центре: первый Президент Республики Татарстан М.Ш. Шаймиев и действующий Президент Республики Татарстан Р.М. Минниханов. Болгар, 2017*

*Татарстан Республикасы җитәкчеләре һәм руханилар «Изге Болгар җыены»н ачу тантанасында. Уртада: Татарстан Республикасының Беренче Президенты М.Ш. Шәймиев һәм Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миннеханов. 2017*

ата-бабаларның традицияләре нигезендә алга таба үстерү максатларында актив кулланыла.

1989 нчы ел Болгар өчен дә, бөтен мөселман дөньясы өчен дә гадәти булмаган, юбилей елы булды – Россия мөселманнары Идел буе Болгарында Ислам динен кабул итүнең һиҗри календаре буенча 1100 еллыгын билгеләп үттеләр. Искәртеп узабыз, 1922 нче елда Татарстанда, әлбәттә, тыйнаграк масштабта, Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгын бәйрәм итү үткәрелде. Бу вакыйга Казанда «Ислам кабул итүнең меңьеллыгы» мәчете һәм мәдрәсәсе ачылу белән истәлекле булды, алар бүген дә уңышлы гына эшләп, үзләренең мөһим рухи һәм дини миссияләрен үтәп киләләр.

Шул ук елда беренче тапкыр «Изге Болгар җыены» яки «зиярат әс-салихин» («чишмә башына, асылыбызга кайту») бәйрәме үткәрелде. Бу чараның максаты – тарихыбызны барлау, милли мәдәниятебезгә игътибарны көчәйтү, аны саклап калу һәм торгызу, рухи байлыгыбызны өйрәнү, Ислам кыйммәтләренә нигезләнгән халыкның мәдәни-тарихи традицияләрен арттыру, бабаларыбызның дин чисталыгын саклап калу иде.

Бәйрәмнең инициаторы – СССРның һәм Себернең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе



*Председатель Духовного управления мусульман Европейской части СССР и Сибири Талгат Таджуддин на празднике «Изге Болгар җыены». Болгар, 2017*

*Россиянең Европа өлеше һәм Себер Диния нәзарәте Рәисе Тәлгать Таҗетдин «Изге Болгар җыены» бәйрәмендә. 2017 ел*



*Верховный муфтий РФ Талгат Таджуддин в рабочем кабинете. Источник: fotokto.ru*

*Россия Федерациясенең Югары мөфтие Тәлгать Таҗетдин эш кабинетында. Чыганак: fotokto.ru*



*На праздновании «Изге Болгар жыены-2015». Президент Республики Татарстан Р.Н. Минниханов, Государственный советник Республики Татарстан М.Ш. Шаймиев и муфтий Татарстана Камиль хазрат Самигуллин принимают волос Пророка Мухаммада, который до этого хранился в Уфе на протяжении 110 лет. Реликвия передана Верховным муфтием Российской Федерации Талгатом Таджутдином в дар мусульманам Татарстана для хранения в Белой мечети г. Болгара Миниатюрный минарет, с заключенным в нём волосом Пророка Мухаммада получен из рук внука пророка Мухаммада в 42-м поколении Абдурразака Абдурахмана Саади. 28 июня 2015 года*

*«Изге Болгар җыены – 2015» бәйрәмендә. Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миннеханов, Татарстан Дәүләт киңәшчесе М.Ш. Шәймиев, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мөхәммәд пәйгамбәребезнең моңа кадәр 110 ел буена Уфада сакланган чәчен кабул итеп алалар. Әлеге реликвияне Россия Федерациясенең Югары мөфтие Тәлгать Таҗетдин Татарстан мөселманнарына олы бүләк рәвешендә Болгарның Ак мәчетендә саклау өчен тапшырды. Мөхәммәд пәйгамбәрнең чәче урнаштырылган кечкенә манара рәвешле савыт Мөхәммәд пәйгамбәрнең 42 нче буынындагы оныгы Абдерразак Абдерахман Сәгъди кулыннан 2015 елның 28 июнендә кабул итеп алынды*



*Муфтий Татарстана Камиль хазрат Самигуллин на праздновании «Изге Болгар жыены» в 2019 году*

*Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Изге Болгар җыены»нда. 2019 ел*



*Слева направо: Президент Татарстана Рустам Минниханов, заместитель председателя правительства Российской Федерации Марат Хуснуллин, государственный советник Республики Татарстан Минтимер Шаймиев, глава Спасского района Республики Татарстан Фаргат Мухаметов*

*Сулдан уңга: Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов, Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе урынбасары Марат Хөснуллин, Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Спас районы башлыгы Фәргать Мөхәммәтов*



*Муфтий Татарстана Камиль хазрат Самигуллин и Верховный муфтий РФ Талгат Таджутдин во время молитвы на празднике «Изге Болгар жыены» в 2019 году*

*Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Россия Федерациясенең Югары мөфтие Тәлгать Таҗетдин «Изге Болгар җыены»нда намаз укыйлар. 2019 ел*




*Выступление участников «Фестиваля татарской молодёжи». Болгар, 1999*
*«Татар яшьләре фестивале»ндә чыгыш ясаучылар. Болгар, 1999*



*На торжественной молитве во время празднования «Изге Болгар жыены». 5 июня 2021 года*
*«Изге Болгар җыены» бәйрәмендә тантаналы намаз. 2021 елның 5 июне*

культуру народов России на основе традиций предков.

1989 г. оказался для Болгара, да и для всего мусульманского мира необычным, юбилейным – мусульмане России отмечали 1100-летие (по хиджре) принятия ислама булгарами. Напомним, что в 1922 г. в Татарстане было проведено, конечно, в скромных масштабах, празднование 1000-летия принятия ислама по современному летосчислению. Памятником этому событию стали мечеть и медресе «Тысячелетие принятия ислама» в Казани, которые и сегодня сохранились и несут свою важную миссию духовности и веры.

В 1989 г. впервые был проведён ***праздник «Изге Болгар җыены»*** («Сбор/собрание в Святом Болгаре») или «Зиярат ас-салихин» («Возвращение к истокам»), посвящённый 1100-летию (по хиджре) добровольного и официального принятия ислама Волжской Булгарией. Целью этого мероприятия объявлялись сохранение и возрождение национальной культуры, возвращение к духовным истокам, умножение культурно-исторических традиций народа, основанных на ценностях ислама, стремление сохранить чистоту религии предков.

Инициатором праздника был председатель Духовного управления мусульман Европейской части СССР и Сибири муфтий Талгат Таджуддин. В нём участвовали муфтии практически всех республик СССР, многочисленные зарубежные гости, журналисты. В программу праздника были включены праздничная молитва у древней Соборной мечети, конкурс чтецов Корана, праздничная проповедь муфтия у Малого минарета, чтение мунаджатов, концерт мастеров татарской эстрады с репертуаром, соответствующим духу религиозного праздника.



*Участник концертной программы «Фестиваля татарской молодёжи». Болгар, 1999*

*«Татар яшьләре фестивале»нең концерт программасында катнашучы. Болгар, 1999*



*Соревнования по татарской национальной борьбе на «Фестивале татарской молодёжи». Болгар, 1999*

*«Татар яшьләре фестивале»ндә милли көрәш ярышы*



*Конная группа для встречи гостей фестиваля. Болгар, 1999*

*Фестиваль кунакларын атлы егетләр төркеме каршы ала*

Это начинание было поддержано исполкомом Всемирного Конгресса татар и муфтиятом Татарстана. С 1989 г. праздник «Изге Болгар җыены» проводится ежегодно. На открытии праздника гостей и участников Джиена традиционно приветствует руководители Республики Татарстан и соседних регионов, духовные лица.

Само по себе почитание и посещение Болгар, как места, священного для потомков татар, не прекращалось никогда, но до 1989 г. не было массовым. Мать Верховного муфтия ЦДУМ РФ Талгата Таджуддина Рашида ханум вспоминала: *«В первый раз я была в Болгаре в 1966 году. Всего 12 человек приплыли на пароходе из Казани. Пристань называлась тогда «Куйбышев Татарский». День был по-летнему тёплый, солнечный. Сначала, как принято, читали специальную молитву в два рака'ата, которую всегда читают при входе в мечеть и при посещении святых мест. Читали Коран, потом Таубе-покаяние <…> После я ездила в Болгар с родственниками неоднократно. Когда бы ни приезжали, народ всегда был, но немного – старики, люди пожилого возраста, изредка – дети, молодёжь. Было ощущение, что память о предках, святых местах ислама в России едва теплится. И хотелось ходить из дома в дом, из деревни в деревню и говорить о долге памяти перед предками, перед единоверцами…».*

Да, сейчас совсем другое дело – Болгар ожил. На «Изге Болгар җыены» приезжают даже татары из Болгарии, Румынии, Венгрии, Финляндии, Турции, США, Германии, Австралии, Китая и странт СНГ. Волею судьбы они оказались далеко за пределамии России и сегодня имеют возможность посетить Родину своих предков.

В 1989 г., в связи с подъемом общественного самосознания и внимания к духовному и культурному наследию при поддержке правительства ТАССР создается ***Фонд «Булгар»*** – производственно-коммерческая организация в целях сохранения и восстановления исторических памятников города Болгара. Фонд существовал недолго, но оставил после себя яркий след: было произведено углубление фарватера Волги близ городища. В результате не только «Метеоры» и «Ракеты», как раньше, но и четырёхпалубные теплоходы получили возможность останавливаться на пристани Болгара. Помимо этого при содействии Фонда архитектурные памятники городища были соединены асфальтированной дорогой, открылись кафе и магазины, налажен выпуск сувенирной продукции, буклетов и путеводителей. Город Болгар вновь стал узнаваемым во всём мусульманском мире. К середине 1990-ых гг. фонд, к сожалению, прекратил свою активную работу.

Следует отметить особую роль молодёжи в проведении «Изге Болгар җыены». Начиная с 1990-х гг. ежегодно проводятся детский Сабантуй, различные конкурсы, театрализованные представления, посвящённые

Тәлгать Таҗетдин. Анда Россиянең барлык республика һәм өлкә мөфтиләре, күпсанлы чит ил кунаклары, журналистлар катнашты. Программга борынгы Җәмигъ мәчете янында бәйрәм догасы, Коръән уку бәйгесе, мөфтинең Кече манара янында бәйрәм вәгазе, мөнәҗәтләр уку, дини бәйрәм рухына туры килерлек репертуар белән татар эстрадасы осталары концерты кертелгән иде.

Бу башлангыч Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм Татарстан мөфтие тарафыннан хупланды. 1989 нчы елдан башлап «Изге Болгар җыены» бәйрәме ел саен үткәрелә. Бәйрәм ачылышында кунакларны һәм Җыенда катнашучыларны гадәттәгечә Татарстан һәм күрше өлкәләр җитәкчеләре, дин әһелләре сәламли.

Борынгы Болгарны олылау һәм аңа сәяхәт кылу беркайчан да туктамады, ләкин, инде әйтелгәнчә, 1989 нчы елга кадәр күпсанлы да булмады. Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте баш мөфтие Тәлгать Таҗетдиннең әнисе Рәшидә ханым: *«беренче тапкыр мин Болгарда 1966 нчы елда булдым. Казаннан пароходта барлыгы 12 кеше бардык. Пристань ул вакытта «Куйбышев Татарский» дип атала иде. Көн җылы, кояшлы булды. Башта, әлбәттә, ике рәкәгать махсус намаз укылды, аны һәрвакыт мәчеткә кергәндә һәм изге урыннарга килеп җиткәч укыйлар. Коръән укыдык, аннары тәүбә догасы* < ... > *Шуннан соң мин Болгарга үз туганнарым белән берничә тапкыр бардым. Кайчан гына килсәк тә, халык һәрвакыт була торган иде, ләкин күп түгел – өлкән яшьтәге кешеләр, сирәгрәк булса да, балалар, яшьләр. Бездә ата-бабалар, Ислам диненең изге урыннары турындагы хәтер-истәлек сүнәр-сүнмәс кенә, көчкә саклана торган хис туа иде. Һәм өйдән-өйгә, авылдан-авылга барып, ата-бабалар, диндәшләр алдында хәтер бурычы турында сөйлисе килә иде...»*.

Әйе, хәзер бөтенләй башка эш – Болгар җанланды. Изге Болгар җыенына хәтта Болгария, Румыния, Венгрия, Финляндия, Төркия, АКШ, Алмания, Австралия, Кытай һәм БДБ илләреннән дә татарлар килә. Язмыш кушуы буенча алар Россиядән читкә чыгып киткәннәр, бүген исә ата-бабалары Ватанына барып кайту мөмкинлеге бар.

Җәмгыятьнең үзаңы күтәрелү һәм рухи-мәдәни мираска игътибар арту сәбәпле, 1989 елда ТАССР хөкүмәте ярдәме белән «Болгар» фонды төзелә. «Болгар» фонды – 1989 нчы елда Болгар шәһәренең тарихи истәлекләрен саклау һәм торгызу максатларында төзелгән җитештерү-коммерция оешмасы – озак яшәмәде, әмма үзеннән соң якты эз калдырды: шәһәрлек янында Идел фарватеры тирәнәйтелде. Нәтиҗәдә, «Метеорлар» һәм «Ракеталар» гына түгел, ә дүрт палубалы теплоходлар да Болгар пристанендә тукталу мөмкинлеге алды. Моннан тыш, фонд ярдәмендә шәһәрнең архитектура һәйкәлләре асфальт юл белән тоташтырылды, кафе һәм кибетләр ачылды, сувенир продукциясе, буклетлар һәм юл күр-




*Эмблема Республиканского фонда возрождения памятников истории и культуры Республики Татарстан*

*Татарстан Республикасы Тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу фонды эмблемасы*

принятию булгарами ислама, другие массовые мероприятия под названием «Изге Болгар форумы» («Форум святого Болгара»), а с 1999 г. – «Фестиваль татарской молодёжи».

Болгар в наши дни – это уникальный город-музей, сакральное место для всех мусульман России и зарубежных стран. Место, которое обладает аурой, позволяющей чувствовать духовную связь с предками, которые жили и трудились на этой земле, строили города, защищали свою страну от внешних врагов. И умирали здесь, оставив после себя не только мастерски выполненные сооружения в камне, но и следующее поколение людей – хранители их великого наследия. Потому и стремятся многотысячные группы мусульман на «Изге Болгар-жыены» – благодарить за их деяния, склонить головы перед творениями их рук – прекрасными памятниками прошлого. Менялись эпохи, но сформировавшиеся в Болгаре парадигмы культуры и духовной жизни на многие века определили не только традиции, нормы морали в Поволжье и Приуралье, но и положили начало современному татарскому этносу, оказали влияние на другие народы ре-



*Судно для проведения работ по углублению фарватера*

*Фарватерны тирәнәйтү эшләрен башкаручы судно Татарстан Республикасы*



*И.В. Рафиков. Туристический причал в Болгаре. 1993*
*Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*
*И.В. Рәфыйков. Болгарда туристлар причалы. 1993*

сәткечләр чыгару җайга салынды. Болгар шәһәре яңадан бөтен мөселман дөньясында танылды. 1990 еллар уртасына фонд, кызганычка каршы, үзенең актив эшен туктата.

Изге Болгар җыенын уздыруда яшьләрнең аерым ролен билгеләп үтәргә кирәк. 1990 нчы еллардан башлап, ел саен балалар Сабантуе, төрле конкурс-бәйгеләр, Ислам динен кабул итүгә багышланган театральләштерелгән тамашалар, Изге Болгар форумнары, ә 1999 нчы елдан – Татар яшьләре фестивале үткәрелә.

Безнең көннәрдә Болгар – уникаль шәһәр-музей, Россия һәм чит илләр мөселманнары өчен сакраль урын. Бу җирдә яшәгән һәм эшләгән, шәһәр төзегән, илен тышкы дошманнардан саклаган бабаларыбыз белән рухи бәйләнешне тоярга ярдәм итәргә сәләтле аурага ия булган урын. Бабаларыбыз монда матур итеп төзелгән таш биналар гына торгызмаганнар, ә мирасыбызны саклаучы киләсе буынны да калдырып, мәңгелеккә киткәннәр. Шуңа күрә меңләгән мөселманнар Изге Болгар җыенына болгар бабаларына изге гамәлләре өчен рәхмәт әйтергә, искиткеч һәйкәлләрдә гәүдәләндерелгән иҗат эшләре алдында баш ияргә дип киләләр.



*Болгарский историко-археологический комплекс. Вид сверху*

*Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы. Югарыдан күренеше*





*Свияжский Богородице-Успенский мужской монастырь*
*Зөядә Богородица-Успение ирләр монастыре. Югарыдан күренеше*



гиона. На протяжении веков средневековый Болгар оказывал разнообразное воздействие на развитие многих сфер жизни Восточной Европы и в целом Евразии. В современных условиях он приобретает важную роль в качестве межрегионального культурного центра российских мусульман, становится уникальной площадкой международного сотрудничества и является единственным музеем-заповедником, представляющим историю ислама в Российской Федерации, мусульманской культуры как части евразийской цивилизации.

В 2010 г. по инициативе первого президента РТ М.Ш. Шаймиева был создан ***Фонд «Возрождение»*** – Республиканский фонд возрождения памятников истории и культуры РТ (Фонд «Возрождение») *«в целях организации содействия возрождению и развитию Болгарского историко-архитектурного музея-заповедника, Государственного историко-архитектурного и художественного музея «Остров-град Свияжск», иных памятников истории и культуры, расположенных на территории Республики Татарстан, сохранению и развитию исторических, культурных и духовных традиций многонационального народа Республики Татарстан, национально-культурной самобытности и традиций татар, а также с целью привлечения необходимых для этого финансовых ресурсов, учитывая предложения, поступившие от Кабинета Министров РТ, органов местного самоуправления, общественных объединений и граждан»*. За почти десять лет реализации программы удалось не только провести реставрационные работы исторических памятников и создать современную туристическую инфраструктуру, благоустроить территории поселений, но главное – во многом воссоздать духовные образы: веру, духовные традиции и культуру наших предков. Международным признанием результатов работы Фонда стало включение в 2014 году Болгарского историко-археологического комплекса в Список объектов Всемирного культурного наследия ЮНЕСКО.

Среди новых объектов, поддерживающих мусульманскую идентичность на территории Болгара, можно отметить Памятный знак принятия ислама, Белую мечеть, благоустроенный колодец Габдрахмана и, конечно же, Болгарскую исламскую академию.

Болгар стал ярким и уникальным выражением идей культурного взаимодействия и взаимовлияния, в результате реализации которых проявился самобытный и неповторимый характер культуры Волжской Болгарии и Золотой Орды. Это место обладает особой духовной аурой, являющейся нематериальным наследием высочайшего уровня. А для многомиллионного татарского народа Болгар олицетворяет духовное единство, древнюю политическую и религиозную столицу. Прекрасными символами сохранения преемственности многовековых духовных традиций Болгара являются возведенные здесь Белая мечеть и Памятный знак.

Чорлар үзгәрә барды, әмма Болгарда формалашкан мәдәни һәм рухи тормыш парадигмалары күп гасырларга Идел буе һәм Урал киңлекләрендә гореф-гадәтләрне, әхлак нормаларын гына билгеләмичә, хәзерге татар этносына нигез салып, төбәкнең башка халыкларына да йогынты ясый. Гасырлар дәвамында Болгар Көнчыгыш Европа һәм гомумән Евразия тормышының күп кенә тармаклары үсешенә төрле йогынты ясап килде. Ул Россия мөселманнары өчен төбәкара мәдәни үзәк буларак зур әһәмияткә ия була, халыкара хезмәттәшлекнең уникаль мәйданчыгына әверелә һәм Россия Федерациясендә, Ислам һәм Евразия цивилизациясенең бер өлеше буларак мөселман мәдәнияте тарихын чагылдыручы бердәнбер музей-тыюлык булып тора.

***«Яңарыш» фонды*** – Татарстан Республикасының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне яңадан торгызу Республика фонды («Яңарыш» фонды) 2010 елда Татарстанның Беренче Президенты М.Ш. Шәймиев инициативасы буенча Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгын, «Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музеен, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан башка тарихи һәм мәдәният һәйкәлләрен, Татарстан Республикасында яшәүче күпмилләтле халыкның тарихи, мәдәни һәм рухи традицияләрен, татарларның милли-мәдәни үзенчәлеген һәм традицияләрен саклау һәм үстерүгә ярдәм итү, шулай ук моның өчен кирәкле финанс ресурсларын җәлеп итү максатыннан барлыкка килде. Бу карарны кабул иткәндә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр дә искә алынды.

Ун ел эчендә тарихи һәйкәлләрне реставрацияләп, заманча инфраструктураны булдырып һәм җирлек территорияләрен төзекләндереп кенә калмыйча ата-бабаларыбызның рухи образларын, гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен торгызу буенча күп эш эшләнде. 2014 нче елда Болгар тарих-археология комплексын ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү Фонд тарафыннан башкарылган эш нәтиҗәләрен халыкара тану булды.

Болгар территориясендә мөселман тәңгәллеген күрсәтүче яңа объектлар арасында Ислам дине кабул итүнең Истәлек билгесен, Ак мәчетне, Габдрахман коесын һәм, әлбәттә инде, Болгар ислам академиясен билгеләп үтәргә кирәк.

Болгар – мәдәни багланышлар һәм үзара йогынты ясау идеяләренең якты һәм уникаль чагылышына әверелде, аларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә Идел буе Болгары һәм Алтын Урда мәдәниятенең үзенчәлекле һәм кабатланмас характеры барлыкка килде. Бу урын иң югары дәрәҗәдәге матди булмаган мирас булган үзенә бер төрле рухи аурага ия. Миллионлаган татар халкы өчен Болгар рухи бердәмлек һәм борынгы сәяси һәм дини башкала символы булып тора. Биредә төзелгән Ак мәчет һәм Истәлек билгесе – Болгарның гасырлар



*Генеральный директор ЮНЕСКО Ирина Георгиева Бокова и председатель попечительского совета Республиканского фонда «Возрождение», Государственный советник Республики Татарстан Минтимер Шарипович Шаймиев в  Болгаре.*
*20 августа 2014 года. Фотография М. Козловского*

*ЮНЕСКО Генераль директоры Ирина Георгиева Бокова, Республика «Яңарыш» фондының попечительләр советы рәисе Минтимер Шәрип улы Шәймиев Болгарда.*
*2014 елның 20 августы. М. Козловский фотографиясе*

буена дәвам иткән рухи традицияләр дәвамчанлыгын саклап калуның гаҗәеп символы буларак билгеләнә.

***Истәлек билгесе (Коръән музее)*** 922 нче елда Идел буе болгарлары тарафыннан Ислам динен кабул итү хөрмәтенә куелган. Ул әлеге урынның Идел болгарлары тарафыннан Ислам кабул ителү, вакыйгасының чынлыгын, рухын һәм хисен саклап калучы бердәнбер аутентик чыганак булуын раслый.

Болгар – күп гасырлар дәвамында, хәтта Россия тарихының татарларны көчләп чукындыру белән бәйле иң катлаулы чорында һәм Совет хакимияте тарафыннан атеистик идеология көчләп тагылган елларда да, табыну һәм зиярат кылу объекты булып тора. Бу фактор мөселман җәмәгатьчелегенең хаҗилар хәрәкәте үзәкләре вәкилләренең Болгарның Ислам дине белән бәйле изге урыннарын олылау мәсьәләсенә игътибар белән һәм җитди карауларын китереп чыгарды. XX–XXI гасыр чикләрендә массакүләм аңда уникаль күренеш – Исламның Төньяк төбәгендә мөсел-

*Генеральный директор ЮНЕСКО Ирина Георгиева Бокова и Президент Республики Татарстан Рустам Нургалиевич Минниханов на торжественном мероприятии, посвящённом внесению Болгарского историко-археологического комплекса в Список Всемирного наследия ЮНЕСКО, в Татарском академическом государственном театре оперы и балета им. Мусы Джалиля. Казань. 20 августа 2014 года. Фотография Рината Сафина*

*ЮНЕСКО Генераль директоры Ирина Георгиева Бокова һәм Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миннеханов М. Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театрында Болгар тарих-археология комплексын ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә керту вакыйгасына багышланган тантаналы чарада*




TANZANIA
(United Republic of)



*Делегация Республики Татарстан на заседании 38-й сессии Комитета Всемирного наследия ЮНЕСКО. Доха, Катар. 23 июня 2014 года*

*Татарстан Республикасы делегациясе ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы комитетының 38 нче сессиясе утырышында. Доха, Катар. 2014, 23 июнь*

*Члены делегации и эксперт ЮНЕСКО Мунир Бушенаки (второй слева) празднуют включение Болгара в Список Всемирного наследия ЮНЕСКО. Доха, Катар. 23 июня 2014 года*

*Делегация әгъзалары һәм ЮНЕСКО эксперты Мөнир Бушенаки (уңнан икенче) Болгарны ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү вакыйгасын шатланып каршы алдылар. 2014, 23 июнь*

*На экскурсии в Музее Болгарской цивилизации. Болгар. 20 августа 2014 года. Фото М. Козловского. Источник: prav.tatarstan.ru*

*Болгар цивилизациясе музеенда экскурсия. Болгар, 2014 елның 20 августы. М. Козловский фотографиясе. Чыганак: prav.tatarstan.ru*





*Мечеть Кул-Шариф в Казанском Кремле. 2016*
*Казан кремлендә Кол Шәриф мәчете. 2016 ел*



*Благовещенский собор в Казанском Кремле. 2016*

*Казан кремлендә Благовещение соборы. 2016 ел*



*Собор Казанской иконы Божией матери в Казани Построен в 1798–1808 годах по проекту зодчего И.Е. Старова; воссоздан в 2016–2021 годах Республиканским фондом возрождения памятников истории и культуры Республики Татарстан во исполнение Указа Президента Республики Татарстан № УП-1066 «О создании Болгарской исламской академии и воссоздании Собора Казанской иконы Божией Матери»*

*Казан Мәрьям Ана иконасы соборы 1798–1808 елларда архитектор И.Е. Старов проекты буенча төзелгән. 2016–2021 елларда Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне яңадан торгызу фонды тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының «Болгар Ислам академиясе һәм Казан Мәрьям Ана иконасы соборын төзү турында» УП-1066 санлы фәрманы нигезендә яңадан торгызыла*

***Памятный знак (музей Корана)*** в честь принятия ислама волжскими булгарами в 922 году стал воплощением общественной инициативы и идеи, в основу которой легло осознание того факта, что данное место является единственным аутентичным источником, свидетельствующим о выдающемся событии – принятии ислама волжскими булгарами, сохраняющим подлинность события, его дух и чувство.

Болгар в представлениях российских мусульман в течение многих столетий, даже в самые сложные периоды российской истории – в эпоху христианизации татар и годы советской власти, связанной с насаждением атеистической идеологии – являлся объектом поклонения и паломничества. Этим фактором обусловлено большое и постоянное внимание представителей мусульманского сообщества и центров паломнического движения к вопросу о возвеличивании исламских памятников Болгара. В массовом сознании к рубежу XX–XXI вв. был сформулирован общественный запрос об увековечении уникального явления – зарождения



*Памятный знак в день церемонии открытия 21 мая 2012 года*
*Истәлек билгесен тантаналы шартларда ачу. 2012 елның 21 мае*



*Памятный знак в период строительных работ*
*Болгарда Истәлек билгесе төзү эшләре вакытында*



*На церемонии открытия Памятного знака, посвященного официальному принятию ислама волжскими булгарами в 922 году. Болгар, 21 мая 2012 года*

*922 елда Идел Болгарында Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүгә багышланган Истәлек билгесен ачу тантанасы. Болгар, 2012 елның 21 мае*






*Р. Аббасов. Карта маршрута посольства аббасидского халифа Аль-Муктадира*

*Р. Аббасов. 921–922 елларда Габбасилар хәлифәсе әл-Мөкътәдир илчелеге хәрәкәт иткән юл картасы*

*Государственный советник Республики Татарстан Минтимер Шаймиев вручает руководству музея-заповедника в Болгаре сертификат Книги рекордов Гиннесса, свидетельствующий о том, что отныне здесь будет находиться самый большой в мире печатный Коран. 21 мая 2012 года*

*Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев Болгар дәүләт музей-тыюлыгы җитәкчелегенә биредә, Истәлек билгесе бинасында, Гиннесның рекордлар китабына кертелгән дөньядагы иң зур басма Коръән саклануы турында сертификат тапшыра*



*Музейно-выставочный комплекс «Памятный знак в честь принятия ислама волжскими булгарами в 922 году» Болгарский историко-архитектурный музей-заповедник*

*922 елда Идел Болгарында Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүгә багышланган музей-күргәзмә комплексы © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



*Президент Республики Татарстан Рустам Минниханов (в центре) среди участников празднования открытия Памятного знака. 21 мая 2012 года*
*Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов (уртада) Болгарда Истәлек билгесе ачу тантанасында катнашучылар арасында. 2012 елның 21 мае*

ман мәдәнияте барлыкка килүне мәңгеләштерү турында таләп формалаша.

Истәлек билгесе – борынгы Болгар архитектурасы рәвешенә туры китереп стильләштерелгән, титанит-тан ясалган түгәрәк гөмбәзле, сигез кырлы бина. Түбәсендә – мөселман ярымае.

Үзәк залда, махсус пьедесталда Италия осталары ясаган Коръән урнаштырылган (шуңа күрә бу бинаны Коръән музее дип атыйлар). Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы тарафыннан бу уникаль китап югары сәнгати дәрәҗәдә башкарылган мәдәни кыйммәт дип танылды. Ул рекордлы үлчәмнәргә ия: озынлыгы 2 метр, киңлеге 1,5 метр, авырлыгы 800 килограмм. Залда доломит, мрамор һәм металлдан эшләнгән Багдад хәлифәсе әл-Мөктәдирнең Болгарга илчелеге маршрутының күләмле картасы урнаштырылган.

Иң биек катта Татарстан рәссамнарының йөздән артык эшләреннән торган картиналар галереясы, күргәзмәләр һәм конференцияләр үткәрү өчен каралган музей-күргәзмә комплексы урнашкан. Комплекс экспозициясендә археологик табылдыклар, язма чыганакларның төп нөсхәләре һәм күчермәләре, нумизматика һәм зәркәнчелек әйберләре, шулай ук сынлы сәнгать үрнәкләре, шул исәптән Идел буе болгарларының

мусульманской культуры в самом северном регионе распространения ислама в виде Памятного знака – монументального сооружения как визуального воплощения этого события, исторической памяти, культурного достояния и традиций, духовных ценностей татарского народа.

Памятный знак представляет собой стилизованное под древнебулгарскую архитектуру восьмигранное здание с круглым куполом и полумесяцем на вершине. В центральном зале, на специальном пьедестале, размещён Коран, изготовленный итальянскими мастерами (поэтому иногда это здание называют музеем Корана). Эта уникальная книга в силу высокого уровня художественного исполнения признана Министерством культуры РФ культурной ценностью. Коран, помещённый в Памятном знаке, является самым большим в мире печатным изданием священного писания мусульман, что подтверждено сертификатом Книги рекордов Гиннесса. Он имеет рекордные размеры: длина – 2 м, ширина – 1,5 м, вес – 800 килограммов. В зале размещена выполненная из доломита, ракушечника, мрамора и металла объёмная карта маршрута посольства аббасидского халифа ал-Муктадира в Болгар.

На цокольном этаже расположились картинная галерея, насчитывающая более ста работ татарстанских живописцев, музейно-выставочный комплекс, предназначенный для проведения выставок и конференций. В экспозиции комплекса представлены археологические артефакты, подлинники и копии письменных источников, нумизматика и предметы ювелирного ремесла, а также образцы изобразительного искусства, в том числе мозаичное панно, повествующее о дне принятия волжскими булгарами ислама в качестве государственной религии и церемонии встречи булгарского хана Алмуша с делегацией багдадского халифа.

Автором эскиза панно является художник Фарит Валиуллин. Основным и самым важным историческим источником стала «Записка» о путешествии на Волгу Ахмеда Ибн-Фадлана. При создании эскиза было использовано наследие великого татарского художника Баки Урманче, которым булгарский период истории татар был глубоко изучен. На панно изображена узнаваемая панорама – живописный берег реки, где состоялась встреча Джа’фара ибн-Абдаллаха (Алмуш-хана) с посланниками халифа в присутствии представителей булгарских родов, различных народов, проживавших на булгарской земле. В центре – булгарский эльтебер с супругой и сам ибн Фадлан в момент прочтения послания халифа ал-Муктадира.

***Габдрахман коесы*** – колодец Габдрахмана, названный в честь одного из сахабов Пророка, проповедовавшего новую религию среди булгар, расположен на северо-восточной окраине городища, в устье Иерусалимского оврага. Он с давних времён почитается мусульманами, посещающими Болгар, как «живой свидетель»

дәүләт дине буларак Ислам динен кабул итү көне һәм Алмуш ханның Багдад хәлифәсенең делегациясе белән очрашуы турында сөйли торган мозаика панносы тәкъдим ителә.

Панноның эскиз авторы – рәссам Фәрит Вәлиуллин. Төп һәм иң мөһим тарихи чыганак булып, Әхмәт ибн Фадланның Иделгә сәяхәте турында «Язмалары» булды. Эскизны төзегәндә бөек татар рәссамы Бакый Урманче мирасы кулланылды, аның тарафыннан татар тарихының Болгар чоры тирән өйрәнелгән. Паннода танылган панорама – елганың матур яры һәм шул тирәдә болгар ханы Җәгъфәр ибн Абдаллаһның (Алмышның) хәлифә илчеләре белән Болгар җирендә яшәүче төрле халык вәкилләре катнашында очрашуы сурәтләнгән. Үзәктә – хәлифә әл-Мөктәдирнең хатын укучы Ибн Фадлан һәм хатыны белән Болгар ханы.

***Габдрахман коесы.*** Габдрахман – болгарлар арасында яңа дин тарату өчен килгән пәйгамбәр сәхәбәләренең берсе. Аның исемендәге кое шәһәрнең төньяк-көнчыгыш читендә, Иерусалим чокырының тамагында урнашкан. Ул элек-электән Болгарга килгән мөселманнар тарафыннан Ислам диненең ата-бабалары җиренә үтеп керүенең беренче адымнарының «тере шаһиты» буларак хөрмәтләнә. Кое суы изге, шифалы дип санала. Коеның урнашу урыны 1998–2002 нче елларда төзекләндерелгән.

***Туйбикә коесы*** – изге сулы икенче кое, Болгар шәһәрлегеннән көнбатышка таба 1,5 километр ераклыкта урнашкан. Мөхәммәт пәйгамбәр сәхәбәләре тылсымы белән дәвалау тапкан болгар ханы кызы хөрмәтенә аталган. Әлеге коены мөселманнар да, православие динендәгеләр дә изге дип атыйлар, бертигез хөрмәтлиләр. Бу урында, янәсе, 1229 нчы елда Аврамий дигән бер христианны үтергәннәр, ә ул соңыннан чиркәү тарафыннан изгеләштерелгән. Чынбарлыкта исә, рус елъязмачылары буенча, Аврамий Бөек шәһәрдә – Биләрдә үтерелә.

***Ак мәчет*** – хәзерге Болгарның горурлыгы һәм Татарстанның архитектура энҗесе – шәһәр читендә, аның көньяк капкасы тирәсендә урнашкан һәм әйләнә-тирә ландшафтка бик тә туры килеп тора. Ул ак италия мәрмәреннән салынган, төсе тынычлык һәм чисталыкны гәүдәләндерә. «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәре» республика программасы нигезендә һәм «Яңарыш» фонды финанс ярдәме белән төрле илләрнең һәм чорларның Ислам архитектурасы үзенчәлекләрен өйрәнеп кайткан Сергей Шәкүров проекты буенча төзелгән. Мәчет 2012 нче елның 10 июнендә, Идел болгарлары тарафыннан Ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгән көннәрдә ачылды. Тантаналы церемониядә Россия Федерациясенең 62 төбәгендәге мөселман җәмгыятьләренең 900дән артык вәкилләре катнашты.

Комплекс бөтендөнья Ислам архитектурасының иң яхшы әсәрләре үрнәге булып тора. Комплекс, мәчеттән тыш, мәдрәсә (шәкертләре өчен тулай торагы белән) һәм мөфти резиденци-




*Экскурсия в музейно-выставочном комплексе «Памятный знак в честь принятия ислама волжскими булгарами в 922 году»*

*922 елда Идел Болгарында Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүгә багышланган музей-күргәзмә комплексында экскурсия*

*В.В. Путин, Р.Н. Минниханов и М.Ш. Шаймиев осматривают Коран, музейно-выставочный комплекс «Памятный знак в честь принятия ислама волжскими булгарами в 922 году». 28 августа 2012 года*

*В.В. Путин, Р.Н. Миннеханов һәм М.Ш. Шәймиев 922 елда Идел Болгарында Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүгә багышланган музей-күргәзмә комплексында Коръәнне карыйлар. 2012 елның 28 августы*



*Самый большой в мире Коран. Музейно-выставочный комплекс «Памятный знак в честь принятия ислама волжскими булгарами в 922 году». Болгарский историко-архитектурный музей-заповедник. 20 августа 2014 года. Фото М. Козловского*





*Дөньядагы иң зур Коръән. 922 елда Идел Болгарында Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүгә багышланган музей-күргәзмә комплексы. 2014 елның 20 августы. Козловский фотографиясе. © Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



*Баки Идрисович Урманче (1897–1990), советский татарский живописец, скульптор, график, фотограф; народный художник РСФСР, народный художник ТАССР, заслуженный художник Казахской ССР; лауреат Республиканской премии имени Габдуллы Тукая (1967)*

*Бакый Идрис улы Урманче (1897–1990), татар совет рәссаме, скульптор, график, фотограф, РСФСРның һәм ТАССРның халык рәссаме, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. (1967)*

первых шагов проникновения ислама в землю их предков. Вода из колодца считается святой, целебной.

***Туйбике коесы*** – другой колодец со святой водой, расположен в 1,5 км к западу от Болгарского городища, назван в честь дочери булгарского хана, нашедшей исцеление благодаря волшебству сподвижников пророка Мухаммада.

Колодец одинаково почитается и мусульманами и православными. Существует предание, что на этом месте якобы был казнён в 1229 г. Авраамий Болгарский, объявленный позднее святым мучеником[11].

***Белая мечеть*** – гордость современного Болгара и архитектурная жемчужина Татарстана – расположена за пределами городища и гармонично вписана в окружающий ландшафт. Она выполнена из белого итальянского мрамора, цвет мечети олицетворяет мир и чистоту. Возводилась по проекту Сергея Шакурова, основательно изучавшего особенности исламской архитектуры разных стран и времён, в соответствии с республиканской программой «Культурное наследие Татарстана: древний город Болгар и остров-град Свияжск» и при финансовой поддержке Фонда «Возрождение». Открытие мечети произошло 10 июня 2012 г., в дни принятия ислама волжскими булгарами (по хиджре). В торжественных церемониях приняли участие более 900 представителей мусульманских общин из 62 регионов Российской Федерации.

Образ комплекса собирательный. Примером послужили лучшие произведения мировой исламской архитектуры, а композиция была обусловлена поставленной задачей и включила в себя, помимо мечети, и медресе (Исламский центр духовного управления мусульман РТ). Главное здание

[11] Русские летописи связывают убийство Авраамия с Великим городом на Черемшане, который бесспорно отождествляется с Билярским городищем.



*Б.И. Урманче. Приезд ибн Фадлана в Булгары. 1973*
*Болгарский государственный историко-архитектурныймузей-заповедник. Болгар*
*Б.Урманче. Ибн Фадланның Болгарга килүе. 1973*
*© Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*



*Паломники на колодце Габдрахмана*
*Мөсафирлар Габдрахман коесы янында*





*Авраамий Болгарский. Икона.*
*Усинский благочиннический округ*
*Воркутинской епархии.*
*Кафедральный собор*
*Воскресения Христова, Усинск.*

*Авраамий Болгарский*
*Воркута епархиясенең Усинск округы*
*иконасы Воскресение Христова*
*кафедраль соборы. Усинск*

*Колодец Авраамия Болгарского Вид со стороны входа*
*Авраамий Болгарский коесы. Керү ягыннан күренеш*



ясе (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Ислам үзәге) биналарын үз эченә ала. 300 кешегә исәпләнгән гыйбадәт залы булган төп бина симметрик композициянең үзәге булып тора. Мәчет үзе сигезьяклы, күпкатлы гөмбәз белән капланган һәм 10 метр биеклектә (эчтән) яктылык гөмбәзе белән тәмамланган. Гөмбәз нигезендәге тәрәзәләргә витражлар куелган. Гыйбадәт залында хатын-кызлар өчен антресоль бар.

Мәчеткә керү өсте очлаеп торган биек портал рәвешендә. Залның шул ук рәвештә ясалган тәрәзәләре витраж пыялалар белән бизәлгән. Төп бинаның ян-ягында 46,5 метр биеклектәге ике дүртьяруслы манара. Алар Гарәбстанның Мәдинә шәһәрендә мөселманнар хаҗ кыла торган Пәйгамбәр мәчете манаралары стилендә эшлән-

*Белая мечеть. 2013*
*Ак мәчет. 2013 ел*





*Сергей Шакуров – автор проекта Белой мечети в Болгаре*

*Сергей Шокуров – Болгардагы Ак мәчет проектының авторы*



*Белая мечеть. 2013*
*Ак мәчет. 2013 ел*



*Оформление купола центрального зала Белой мечети. 2014*



*Ак мәчетнең үзәк залындагы гөмбәз*

с молельным залом, рассчитанным на 300 человек, является центром симметричной композиции. Сама мечеть представляет собой двусветный восьмигранный объём, перекрытый многолопастным сводом и завершённый световым куполом диаметром и высотой (изнутри) 10 метров. Окна в основании купола заполнены витражами. В молельном зале имеется антресоль для женщин.

Вход в мечеть оформлен высоким порталом со стрельчатым проёмом, форму которого повторяют высокие стрельчатые окна зала, также украшенные витражами. Здание фланкировано двумя четырёхъярусными стройными минаретами высотой 46,5 м, выполненными в стиле минаретов Мечети Пророка, находящейся в месте паломничества всех мусульман – Медине. Стены мечети украшены традиционными декоративными элементами – тюльпанами, арабесками, мукарнасами и геометрическими узорами, создающими неповторимую атмосферу внутри здания. Символичность и таинственность двухуровневому молельному залу придаёт рассеянное освещение,



*Оформление одного из витражных окон*
*Витражлы тәрәзәләрнең берсе*



*Большая потолочная люстра молельного зала*
*Гыйбәдәт кылу залында түшәм люстрасы*



*Изречения из Корана, традиционные мусульманские орнаменты – в украшении стен молельного зала*
*Гыйбәдәт кылу залының диварларында традицион мөселман бизәкләре – Коръән аятьләре, хикмәтле сүзләр*



*Пятничный молебен в Белой мечети. 31 июня 2020 года*
*Ак мәчеттә җомга намазы. 2020 елның 30 июне*

а монохромная цветовая гамма стен и купола в сочетании с деревянными элементами подчёркивают красоту резного декора.

По сторонам мечети находятся двухэтажные корпуса резиденции муфтия и медресе с общежитием для шакирдов, Они связаны с мечетью арочной галереей по первому этажу. Центральный и угловые ризалиты боковых зданий объединены портиками в форме аркады на 88 колоннах. Входы оформлены порталами, идентичными главному порталу мечети. П-образный комплекс обрамляет площадь, предназначенная для праздничных молений, развёрнуты главными фасадами на мечеть.

Белая мечеть олицетворяет символ религиозного ренессанса на болгарской земле. Она станет центром притяжения паломников, как в свое время принимала в своих стенах верующих Соборная мечеть.

Создание храмового комплекса в Болгаре можно назвать эпохальным явлением исламского сообщества Татарстана и России. Впервые на святой, намоленной Болгарской земле возрождается цитадель исламского богослужения, образования и просвещения. Особенно важно, что это не только мечеть, но и медресе. Постоянное присутствие шакирдов (студентов) на этой благословенной территории отражает связь времён



*Один из минаретов Белой мечети. 2014*
*Ак мәчет манараларының берсе. 2014*

*Белая мечеть. Панорама*





*Ак мәчет. Панорама*

и поколений, являясь символом возрождённого мусульманского Болгара.

Белая мечеть и ряд других инфраструктурных объектов возведены за пределами памятника с целью разгрузки территории от массового притока паломников и туристов. До возведения Белой мечети и Памятного знака на территории городища наблюдался наплыв паломников, размещавшихся на археологических объектах и рядом для выполнения религиозных обрядов, связанных с ритуалом намаза, жертвоприношений и др. Отсутствие специально предусмотренных мест для массового исполнения религиозной обрядности разрушало целостность памятника и оказывало неблагоприятное воздействие на сохранность археологических объектов. Решение этой задачи было направлено на обеспечение выполнения требований целостности и подлинности объектов культурного наследия. В результате исполнения этих условий существенно уменьшилась нагрузка на объекты наследия. Функциональное зонирование усиливает сохранность и аутентичность городской средневековой планировки и культурных слоёв, а также обеспечивает поддержание подлинности, места, духа и чувств.

***Болгарская исламская академия.*** 21 мая 2016 года в День официального принятия ислама Волжской Булгарией в рамках празднования «Изге Болгар җыены» прошла торжественная закладка капсулы в основание Болгарской исламской академии. В капсулу запечатано послание потомкам на четырёх языках – татарском, русском, английском и арабском. Место расположения Академии согласовано с Центром Всемирного наследия ЮНЕСКО. С инициативой создания Болгарской исламской академии выступили крупнейшие централизованные мусульманские религиозные организации страны: Центральное духовное управление мусульман России, Духовное управление мусульман Российский Федерации, Духовное управление мусульман Республики Татарстан. Данная инициатива получила поддержку Президента Российской Федерации.

Болгар был местом притяжения именитых учёных и признанным центром классической ханафитской богословской школы, а также одним из признанных интеллектуальных центров своего времени наряду с Каиром, Стамбулом, Багдадом и Самаркандом. Болгарская исламская академия призвана сохранить единство мусульманской уммы, мир и согласие в стране, возродить богатое богословское наследие и духовные традиции предков.

Болгарская исламская академии, открывшаяся в 2017 году, представляет собой комплекс образовательных и жилых зданий. В процессе обучения используются учебные помещения «Ак мечети» и других объектов Болгарского музея-заповедника. Она осуществляет подготовку интеллектуальной элиты мусульманской уммы страны – магистров и докторов исламского богословия. Созданы возможности для получения

гән. Мәчет диварлары традицион декоратив элементлар – лалә чәчәкләре, арабесклар (катлаулы шәрык орнаменты), мукарнаслар (бал корты балавызына охшаш орнамент) һәм бина эчендә кабатланмас атмосфера тудыра торган геометрик бизәкләр белән бизәлгән.

Мөфти резиденциясенең ике катлы корпуслары һәм шәкертләр өчен тулай торак бинасы беренче катта аркалы галерея белән әйләндереп алынган. Ян биналарның үзәк һәм почмак ризалитлары 88 колонналы аркада рәвешендәге портиклар белән берләштерелгән. Керү урыннары мәчетнең төп порталына охшаш порталлар белән бизәлгән. П-шәкелле комплекс бәйрәм намазлары өчен билгеләнгән мәйданны колачлый.

Ак мәчет Болгар җирендә дини Ренессанс символын гәүдәләндерә. Ул, кайчандыр борынгы Җәмигъ мәчете кебек, дин тотучыларны үзенә тартып торучы үзәк булып әверелде.

***Болгар ислам академиясе.*** 2016 нчы елның 21 нче маенда, Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми кабул итү көнендә. «Изге Болгар җыены» кысаларында Болгар ислам академиясе нигезенә капсула салу тантанасы узды. Капсулада дүрт телдә – татар, рус, инглиз һәм гарәп телләрендә киләчәк буыннарга юллама язылган. Академиянең урнашу урыны ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы үзәге белән килештерелгән. Болгар ислам академиясен булдыру инициативасы белән илнең иң зур үзәкләштерелгән мөселман дини оешмалары: Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте, Россия Федерациясе мөселманнарының Диния нәзарәте, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте чыкты. Әлеге инициатива Россия Федерациясе Президенты тарафыннан да хупланды.

Болгар, Ислам дөньясының төньяк форпосты буларак, һәрвакыт танылган галимнәрне җәлеп итү урыны һәм классик хәнәфи дини мәктәбенең танылган үзәге, шулай ук Каһирә, Истамбул, Багдад һәм Сәмәрканд белән беррәттән, үз чорының танылган интеллектуаль үзәкләреннән берсе булды. Болгар ислам академиясе мөселман өммәтенең бердәмлеген, илдә тынычлыкны һәм татулыкны саклап калырга, ата-бабаларыбызның бай дини мирасын һәм рухи традицияләрен торгызырга тиеш.

Болгар ислам академиясе – белем бирү һәм торак биналар комплексы. Уку барышында «Ак мәчет» һәм Болгар музей-тыюлыгының башка биналары да кулланыла. Ул илебезнең мөселман өммәте интеллектуаль элитасын – Ислам дине магистрларын һәм докторларын әзерләүне гамәлгә ашыра. Өстәмә һөнәри белем алу өчен мөмкинлекләр тудырылган. Академиядә бер үк вакытта көндезге һәм читтән торып берничә меңгә кадәр кеше укый ала. Фәнни-педагогик процесста әйдәп баручы белгечләр һәм дин белгечләре катнаша. Танылган чит ил мөселман мәгариф үзәкләре белән тыгыз хезмәттәшлек оештырылган, чит илләрдә югары һөнәри белем бирү системасы эшчәнлеге тәҗрибәсе актив өйрәнелә, ике



*Болгарская исламская академия. Панорама*

*Болгар Ислам академиясе. Панорама*



*Торжественная церемония, посвящённая закладке памятной капсулы в основание будущей исламской академии в Болгаре. 21 мая 2016 года*



*Болгар Ислам академиясе нигезенә истәлек капсуласы куюга багышланган тантаналы церемония. 2016 елның 21 мае*



*В капсулу заложили слова потомкам на четырёх языках: татарском, русском, английском и арабском*

*Капсулага татар, рус, инглиз һәм гарәп телләрендә киләчәк буынга җиткереләчәк сүзләр язып урнаштырылган*




Болгар
ислам академиясе
21.05.2016
Болгарская
исламская академия






*Государственный советник Республики Татарстан, председатель Попечительского совета республиканского фонда «Возрождение» Минтимер Шаймиев знакомится с ходом строительства Болгарской исламской академии в Болгаре. 7 октября 2016 года*

*Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе, «Яңарыш» фондының попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев Болгар Ислам академиясенең төзелеш барышы белән таныша. 2016 елның 7 октябре*

*Закладка капсулы и камня по случаю начала строительства Болгарской исламской академии*

*Болгар Ислам академиясе бинасын төзи башлау уңаеннан аның нигез ташын салу һәм капсула урнаштыру күренеше*

*Верховный муфтий РФ Талгат Таджуддин, муфтий Татарстана Камиль хазрат Самигуллин, государственный советник РТ Минтимер Шаймиев, президент РТ Рустем Минниханов на закладке памятной капсулы и первого камня Болгарской исламской академии*

*Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе, «Яңарыш» фондының попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев Болгар Ислам  Россия Федерациясенең Югары мөфтие Тәлгать Таҗетдин, Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов Болгар Ислам академиясе нигезенә беренче ташны һәм истәлек капсуласын куялар. академиясенең төзелеш барышы белән таныша. 2016 елның 7 октябре. Академиянең конференц-залы төзелеш барышында*



*Председатель Духовного Управления мусульман РТ Камиль Самигуллин и ректор Болгарской исламской академии Даниял Абдрахманов знакомят Государственного советника РТ, Председателя Республиканского фонда «Возрождение» Минтимера Шаймиева, полномочного представителя Президента РФ в Приволжском федеральном округе Игоря Комарова, губернатора Ульяновской области Сергея Морозова, а также главного федерального инспектора по РТ Рената Тимерзянова с деятельностью Болгарской исламской академии. 3 октября 2019 года*

*Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Болгар Ислам академиясе ректоры Даниял Габдрахманов Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе, «Яңарыш» фондының попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиевны, Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаровны, Ульяновск өлкәсе губернаторы Сергей Морозовны һәм Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор Ринат Тимерҗановны Болгар Ислам академиясенең эшчәнлеге белән таныштыралар. 2019 елның 3 октябре*

дополнительного профессионального образования. В Академии одновременно могут обучаться очно и заочно до нескольких тысяч человек, в научно-педагогическом процессе задействованы ведущие специалисты и богословы.

Организовано тесное взаимодействие с крупными зарубежными мусульманскими образовательными центрами, активно изучается опыт функционирования системы высшего профессионального религиозного образования в зарубежных странах и прорабатывается возможность выдачи двойных дипломов и создания совместных образовательных программ обучения с высшими учебными заведениями Иордании, Египта, Марокко и Сирии. Продолжив традиции татарского богословского наследия, Болгарская исламская академия призвана стать ведущим мусульманским научно-образовательным и духовно-просветительским центром.



*Болгарская исламская академия. Конференц-зал*
*Болгар Ислам академиянең конференц-залы*

диплом бирү һәм Иордания, Мисыр, Марокко һәм Сүриянең югары уку йортлары белән уртак белем бирү программалары булдыру мөмкинлеге карала. Татар дини мирасы традицияләрен дәвам итеп, Болгар ислам академиясе әйдәп баручы мөселман фәнни-белем бирү һәм рухи-агарту үзәге булырга тиеш.

## Болгар в современной мусульманской культуре

Болгар в наши дни – это узнаваемый в России город-музей, где сконцентрировано уникальное собрание знаний и достижений, материализованных в средневековых каменных зданиях, рядовых жилищах, хозяйственно-производственных сооружениях и обнаруженных при их раскопке артефактах.

Остатки архитектурных сооружений (мечетей, мавзолеев, бань), наиболее значимые из которых были




*Карта-схема достопримечательностей Болгара*
*Болгарский государственный историко-архитектурный музей-заповедник*

*Болгарның истәлекле урыннары карта-схемасы*
*© Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы*

## Яңарыш: хәзерге Ислам мәдәниятендә Болгар

Болгар – бөтен дөньяга танылган шәһәр-музей. Анда борынгы чорлардан калган таш биналарда, гади торак йортларда, хуҗалык-җитештерү корылмаларында һәм казу вакытында табылган әйберләрдә гәүдәләнгән белемнәр һәм казанышларның уникаль җыелмасы тупланган.

Мәчет, төрбә, мунча кебек архитектура корылмаларының калдыклары (аеруча әһәмиятлеләре югарырак тасвирланган иде) ачык һавада саклана. Казу эшләре вакытында чыккан табылдыкларның күп өлеше әле күптән түгел генә илебезнең төрле музей фондларында (Дәүләт тарих музее, Мәскәү; Дәүләт Эрмитажы, Санкт-Петербург һ.б.) саклана бирде. Табылдыкларның бер өлеше генә Татарстан Республикасы Милли музее экспозицияләрендә күрергә мөмкин иде. Дөрес, Болгарның үзендә археология музее булдыру ниятеннән бер-



*Предметы с текстами благожелательного характера и эпитафиями в разделе экспозиции: Ислам в Золотой Орде*

*Болгар цивилизациясе музееның «Ислам һәм Алтын Урда» экспозициясендә хуҗасына хәерһаклык теләп язылган әйберләр һәм эпитафия истәлеге. © Болгар цивилизациясе музее*

*Музей Болгарской цивилизации. Панорама со стороны причала речных судов. 2014*

*Болгар цивилизациясе музее. Елга суднолары причалы ягыннан панорама. 2014 ел*





*Часть интерьера музейного зала, посвящённого городу Болгару*
*Болгар шәһәренә багышланган музей залының бер өлеше*
*© Болгар цивилизациясе музее*





*Экспозиционный блок, посвящённый истории Хазарского каганата, Первого Болгарского царства и ранних болгар на Волге*

*Хәзәр каһанлыгы, Беренче Болгар дәүләте һәм Урта Иделдәге элгәреге болгарлар тарихына багышланган экспозицион блок. © Болгар цивилизациясе музее*

ничә омтылыш булды. Күпләр Успение чиркәвендә оештырылган музей экспозицияләрен дә хәтерли, ләкин ул да Болгар коллекцияләренең барлык байлыгын күрсәтә алмады.

Һәм менә «Яңарыш» фонды эшчәнлегенең беренче елында ук, ягъни 2010 елда, ***Болгар цивилизациясе музееен*** булдыру турында карар кабул ителде.

Музей өчен Болгар шәһәрлегендә, Иделнең югары террасасы сөзәклегендә алты катлы яңа монументаль бина төзелде. Аның архитектурасы урта гасыр Болгар корылмаларының архитектурасы белән аваздаш. Бинаның төп өч күләме (төп корпус һәм ике башня-ротонда) Болгар, Сувар, Биләр шәһәрләрен символлаштыра.

2013 нче елның маенда Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы структурасына керүче Болгар цивилизациясе музее ачылды. Музейның төп экспозицияләре 2 мең квадрат метр мәйданда өченче һәм дүртенче катларда урнашкан

*Фрагмент экспозиционного комплекса «Открытие Болгара» на фоне декоративно-художественного панно «Культурный слой Болгарского городища»*

*«Болгарны ачу» дип аталган экспозицион комплексның бер өлеше «Болгар шәһәрлегенең культура катламы» декоратив-сәнгать панносы фонында*




*Экспозиционный объект «Стрела времени». Включает сведения об основных хронологических вехах становления цивилизации и культуры волжских булгар. Музей Болгарской цивилизации*




*«Вакыт угы» экспозицион объекты Идел болгарлары цивилизацион үсешенең төп хронологик этапларына аңлатма бирә*
*© Болгар цивилизациясе музее*



*Сад игр и размышлений*
*Уеннар һәм уйланулар бакчасы*



*Чаша фонтана, символизирующего хранилище памяти об ушедших деяниях и ярких исторических личностях, к которому со стороны ансамбля «Восхождение» подводит Аллея поэтов и учёных*

*Фонтан тәлинкәсе – үткән буыннар, күренекле тарихи шәхесләр истәлеген саклау символы. Бу урынга «Югарыга күтәрелү» ансамбле ягыннан Шагыйрьләр һәм галимнәр аллеясы алып килә*



*Часть Музейного парка – монументальный ансамбль «Восхождение. Становление тюрко-татарской письменности: к вершинам духовного совершенства»*

*Музей паркының бер өлеше. «Югарыга күтәрелү. Төрки-татар язмачылыгы формалашу: рухи камиллеккә юл» дип аталган монументаль ансамбль*




*Музейный парк Болгара – продолжение Музея Болгарской цивилизации под открытым небом. Карта-схема*

*Болгарның музей паркы – Болгар цивилизациясе музееның ачык һавадагы дәвамы*

кратко описаны выше, сохраняются под открытым небом. Огромное количество вещевых находок, собранных при раскопках, до недавнего времени хранились в фондах различных музеев и только часть из них, наиболее интересных, находила место в экспозициях Национального музея Республики Татарстан, Государственного исторического музея (Москва), Государственного Эрмитажа (Санкт-Петербург). Правда, было несколько попыток создать археологический музей в самом Болгаре. Многие помнят ещё казавшиеся в своё время великолепными экспозиции музея в Успенской церкви, но и он не смог демонстрировать посетителям всё богатство болгарских коллекций. И вот в первый же год деятельности Фонда «Возрождения», т. е. в 2010 г., было решено создать ***Музей болгарской цивилизации***, призванный представить как подлинные памятники истории и культуры болгаро-татарского населения Поволжья, так и научно-теоретические воззрения на место болгарского наследия в мировом культурном пространстве.

Для музея возведено новое монументальное шестиэтажное здание на откосе высокого участка верхнего плато Болгарского городища. Его архитектура перекликается с архитектурой сохранившихся построек средневекового Болгара. Три основных объёма здания (главный корпус и две башни-ротонды) символизируют три крупнейших города: Болгар, Сувар, Биляр.

В мае 2013 г. «Музей болгарской цивилизации», входящий в структуру Болгарского государственного историко-архитектурного музея-заповедника, был открыт. Основные экспозиции музея расположены на третьем и четвёртом этажах на площади около 2 тыс. кв. м и состоят из трёх основных частей: «Открытие древнего Болгара», «История болгарской цивилизации» и «Древний Болгар: жизнь города». В экспозициях представлены более 1600 подлинных предметов из фондов Болгарского заповедника, Музея археологии РТ, а также копии предметов из коллекций Иске-Казанского и Билярского музеев-заповедников, Государственного Эрмитажа, Государственного Исторического музея, Музеев Московского Кремля, Археолого-этнографического музея Чувашского государственного педагогического университета и многих других. В Музее можно увидеть макеты архитектурных памятников Болгара, скульптурные портреты жителей Болгара, реконструированных антропологами по черепам погребённых.

Огромный интерес у посетителей вызывают не только экспозиции, демонстрирующие подлинные предметы из раскопок Болгара и других булгарских городов, но и разделы, рассказывающие об истоках тюрко-татарской культуры, начиная с эпохи хунну/гуннов, Тюркских каганатов, Великой Булгарии Кубрата и Хазарского каганата. Подлинные сокровища представлены в разделах,

һәм өч төп өлештән тора: «Борынгы Болгарны ачу» «Болгар цивилизациясе тарихы» һәм «Борынгы Болгар: шәһәр тормышы». Экспозицияләрдә Болгар дәүләт тыюлыгы, Татарстан Республикасы археология музее фондларыннан 1600дән артык чын әйбер, шулай ук Иске Казан һәм Биләр дәүләт музей-тыюлыклары, Дәүләт Эрмитажы, Дәүләт тарих музее, Мәскәү Кремле музейлары, Чуваш дәүләт педагогика университетының археология-этнография музее һәм башка музейлар коллекцияләреннән алынган предметларның күчермәләре тәкъдим ителә. Болгар цивилизациясе музеенда Болгар архитектура һәйкәлләренең макетларын, Болгар халкының антропологлар тарафыннан реконструкцияләнгән скульптур портретларын күрергә мөмкин.

Борынгы Болгар һәм башка Болгар шәһәрләренең казылма әйберләрен күрсәтеп кенә калмыйча, хунн/гуннар, Төрки каһанлыклары, Бөек Болгар һәм Хазар каһанлыгы чорыннан башлап төрки-татар цивилизациясе тарихы турында сөйләүче бүлекләр дә килүчеләр арасында зур кызыксыну уята. Чын хәзинәләр Җучи олысының шәһәр мәдәниятенә һәм урта гасыр чорындагы татар дәүләтләренә багышланган бүлекләрдә тәкъдим ителә. Болгар цивилизациясе музееның берничә бүлеге Ислам диненең болгар мәдәниятендә тоткан ролен чагылдыра.

Биредә «Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкка озын юл» дип исемләнгән күргәзмәнең Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булганын да әйтеп китәргә кирәктер.

* * *

Болгарның рухи мирасы, Идел Болгарстаны һәм Алтын Урда башкаласының якты һәм бай тарихы татар сынлы, театр һәм музыка сәнгате, матур әдәбияты һәм шигърияте, гомумән, милли мәдәният үсешенә көчле этәргеч ясады. Болгар бүген дә, күп гасырлар дәвамында кебек үк, Россия мөселманнарының һәм бөтен дөньядагы татар диаспорасының төп зиярат кылу үзәкләренең берсе булып кала бирә. Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәверендә, Мәскәү патшалыгы, Россия империясе, Советлар Союзы чорында үзгәреп һәм трансформацияләнеп, болар барысы да татар халкының традицион мәдәниятендә сакланып калганнар, профессиональ иҗат өлкәсендә тикшерелгәннәр һәм яңадан өйрәнелгәннәр.

1990 еллар башында милли яңарыш барышында татарларның иҗтимагый аңында идеологик стереотиплардан арынып, тарихка, мәдәни мираска, халыкның гореф-гадәтләренә һәм рухи кыйммәтләренә ихтыяҗ арткан чорда, татар тарихчыларының, прозаикларының, шагыйрьләренең һәм рәссамнарының күп санлы әсәрләре иҗат ителде. Болгарның күпгасырлык тарихындагы фаҗигале вакыйгалар халык иҗаты әсәрләрендә – риваятьләрдә, легендаларда, тарихи җырларда һәм дастаннарда чагылыш тапты. Алар заманча милли мәдәниятнең яңа әдәби һәм музыкаль әсәрләрен булдыру өчен нигез булып торалар.




*Награждение лауреатов Государственной премии Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая за 2016 год. На фото слева направо: Д. Бугров, Р. Хайрутдинов, А. Ситдиков, И. Щетинин, Р. Шигабутдинов, Ф. Валиуллин, А. Леухин, художник-каллиграф Н. Исмагилов, поэт Г. Муратов. В центре - Президент Республики Татарстан Рустам Минниханов*

*Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатларын бүләкләү. Сулдан уңга: Д. Бугров, Р. Хәйретдинов, А. Ситдыйков, И. Щетинин, Р. Шиһабетдинов, Ф. Вәлиуллин, А. Леухин, рәссам-каллиграф Н. Исмәгыйлев, шагыйрь Г. Морат. Уртада – Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миннеханов*

посвящённых городской культуре Улуса Джучи и средневековым татарским государствам. Несколько разделов Музея отражают роль ислама в культуре Болгара. Следует отметить, что авторы художественно-пространственной инсталляции «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» получила Государственную премию Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая.

* * *

Духовное наследие Болгара, яркая и насыщенная история столицы Волжской Булгарии и Золотой Орды дали мощный толчок для развития татарского изобразительного, театрального и музыкального искусства, художественной литературы и поэзии, национальной культуры в целом. Мощным импульсом для появления многочисленных произведений татарских историков, прозаиков, поэтов и художников, деятелей музыкальной культуры стал период с начала 1990-х гг., когда в процессе подъема национального движения в общественном сознании татар проявился живой интерес к подлинной, свободной от идеологических стереотипов, истории, к культурному наследию, традициям и духовным ценностям народа. Важнейшие события, в том числе и трагические, в многовековой истории Болгара нашли отражение в произведениях устного народного творчества – в преданиях и легендах, исторических песнях и дастанах. Они и послужили основой для создания новых литературных и музыкальных



*Премьера балета «Золотая Орда».*
*Татарский театр оперы и балета им. Мусы Джалиля. 2013*
*«Алтын Урда» балеты премьерасы.*
*М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры. 2013*

Иң кызыклы үрнәкләр, яңа иҗади уңышлар арасында премьерасы Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры сәхнәсендә 2013 нче елда тамашачы хөкеменә тәкъдим ителгән, бөек цивилизациянең һәлак булу темасына багышланган «Алтын Урда» исемле балетны әйтеп үтәргә кирәк. Спектакльгә либреттоны Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, музыкасын талантлы композитор Резедә Ахиярова язган. Балетның нигезенә көчле мәхәббәт кичерешләре, бәхетле һәм бер үк вакытта фаҗигале мәхәббәттә кискен борылышлар, хакимлеккә ашкыну, мәкерле хыянәт, җиңү тантанасы һәм җиңелү ачысы һәм шул ук вакытта безнең көн өчен мөһим тарихи үткәннең гыйбрәтле дәресләре салынган.

Тамашачылар һәм музыка тәнкыйтьчеләре арасында зур кызыксыну уяткан 2013 нче елның тагын бер истәлекле вакыйгасы – балетмейстер Григорий Ковтунның яшь



*Резеда Ахиярова*
*Резидә Ахиярова*


*Эльмир Низамов*

произведений современной национальной культуры.

Духовное наследие Болгар, яркая и насыщенная история столицы Волжской Болгарии и Золотой Орды дали мощный толчок для развития татарского изобразительного, театрального и музыкального искусства, художественной литературы и поэзии, национальной культуры в целом. И сегодня Болгар, как и на протяжении многих веков, продолжает оставаться одним из главных центров паломничества мусульман России и татарской диаспоры всего мира. Трансформируясь и преображаясь в эпохи Золотой Орды и Казанского ханства, во времена Московского царства, Российской империи, Советского Союза, они были сохранены в традиционной культуре татарского народа, подвергнуты изучению и осмыслению в профессиональной творческой сфере.


*Григорий Ковтун*

Среди наиболее интересных образцов, новых творческих удач необходимо выделить премьеру на сцене Татарского академического театра оперы и балета имени Мусы Джалиля балета «Золотая Орда» – героической поэмы на тему гибели великой мировой цивилизации, представленную на суд зрителя в 2013 г. Либретто к спектаклю написал народный поэт Татарстана Ренат Харис, музыку – талантливый композитор Резеда Ахиярова. В основу балета легли столкновения сильных человеческих страстей: возвышенные и одновременно трагические любовные перипетии, неизбывная жажда власти и вероломное предательство, торжество победы и горечь поражения и вместе с тем важные для наших дней поучительные уроки исторического прошлого.

Другим замечательным событием 2013 г., вызвавшим живой интерес у зрителей и музыкальных критиков, стала постановка балетмейстером Григорием Ковтуном одноактной оперы «Чёрная палата» на музыку молодого композитора Эльмира Низамова. Либретто к спектаклю на легендарные сюжеты булгарской истории было также написано Ренатом Харисом. Опера специально была подготовлена для исполнения на территории Болгарского городища с декорациями, воссоздающими дворцы и мечети средневекового города.

Интерес Рената Хариса к историческому прошлому воплотился в многочисленных поэтических произведениях, в частности, поэме «Клятвенная чаша». В 2005 г. одна из масштабных работ поэта – либретто



*Сцена из оперы «Черная палата».*
*Татарский государственный театр драмы и комедии им. Карима Тинчурина. 2013*
*«Кара пулат» операсыннан күренеш. К. Тинчурин исемендәге*
*Татар дәүләт драма һәм комедия театры. 2013*

композитор Эльмир Низамов музыкасына «Кара пулат» операсын сәхнәләштерүе. Болгар тарихының легендар сюжетларына нигезләнгән спектакльгә либретто Ренат Харис тарафыннан язылган. Опера урта гасырдагы сарайларны һәм мәчетләрне декорацияләрдә куллану максаты белән Болгар шәһәре территориясендә кую өчен махсус әзерләнгән иде.



*Ренат Харис (Ренат Магсумович Харисов)*
*Ренат Харис (Ренат Мәгъсум улы Харисов)*

Ренат Харисның илебезнең тарихи үткәне белән кызыксынуы күп санлы шигъри әсәрләрдә, аерым алганда, «Ант касәсе» поэмасында чагылды. 2005 нче елда шагыйрьнең зур күләмле эшләренең берсе – «Кыйссаи Йосыф» балеты либреттосы әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Россия Федерациясенең Дәүләт бүләгенә лаек булды. Либреттоның нигезе итеп, Гүзәл Йосыф – танылган болгар шагыйре Кол Гали поэмасының төп герое турындагы легенда алынган. Спектакль кеше яшәешенең ма-



*Татарский государственный фольклорный ансамбль под руководством Заслуженного артиста Российской Федерации Айдара Файзрахманова*

*Россия Федерациясенең атказанган артисты Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор ансамбле*

балета «Сказание о Йусуфе», была удостоена Государственной премии Российской Федерации в области литературы и искусства. В основу либретто Ренат Харис положил столетиями пересказываемую на разных языках легенду об Иосифе Прекрасном, ставшим главным героем известной поэмы выдающегося булгарского поэта Кул Гали. Спектакль-притча о красоте и смысле человеческого бытия стал одним из самых успешных проектов Татарского академического театра оперы и балета имени Мусы Джалиля.



*Нурихан Фаттах*
*Нурихан Фәттах*

Образ Болгара фигурирует в десятках произведений современных татарских поэтов, в песенном репертуаре артистов эстрады, любящих снимать свои клипы на фоне Чёрной палаты и Малого минарета, стен Казанского кремля и мечети Кул Шарифа. Булгарская тематика нашла свое достойное место в репертуарах Татарского государственного фольклорного ансамбля под руководством Заслуженного арти-

турлыгы һәм мәгънәсе турында. Ул – Муса Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрының иң уңышлы проектларыннан берсе.

Болгар образы хәзерге татар шагыйрьләренең дистәләрчә әсәрендә, Кара пулат һәм Кече манара фонында үз клипларын төшерергә яратучы эстрада артистларының җыр репертуарында, Казан Кремле һәм Кол Шәриф мәчете диварларында сурәтләнгән. Россия Федерациясенең атказанган артисты Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор ансамбле, Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең җыр һәм бию ансамбле репертуарларында Болгар тематикасы лаеклы урын алды.

Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Флүс Латыйфи, Марат Әмирханов, Вахит Имамов һәм башка татар язучыларының урта гасыр болгар-татар тарихының, шәхесләренең сәнгати реконструкцияләрендә уңышлы чагылыш тапкан тарихи романнары халык тарафыннан киң танылды.

Рәссамнарның иҗатын аерым ассызыклап үтәсе килә. XIX гасырның беренче яртысыннан ук борынгы болгар-татар һәйкәлләре Россия һәм чит ил рәссамнарының игътибарын

*Сцена из балета «Сказание о Йусуфе»*
*«Йосыф кыйссасы» балетыннан күренеш*





*Мусагит Хабибуллин*
*Мөсәгыйть Хәбибуллин*

имеем в виду, в первую очередь, натурные рисунки с изображениями архитектурных памятников Болгара, выполненные в 1837 году англичанином Эдуардом Турнерелли, и литографии француза Андре Дюрана «Руины в Болгарах, вошедшие в его «Альбом путешествия живописного и археологического по России…», изданный в Париже в 1849 году.

Данное направление в живописи было продолжено в творчестве русских художников-пейзажистов – братьев Григория и Николая Чернецовых (1802–1865; 1805–1879), запечатлевших в рисунках Большой и Малый минареты, Восточный мавзолей, Белую и Чёрную палаты, а также нашего знаменитого земляка Ивана Шишкина (1832–1898), написавшего серию рисунков «Памятники архитектуры древних Булгар».

Долгое время художники молчали. Лишь в 1970-х гг. вновь возобновился интерес к далёкому прошлому татар, в том числе и к булгарским древностям. Великий Болгар появляется в акварелях Рашида Гусманова, Баки Урманче, чуть позднее – Канафи Нафикова, Рифката Вахитова. Среди них особо выделяется картина Б. Урманче «Приезд ибн Фадлана в Болгары» (1973), изображающая одно из важнейших событий в истории предков современных татар, вошедших благодаря исламу в мир мусульманской цивилизации.

В дальнейшем болгарская тематика в творчестве

ста Российской Федерации Айдара Файзрахманова, Государственного ансамбля песни и танца Татарской филармонии имени Габдуллы Тукая.

Получили народное признание исторические романы Нурихана Фаттаха, Мусагита Хабибуллина, Вахита Имамова, Марата Амирханова и других татарских писателей, создавших удачные опыты художественных реконструкций событий и личностей булгаро-татарского средневековья.

Особо хочется подчеркнуть творчество российских и зарубежных художников, которые ещё с первой половины XIX столетия сделали объектом своего внимания памятники булгаро-татарской старины. Мы



*Фиринат Халиков*

җәлеп иткән. Без беренче чиратта 1837 нче елда инглиз Эдуард Турнереллиның натурадан төшерелгән Болгар архитектурасы һәйкәлләрен, француз Андре Дюранның 1849 нчы елда Парижда нәшер ителгән «Россиянең рәсем сәнгате һәм археология буенча сәяхәт альбомы»на кергән литографияләрен күз алдында тотабыз.

Рәсем сәнгатендә әлеге юнәлеш рус пейзажчылары – бертуган Григорий һәм Николай Чернецовлар (1802–1865; 1805–1879) язган картиналарда дәвам итә. Ул картиналарда без Олы һәм Кече манара, Көнчыгыш мавзолей, Ак Һәм Кара пулатлар кебек архитектура һәйкәлләрен күрәбез. Атаклы якташыбыз Иван Шишкин (1832–1898) «Борынгы Болгар архитектурасы һәйкәлләре» дигән рәсемнәр сериясен язган.

Советлар хакимияте чорында бары тик 1970 нче еллардан башлап кына ерак тарихыбызга, шул исәптән болгар борынгылыкларына карата кызыксыну уяна. Бөек Болгар Рәшит Госманов, Бакый Урманче акварельләрендә, бераз соңрак Канәфи Нәфыйков,



*Марат Амирханов*
*Марат Әмирханов*

Рифкать Вахитов акварельләрендә гәүдәләнә. Алар арасында Бакый Урманченың «Ибн Фадланның Болгарга килүе» картинасы (1973) аерылып тора.

Алга таба рәссамнар иҗатында Болгар тематикасы киңәя бара, моңа К. Нәфыйковның «Болгар урамы» (1975), «Ага-Базар» (1976), «Чүлмәкче остаханәсендә» (1979), «Болгарда чуен коючылар» (1980) һ.б. картиналары дәлил. 1990 нчы елларда Рифкат Вахитов иҗатында Казан чоры башлана. Ул ерак бабаларыбызның тарихын үзенчә күрә һәм аңлый белә. Мисалы – «Болгар иле турында легенда» картинасы.

Күренекле татар рәссамы Фиринат Халиков иҗаты бүгенге Татарстанның сәнгать дөньясында үзенә бер аерым урын алып тора. Аның профессионал тарихчылар белән хезмәттәшлек нәтиҗәсендә туган күпсанлы картиналарын карап, тарихыбызның Идел буе Болгары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларын яхшылап өйрәнергә була.

Болгар-татар тарихының таныш сюжетларын һәм образларын без Равил Заһидуллин, Рушан Шәмсетдинов, Илгизәр Самакаев,



*Вахит Имамов*



*Андре Дюран*



*Эдуард Турнерелли*



*Иван Шишкин*

*Р.А. Гусманов. Северный мавзолей в Болгаре*
*Р.А. Госманов. Болгарда Төньяк төрбә*





*К.А. Нафиков. Жыен – Поднятие хана на трон*
*К.А. Нәфыйгов. Җыен – ханны тәхеткә утырту*



*Б.И. Урманче. Порт в Болгаре*
*Б.И. Урманче. Болгарда порт*



*Р.М. Вахитов. Приезд ибн Фадлана*
*Р.М. Вахитов. Ибн Фадланның Болгарга килүе*

художников расширяется, о чём свидетельствуют картины К. Нафикова «Улица в Болгарах» (1975), «Ага-Базар» (1976), «В мастерской гончара» (1979), «Чугунолитейщики в Болгарах» (1980) и др. В 1990-х гг. начинается казанский период творчества Р. Вахитова, предложившего свое видение прошлого своих предков в триптихе «Легенда о Болгарской земле» (1991).

Особое место в художественной жизни современного Татарстана занимает творчество Фирината Халикова, блестящего живописца, по многочисленным картинам которого, созданным в содружестве с профессиональными историками, можно изучать всю историю татар периода Волжской Булгарии, Золотой Орды и Казанского ханства.

Знакомые сюжеты и образы булгаро-татарской истории мы находим в полотнах художников Равиля Загидуллина, Рушана Шамсутдинова, Ильгизара Самакаева, Фарида Якупова, Фарида Валиуллина, Булата Гильванова, Рустема Хузина и др.

Средневековая тюрко-татарская культура, город Болгар и ислам – эта триада ещё долго будет вдохновлять творческое сообщество на создание новых произведений искусства и сохранение традиций народов России.



*Р.Ф. Хузин. Булгарский учёный в эпоху Золотой Орды. 2008*
*Р.Ф. Хуҗин. Алтын Урда чорында болгар галиме. 2008*

Фәридә Якупова, Фәридә Вәлиуллина, Булат Гыйльванов, Рөстәм Хуҗин һ.б. рәссамнар әсәрләрендә табабыз.

Татарларның урта гасыр дәүләтчелеге, Болгар шәһәре һәм Ислам дине – бу триада безнең сәнгать җәмәгатьчелеген киләчәгебез хакына яңа әсәрләр иҗат итүгә рухландырачак әле.



*Ф.Г. Халиков. Вид на Малый минарет и Ханскую усыпальницу в Болгаре. 2003*
*Ф.Г. Халиков. Болгарда Кече манара һәм Хан төрбәсе. 2003*



# ЗАКЛЮЧЕНИЕ

Болгар является выдающимся примером в мировой истории, в котором нашли отражение геополитические и исторические изменения в Евразии в X – начале XXI в., игравших важную роль в формировании государств, распространении ислама, сохранении обычаев и культурных традиций. На протяжении столетий Болгар оказывал влияние на развитие духовной культуры, технологий, монументального и декоративного искусства, градостроительства народов Поволжья. В событиях связанных с Болгаром, нашли свое выражение многие исторические процессы и их проявление стало неотъемлемой частью культурного наследия России. Его прошлое является свидетельством исторической преемственности культурного разнообразия, сложившегося в Поволжье и Приуралье в период существования Булгарского государства, Золотой Орды, Казанского ханства.

Великому Болгару, известному в средневековье как значимому городу на Волжском и Камском пути, выпала честь быть местом встречи Багдадского посольства и официального принятия ислама. С этого времени Волжская Булгария стала носителем традиций мусульманского мира. И сегодня Болгар с его уникальными памятниками – свидетельство существования высокоразвитой культуры ислама на Среднем Поволжье и Приуралье в X–XV вв.

Значение ислама в жизни предков современных татар в Булгарском государстве, Золотой Орде, Казанском



*Волос Пророка Мухаммада на хранении в Белой мечети Болгара*

*Болгардагы Ак мәчеттә Мөхәммәд пәйгамбәрнең чәче саклана*

# ЙОМГАК

Болгар – X–XXI гасыр башында Евразиядә дәүләтләрне формалаштыруда, Ислам дине таралуында, гореф-гадәтләрне һәм мәдәни традицияләрне саклауда мөһим роль уйнаган геосәяси һәм тарихи үзгәрешләрнең дөнья тарихында күренекле мисал, үрнәк булып тора. Болгар гасырлар дәвамында Идел буе халыкларының



рухи мәдәниятен, технологияләрен, монументаль һәм декоратив сәнгатен, шәһәр төзелешен үстерүгә йогынты ясады. Болгар белән бәйле вакыйгаларда күп кенә тарихи процесслар чагылды һәм аларның чагылышы Россиянең мәдәни мирасының аерылгысыз өлешенә әйләнде. Аның үткәне Идел буе һәм Урал җирләрендә Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында барлыкка килгән мәдәни төрлелекнең тарихи дәвамчанлыгына дәлил булып тора.

Урта гасырларда Идел һәм Чулман юлларында мөһим шәһәр буларак танылган Бөек Болгар Багдад илчелеген каршы алу һәм Ислам динен рәсми рәвештә кабул итү урыны буларак танылды. Шул вакыттан Идел буе Болгары мөселман дөньясы традицияләрен яшәтүче һәм дәвам итүче төбәк булып китә. Идел буе Болгары – мөселман дөньясының аерылгысыз бер өлеше! Уникаль архитектура һәйкәлләре булган Болгар бүген дә X–XV гасырларда Урта Идел буе һәм Урал төбәкләрендә югары үсеш алган Ислам мәдәниятенең күркәм бер мисалы булып тора.

Болгар дәүләтенең, Алтын Урданың, Казан ханлыгының болгар-татар халкы тормышында, соңыннан Россия дәүләте составында Ислам диненең роле бәяләп бетергесез. Ислам Идел-Урал төбәгенең һәм Себернең төрки телле халыкларының



*В.В. Путин и духовные главы основных конфессий России: православия, ислама и иудаизма*
*Россия Президенты В.В. Путин һәм Россиянең төп конфессияләре – православие, ислам һәм яһүд дине руханилары.*

ханстве и Российском государстве трудно переоценить. Ислам способствовал этнической консолидации тюркоязычных народов Волго-Уральского региона и Сибири и сложения многомилионного татарского народа. В сложнейших условиях ислам помог татарам сохраниться в качестве целостного этноса, преумножить богатства своей самобытной культуры, сформировать схожий менталитет и выработать национальный характер. Все это произошло потому, что исламские духовно-нравственные ценности, изложенные в Коране, стали частью самосознания и национальной психологии татар России.

В Болгаре сохранились уникальные памятники мусульманской культуры XIII–XIV веков, которые до сих пор являются объектом внимания и всё больше привлекают к себе многочисленных паломников и туристов России и зарубежья. В условиях, когда современная культура практически полностью потеряла свои национальные черты, вполне актуально и всё настойчивее звучат призывы обратиться в поисках утраченного к историческому наследию и традиционной духовности. Культурные традиции мусульманских народов нашей страны, сохраняющие память о прошлом – один из важнейших и неотъемлемых компонентов российской цивилизации. Осознание общей истории сегодня и в будущем является основой формирования общественного и культурного согласия между народами и национального единства.

этник берләшүенә һәм күп миллионлы татар халкын формалаштыруда мөһим урын тотты. Авыр һәм катлаулы шартларда Ислам дине ул безгә бербөтен халык буларак сакланып калырга, үзенчәлекле мәдәниятебезнең байлыгын арттырырга, менталитет һәм милли характер булдырырга ярдәм итте. Ислам диненең гасырлар барышында сыналган һәм изге Коръәндә күрсәтелгән рухи-әхлакый кыйммәтләре Россия татарларының үзаңына һәм милли психологиясенә әверелде.

Болгарда XIII–XIV гасырларга караган уникаль архитектура һәйкәлләре сакланган, алар бүгенге көнгә кадәр Россиядән һәм чит илләрдән күпсанлы зиярат итүчеләрне үзләренә җәлеп итәләр. Хәзерге заман мәдәнияте үз милли үзенчәлекләрен тулысынча диярлек югалткан шартларда тарихи мираска һәм асыл гореф-гадәтләребезгә мөрәҗәгать итәргә өндәүләр бик актуаль һәм таләпчәнрәк яңгырый башлады. Илебез мөселман халыкларының үткәннәрен хәтердә саклаучы мәдәни традицияләре Россия цивилизациясенең мөһим һәм аерылгысыз компонентларыннан берсе. Бүген һәм киләчәктә уртак тарихны аңлау халыклар арасында җәмгыяви һәм мәдәни гармония һәм милли бердәмлек формалашуның нигезе булып тора.



*Памятник Кул Гали. Музей Болгарской цивилизации.*

*Кол Галигә һәйкәл. © Болгар цивилизациясе музее*

*Скульптор Демченко В.А.*

## Использованная литература

**Айдаров С.С.** Национально-региональные основы архитектуры Татарстана / Сост. Г.Н. Айдарова-Волкова, И.В. Краснобаев. Казань: Изд-во КГАСУ, 2014. 309 с.

**Археология Волго-Уралья**: учебник. Т.1 / Институт археологии им. А.Х.Халикова АН РТ, Марийский государственный университет. – Казань: Изд-во АН РТ, 2025. 776с.

**Белавин А.М., Иванов В.А.** Восход золотого полумесяца над Восточной Европой (Начальные этапы утверждения ислама в Урало-Поволжье). Уфа: Изд-во Башкир. гос. пед. ун-та, 2011. 135 с.

**Болгарский историко-археологический комплекс**. т. 1. Болгар - объект всемирного наследия ЮНЕСКО. / Р.М. Валеев, А.Г. Ситдиков, Р.Р. Хайрутдинов Казань: ООО «Главдизайн», 2016. 400с.

**Болгарский историко-археологический комплекс**. т. 2. Управление объектами Всемирного культурного и природного наследия: Болгарский историко-археологический комплекс. Культурный ландшафт Болгарского историко-археологического комплекса (с приложениями) / Р.М.Валеев, А.Г.Ситдиков, Р.Р.Хайрутдинов, Б. Рудольф,С.Г.Персова, П.М.Шульгин.-Казань: ООО «Главдизайн», 2016. 508с.

**Великий Болгар** / Науч. ред. А.Г. Ситдиков. М.; Казань: Феория, 2013. 404 с.

**Город Болгар.** Монументальное строительство, архитектура, благоустройство / Отв. ред. Г.А. Фёдоров-Давыдов. М.: Наука, 2001. 365 с.

**Гилязов И.А.** Казанский край в составе Русского государства (2-я половина XVI—XVIII вв.) // Татарстан: из века в век. Казань: Заман Татарское кн. изд-во, 2013. С. 88-109.

**Давлетшин Г.М.** Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 431 с.

**Давлетшин М.Г.** Духовная культура Золотой Орды в отечественной историографии: (имперский и советский периоды) / История и культура Золотой Орды и татарских ханств, вып. 33. Казань, 2023. 270 с.

**Загидуллин И.К.** Татарское национальное движение в 1860-1905 гг. Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. 423 с.

**Измайлов И., Хамидуллин Б.** Ислам в Золотой Орде. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. 63 с.

**Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье**: история и современность. Очерки / Отв. ред. Р.М. Мухаметшин. Казань: Мастер Лайн, 2001. 452 с.

**Ислам.** Энциклопедический словарь / Ред. Г.В. Милославский, Ю.А. Петросян, М.Б. Пиотровский. М.: Наука, 1991. 315 с.

**Музей болгарской цивилизации**. Т. I. Древний Болгар: жизнь города / Авт. В.С. Баранов, Д.Г. Бугров, А.Г. Ситдиков. Казань: Главдизайн, 2016. 267 с.

**Музей болгарской цивилизации**. Т. II. История тюрко-болгарской цивилизации / Авт. В.С. Баранов, Д.Г. Бугров, А.Г. Ситдиков. Казань: Главдизайн, 2016. 254 с.

**Музей болгарской цивилизации**. Т. III. Открытие древнего Болгара / Авт. Х.М. Абдуллин, В.С. Баранов, Д.Г. Бугров, А.Г. Ситдиков. Казань: Главдизайн, 2016. 263 с.

**Махмутов М.И.** Мир ислама: прошлое и настоящее. Казань: Центр инновационных технологий, 2006. 616 с.

**Мухаметшин Д.Г.** Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Казань: Ин-т истории АН РТ, 2008. 132 с.

**Мухаметшин Р.Р.** Татары и ислам в XX веке (Ислам в общественной и политической жизни татар и Татарстана). Казань: «Фэн», 2003. 303 с.

**Очерки истории исламской цивилизации**. Т. 1 / Под общей ред. Ю.М. Кобищанова. М.: РОССПЭН, 2008. 936 с.

**Ситдиков А.Г.** Казанский Кремль: историко-археологическое исследование. Казань, 2006. 288 с.

**Ситдиков А.Г., Бугров Д.Г., Измайлов И.Л., Мухаметшин Д.Г**. Встреча в Болгаре. Экскурсия по залам Музея болгарской цивилизации. Казань: ООО «Мастер-Граф», 2014. 84 с.

**Хузин Ф.Ш.** Исследования по булгаро-татарской археологии. Казань: Фолиант, 2011. 468 с.

**Янин В.Л.** Денежно-весовые системы русского средневековья. Домонгольский период. М.: Изд-во Москов. ун-та, 1956. 207 с.





*Болгар в день празднования годовщины принятия ислама волжскими булгарами. 2000-е годы*
*Болгар Ислам динен кабул итүгә багышланган бәйрәм көнендә. 2000 нче еллар башы.*

*Научное издание*

**Айрат Ситдиков, Фаяз Хузин**

# ГОРОД БОЛГАР: МУСУЛЬМАНСКИЙ МИР НА ВОЛГЕ

**Айрат Ситдыйков, Фаяз Хуҗин**

# БОЛГАР ШӘҺӘРЕ: ИДЕЛ БУЕНДА МӨСЕЛМАН ДӨНЬЯСЫ

Оригинал-макет *Асылгараева Г.Ш.*
Содействие в подборе иллюстративного материала:
Х.М. Абдуллин, В.С. Баранов, Ф.В. Чумаков, Д.В. Петров

Использованы материалы:
© Национального музея Республики Татарстан
© Болгарского государственного историко-архитектурного музея-заповедника
© Билярского государственного историко-археологического и природного музея-заповедника
© Государственного музея изобразительных искусств Республики Татарстан
© Государственного историко-архитектурного и художественного музея-заповедника «Казанский кремль»
© Фото на задней стороне обложки из архива Болгарской исламской академии

Подписано в печать 28.07.2026 г.
Тираж 700 экз. Заказ № 28.7/3
Оригинал-макет подготовлен
в Институте археологии им. А.Х. Халикова АН РТ
420111 г. Казань, ул. Баумана, 20
Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111 г. Казань, ул. Баумана, 20
Отпечатано с готового оригинал-макета
ИП Казанцев Д.В.
420034, г. Казань, ул. Энергетиков, д. 5

16+